ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# КИЛЕШҮ-ХОКУК ЯЗМАЛАРЫ

## XVIII–XX гасыр башы

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2023

**УДК 930.2**
**ББК 63.212**
**К 37**

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

**К 37** Килешү-хокук язмалары (XVIII–XX гасыр башы) / төз. Р.Ф.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2023. – 224 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 32 нче китап).

Китапта татар телендәге тарихи чыганакларның бер төре – хосусый актлар тупланды.

1736 елдан алып 1923 елга кадәрге арада төрле даталарга караган сату-алу, васыятьнамә, мирас бүлешү, тәрбиягә бала бирү, хезмәткә яллану һәм башка шундый – егермедән артык төрдәге – 120 текст искәрмәләр һәм аңлатмалар белән тулыландырып бирелде.

Мондый төр кульязмалар – үз чорларын чагылдыра торган алыштыргысыз тарихи истәлекләр.

ISBN 978-5-88473-100-4

**УДК 930.2**
**ББК 63.212**

© Мәрданов Р.Ф., 2023
© «Милли китап» нәшрияты, 2023

# «РАСЛЫГЫНА ТАМГАЛАРЫБЫЗ САЛДЫК...»

«Татар археографиясе» сериясенең бу басмасында гарәп хәрефле татар кулъязмалары арасында күп очрый торган килешү-хокук язмалары туплап бирелде. Алар фәндә хосусый актлар дип йөртелә һәм язма тарихи чыганак буларак өйрәнелә.

Хосусый акт – аерым кешеләр арасындагы хосусый һәм милек мөнәсәбәтләрен татар телендә теркәгән килешү, алыш-биреш, сату-алу, мирас, никах, васыять һәм башка шундый хокук документы. Алар, гадәттә, ике тараф кешеләренең, шаһитларның имзалары (яисә тамгалары) белән, кайбер очракларда мөһер белән расланган. Мондый төр язма истәлекләрнең барысының да диярлек тарихлары тирән һәм уртак – алар ислам шәригате өйрәтмәләренә нигезләнгән һәм алар архив материаллары белән бер дәрәҗәдәге документаль чыганак булулары ягыннан әһәмиятле.

Тарихчы һәм археограф Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин (1953–2019) татар хосусый актларын тарихи чыганак буларак фәнни нигездә тәфсилләп өйрәнгән иде. Аның бу темага багышланган хезмәте китап булып басылды[1]. Ул татар халкының үз дәүләтеннән мәхрүм булып яшәгән хәлендә дә язма юридик мөнәсәбәтләрен туган телдә теркәү күренеше яшәп килгән дип язган. Галим татар хосусый актларының төрләре итеп сату-алу, төрле милекне алмашу һәм закладка салу, товар-кредит мөнәсәбәтләре, бүләк итү, васыять итү, мирас бүлү, вәкыф кылу, үзара булган низаг-дәгъваларны көйләү, никах

[1] Миннуллин З. Татарские частные акты XVII – первой половины XIX в.: источниковедческая характеристика. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. – 150 с.

һәм аерылышу кебекләрне атаган[2]. Җ.Миңнуллин татар хосусый актларын төп 6 өлешкә (никах-гаилә, яллану, милекне бушка бирү, акча алу, үзара килешү, алыш-биреш) бүлгән һәм алар һәрберсе өчтән алып сигезгә кадәр төрләрдән тора дип тәгаенләгән. Галим, үзе өйрәнгән материаллар нигезендә, татар хосусый актларының барлыгы 29 төрен ачыклаган[3].

Быелның көзендә – ноябрь аенда Җәүдәт Миңнуллинның тууына 70 ел тула. Ул безнең остазыбыз, коллегабыз һәм киңәшчебез иде. «Безнең» дигәндә, Милли китапханәнең директор урынбасары Ирек Һадиевны, Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинны һәм бу юлларны язучы үземне күздә тотам. Мәрхүм Җәүдәт әфәнденең татар кульязмалары өлкәсендәге эшчәнлеге, археографик экспедицияләргә бәйләп, «Татар археографиясе» сериясенең 30 нчы китабында берникадәр тасвирланды[4].

Сериянең хәзерге – 32 нче басмасын замандашыбыз, тарихчы, археограф галим һәм текстолог Җәүдәт Миңнуллинның якты истәлегенә ихлас хөрмәтебез билгесе булсын дип ниятләдек.

Татар телендәге хосусый актларның өйрәнелү тарихы, гомуми халәте, тарихи чыганак буларак әһәмиятләре, мәгънәви кыйммәтләре, саклану урыннары һәм башка мөһим мәсьәләләре Җ.Миңнуллинның әйтеп үтелгән хезмәтендә нигезле тасвирланган[5]. Шул сәбәпле, татар хосусый актларына киң рәвештә тукталу ихтыяҗы юк. Без бары тик әлеге – үзебезнең китап-

---

[2] Шунда ук. – Б. 25.

[3] Шунда ук. – Б. 109.

[4] Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2022. – 250 б.

[5] Җ.Миңнуллин китабының 13 нче битендә материаллары кулланылган 6 оешма һәм бер шәхси архив телгә алынган. Алар арасында Татарстан Республикасының Милли китапханәсе булмавына аңлатма бирү таләп ителә. Хикмәте шунда ки, Җ.Миңнуллинның 2020 елда басылып чыккан фәнни хезмәте – тарих фәннәре кандидаты исеменә 1988 елда якланган диссертациясенең тексты. Ә Милли китапханәдә кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге берничә ел соңрак – 1992 елда оештырылган иде.

ка кергән текстларга бәйле күзәтү ясау һәм кайбер гомуми фикерләрне белдерү белән чикләнәбез. Җ.Миңнуллинның бу темага багышланган хезмәте фәнни яктан кыйммәтле булганлыктан, без аңа бу китапта еш мөрәҗәгать итәрбез, кайбер чагыштырулар да язылыр.

Халкыбызның фаҗигаләр белән тулы тарихындагы күп сәбәпләр аркасында татар хосусый актларының калдык фрагментлары һәм ялгыз үрнәкләре генә сакланып калган, берәр төбәк яки аерым чорга караган тулы комплекс документлар юк дип, Җәүдәт Миңнуллин бик хаклы әйткән[6]. Шулай да, андый төр кулъязма истәлекләрнең сакланган хәтлесе дә бик күп һәм галимнәрнең өйрәнүенә мохтаҗ.

Бу җыентыкта 120 данә хосусый акт тексты: төп нөсхәләр, күчермәләр һәм формуляр-калыплар урын алды. Алар – сатуалу, вәкыф итү, мирас бүлү, аерылышу, солыхнамә, баланы тәрбиягә бирү, васыятьнамә – гомумән, барлыгы егермедән артык төрдәге хосусый акт үрнәкләре. Текстларның зур күләмлеләре дә, аз гына мәгълүматлылары да бар. Алар хронологик яктан 1736 елдан алып, 1923 елга кадәрге вакытка нисбәтле. Биш документ совет хакимлеге урнашканнан соңгы 1919–1923 елларга карый. Хәер, алары да йөз елдан элеккеге инде. Соңгырак чорныкылар гасырлар буе дәвам итеп килгән татар язма документлары традицияләрен саклаган булулары һәм тарихи әһәмиятләре ягыннан игътибарга лаек. Гомумән, бу җыентыктагы текстларның XVIII гасырга караганнары – 38, XIX гасырга нисбәтлеләре – 71 һәм XX гасырның беренче чирегенекеләр – 11 данә.

Китапта урын алган текстларның җидесе формулярлар, ягъни язылырга тиешле документларның үрнәкләре-калыплары. Аларның өчесе хәлегънамә (бу китапта №№17, 30, 105), калганнары васыятьнамә (№36), гаһеднамә (№37), инабәт язуы (№103) һәм солыхнамә (№35) формулярлары. Соңгы икесе үз эчләрендә ике һәм өч варианттан тора. Хәлегънамә формуляр-

[6] Миннуллин З. Татарские частные акты..., 2020. – С. 51.

ларыннан 30 нчы сан белән билгеләнгән 1768 елгысында кеше исемнәре дә аталган, ә 1794 елгы солыхнамә формулярлары вариантларының өчесендә дә тамга рәсемнәре ясалган.

Төрле килешүләр теркәлгән кульязма истәлекләр фәнни китапханәләрдә электән тупланып килгән, Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә исә 1992 елда кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге оештырылган вакыттан алып хәзергәчә җыела. Шул исәптән, соңгы еллардагы археографик экспедицияләрдә дә хосусый акт язмалары табылып тора. Милли китапханәнең быелгы – 2023 ел җәендә – оештырылган археографик экспедициясендә табылган хосусый актларның да берничәсе бу басмада урын алды. Гомумән, китапка кертелгән кульязма документларның күпчелеге (барлыгы 94 текст) Милли китапханәдә саклана, Россия дәүләт борынгы актлар архивы фондларыннан 16 текст (№№1–16) алынды, Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегеннән җиде текст (№№40, 91, 92, 94, 96, 99, 100), Татарстан Республикасының Милли музеендагы Зәйнәп Максудова фондыннан өч кульязма истәлек тексты (№№29, 83, 95) кулланылды.

Китапка кергән килешү-хокук язмаларының сакланышлары төрлечә: бик яхшы хәлдәгеләре булса да, күпчелеге тузган һәм таушалган. Кайберләренең кәгазьләре соңрак бер-берсенә ябыштырылып, башка кульязма китапларга тышлык өчен катыргы сыман кулланылганга күрә, андыйларның сакланышлары аеруча аянычлы.

Тупланган кульязма истәлекләрдә гади кешеләр белән бергә, татар тарихында мәшһүр шәхесләрнең исемнәре дә очрый. Мәсәлән, Котлыгмөхәммәт морза Тәфкилев исеме. Кайбер хосусый актлар танылган имамнар һәм тарихчылар Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Әмирханов тарафыннан кәгазьгә язылган. Шулай ук Оренбург Каргалысында имам һәм мөдәррис булган Габдрахман Кирмәнигә, хәзерге Әтнә районындагы Яңа Шимбер һәм Тәтеш районындагы Үтәмеш авылларында имамлык иткән Минуш Мостай улына, хәзерге Ютазы районында-

гы Бәйрәкә авылының мулласы, ишан Габделгали Гобәйдулла улына һ.б. бәйле документлар бар. Казан шәһәренең мәшһүр сәүдәгәрләреннән Юнысовларга, Мөхәмммәтшакир Мусинга, Үтәмешевләргә бәйле хосусый актлар да аерым әһәмияткә ия.

Милли китапханә хезмәткәрләренең быелгы җәйдә Арча районына оештырган экспедициясе вакытында табылган 1779–1781 еллардагы язмалар, әүвәлгерәк булулары белән бергә, Пугачёв күтәрелешендә полковник дәрәҗәсендә катнашкан Ямансарый Җәббар улына һәм аның улы Киекбай Ямансарый улына турыдан-туры бәйлелеге ягыннан аеруча мөһим.

Исемнәре билгеле булган башка шәхесләр турында һәм кайбер бүтән кызыклы тарихи мәгълүматлар китапта аерым текстларга карата язылган искәрмәләрдә дә бар. Мәсәлән, Минуш мулланың күп буынлы шәҗәрәсе һәм нәсел тарихы, шагыйрь Даут Гобәйдинең фаҗигале язмышы һ.б.

Тарихчы Җәүдәт Миңнуллин китабында XIX гасыр уртасына кадәрге чор документлары өйрәнелгән булса, бу китапта аннан соңгы 70 елдан артык вакыттагылары да урын алды. Алар, татар телендәге хосусый актларның бай һәм күпкырлы традицияләре XX гасыр башына – совет чорына кадәр дәвам иткәнлеген тулырак күзалларга ярдәм итә.

Татар телендә язылган хокук-килешү документлары үз чорларының кыйммәтле чыганаклары буларак кадерле һәм алар, һичшиксез, тәфсилләп өйрәнүгә лаек.

Китаптагы хокук язмаларын түбәндә төркемләп язып, берникадәр күзәтү ясап китәбез.

### Алыш-биреш килешүләре

Бу китапта тупланган хокук-килешү документларының шактые (барлыгы 44 язма) үзара алыш-биреш гамәлләре турында[7]. Ягъни, бер бай кешедән үз авылдашлары һәм күрше-

---

[7] Җ.Миңнуллин да үзе өйрәнгән татар хосусый актларының күпчелеге (иллегә якыны) алыш-биреш һәм сату-алу турында булуын искәрткән (Миннуллин З. Татарские частные акты..., 2020. – С. 94).

тирәдәге бүтән авылларда яшәүчеләр бурычка акча алып, аны әйберләтә (кап сугып, ашлык яисә он, умарта, бал һ.б. белән) кайтару турында килешкәннәр. Авыл кешеләренең бурычка акча алулары, нигездә, салымнар түләү ихтыяҗыннан булган. Андыйлар документларда «иманама» һәм «имана тугрысына» дип язылган. Бурычны түләү-кайтару вакыты «шомырт чәчәгенә төшкән вакытта, киләсе җәйгә, сабанга төшкәч, көзгә, раштуага» һ.б. рәвештә билгеләнгән. Православие диненең зур бәйрәмнәре вакыт билгеләү өчен еш кына нигез булган. Мәсәлән, Пукрау, Микул, Спас кебекләр (моның хикмәтенә түбәндәрәк тукталырбыз).

Бурыч алучы тарафыннан «йөкче» (поручитель) исеме дә теркәлгән. Әгәр бурыч, килешенгән әйбер белән кайтарылмаса, аны алган кеше (ул түләмәсә, «йөкче»се) үзенең атын, сыерын, имана җирен яки башка нәрсәсен сатып түләргә вәгъдә кылган. Түләү вәгъдәсе берничә көн печән чабу, иген урып бирү һ.б.ш. кул хезмәте белән дә башкарылган.

Китаптагы документларның берсендә (№27) йөкче сыйфатында хатын-кыз – Хәмидә Биккол кызы язылган булуы – үзенчәлекле һәм сирәк күренеш.

Үзара килешү кәгазенә бурычка алучы, йөкче һәм шулай ук шаһитлар кул куйганнар яисә тамга салганнар.

Алыш-биреш, сату-алу һ.б. килешү язмаларыннан бу китапта ике дәфтәрнең материаллары тулысынча диярлек кулланылды. Беренчесенең сакланышы шактый начар, икенчесе уртача.

Дәфтәрләрнең беренчесе Үти (хәзерге Буа районындагы Бик-Үти) авылы кешесе Мөхәммәт мулла Хаҗи улының 1764–1767 еллардагы язмалары. Аның дәфтәрендәге 11 текст китапта урын алды. Бу кеше үзе яшәгән авыл һәм күрше-тирәдәге барлыгы 7 авыл кешеләре белән (кайберләре белән берничә мәртәбә) алыш-биреш иткән. Китапта бирелгән текстларның 18 нче сан астындагысында аның барлыгы 9 кеше белән, 22 нче сандагысында 7 кеше белән, 27 нче сандагысында 4 кеше белән алыш-биреш иткәнлеге теркәлгән.

Мөхәммәт Хаҗи улы эш йөрткән авыллар Зөя өязенең Ак-



*Мөхәммәт мулла Хаҗи улының дәфтәре. 1764–1767 еллар (Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «543т» шифры белән саклана)*

кылыч сотнясына кергәннәр. Тарихи чыганаклардан билгеле булганча, «кенәз Аккылыч сотнясы» атамасының тарихы борынгыдан килгән. Ул – 1568 елда оештырылган Зөя өязендәге дүрт татар кенәзе исемнәре белән бәйле сотняларның[8] – административ берәмлекләрнең берсе. Башка сотнялар – Ишәй, Тимәй һәм Бикбулат исемнәре белән атап йөртелгән. Кенәз Аккылыч сотнясы шуларның иң зурысы булган. Гарәп язулы

[8] *сотня* – татар ханлыклары заманындагы хәрби-административ «меңлек»ләр һәм «йөзлек»ләр үрнәгендә рус империясендә дәвам иткән административ

татарча кульъязмаларда әлеге исем «Аклыч» рәвешендә язылган булса да, аның Аккылыч булганлыгы шик уятмый, чөнки элеккерәк текстларда (XIX гасыр башына кадәр диярлек) бер үк аваз ике мәртәбә кабатланган татарча сүзләрдә һәм исемнәрдә хәреф бер генә мәртәбә язылган. Аккылыч исеме башлангычта «Хаккылыч» булгандыр, ягъни «Хак (Алла) кылычы», «Хак дин кылычы» мәгънәсендә. Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынма сүзләрдәге «х» авазын төрки-татарлар еш кына төшереп калдырганлыгы билгеле. Шул сәбәпле, Хак сүзе Ак булып киткән. Бу исемгә аваздаш мәгънәдәге, гарәп теленнән кергән Сәйфулла һәм Сәйфетдин исемнәре дә татарларда киң кулланылган.

Кенәз Аккылыч Тугыш улының (1587–1637) әтисенә (Тугыш Дәүләтбахты улына) патша Иван Грозный вакытында бик зур җир-су биләмәләре бирелгән. Әтисеннән күчкән биләмә территориясе улы Аккылыч исеменә бәйләп XVII–XVIII гасырларда (1781 елга хәтле) кулланылышта йөргән.

«Татар археографиясе» сериясенең 28 нче китабында бу нәсел шәҗәрәсенең бер тармагы турындагы мәгълүматны бастырган идек. Анда болай язылган: «Габдеррәшид бине Җарбану бинте Сөләйман бине Көнтуган бине Җанбулат бине Киләй бине Килкә бине Килмәт бине кенәз Тимәй. Янә дәхи кенәз Аккылыч. Бу кенәзләр дүртесе бертугма кардәшләрдер. Анларны падишаһ әгъзам хөрмәтләп, кенәз атап сотня виргән. Ислам дине үзәренә карар кылганнар һәм бүген дә ушандак ул түрт кенәз исеме берлә түрт сотня атарлар»[9]. Әлеге мәгълүматта Габдеррәшид исемле зат үзенең әнисе Җарбану ягыннан бул-

---

бүленеш берәмлеге. Баштарак ул рус телендәге «сотня» сүзе белән аталган, XVIII гасыр ахырындагы реформадан соң административ берәмлек мәгънәсендәге татарча «йөз» сүзенең «өйез» дигән әйтелеше нигезендә «өяз» дип үзгәртелгән (русча: уезд). Бу китаптагы 16 нчы санлы документта «сотня» административ берәмлеге «ил» дип аталган булуы белән үзенчәлекле.

[9] Шәҗәрәләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2021. – Б. 148.

ган тармакны теркәгән. Анда дүрт бертуган турында әйтелсә дә, аларның икесе генә – Тимәй белән Аккылыч кенәз исемнәре генә язылган. Шулай да бу язмадан аңлашылганча, Тимәй, Аккылыч, Ишәй һәм Бикбулат кенәзләр дүртесе бертуган булган. Бу турыда үз нәсел дәвамчылары язып калдырган мәгълүмат ышанычлы булса кирәк.

Үти авылы кешесенең дәфтәре шактый начар сакланганлыгы сәбәпле, текстлары тулысынча укырлык булмаса да, танылган кадәрле мәгълүматларының әһәмияте зур. Аларда төрле авылларның муллалары исемнәре теркәлгән булуы да мөһим. Чөнки ул чордагы муллаларның исемнәрен башка төр чыганаклардан ачыклау мөмкин түгел диярлек. Әлеге дәфтәрдә исә Әлки авылының Габдери мулла һәм Гадел абыз, Бик авылының Морадбакый мулла, шулай ук Мостай абыз, Рахман мулла, Солтангали мулла исемнәре теркәлгән.

Икенче дәфтәрнең иясе – хәзерге Теләче районындагы Урта Мишә авылының Хәмзә Максуд улы. Аның дәфтәреннән бу китапка 1822–1833 еллар арасында теркәлгән 36 хосусый акт тексты кертелде. Бу зат та үз авылы һәм күршедәге – барлыгы 11 авыл кешеләре белән эш йөрткән. Хәмзә, бай, күрәсең, өлкән яшьтә[10] булгандыр, чөнки кайбер язмаларда ул «Хәмзә агай» диелгән. Аның үзе тарафыннан 1822 һәм 1824 елларда теркәгән язмаларындагы «Мамадыш округының Казан өязенең Йөри юлы» дигән гыйбарәсендә әүвәлгерәк административ берәмлек исемнәрен кулланган булуы да өлкән яшьтә булгандыр дип уйларга нигез бирә. Чөнки ул вакытта «Казан өязенең Йөри (Җөри) юлы» дигән рәсми берәмлек гамәлдән чыкканына ярты гасырга якын вакыт узган булган[11]. Икенче яктан караганда, бу кызыклы тарихи факт – кайбер атамалар,

[10] Аның яшәгән елларын халык исәбен теркәү документларыннан ачыкларга мөмкин.

[11] Бу факт Җ.Миңнуллинның, элекке архаик административ-территориаль атамалар, шул исәптән «юл» дигәне XVIII гасыр ахырыннан татар хосусый актларында кулланылмаган, дип язган фикерен (Миннуллин З. Татарские частные акты..., 2020. – С. 105) кире кага.



*Хәмзә Максуд улының дәфтәре. 1822–1833 еллар (Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «1047т» шифры белән саклана)*

кулланылудан туктаганнан соң да, гади халыкның гамәли язмаларында һәм хәтерендә тиз генә җуелмаганын күрсәтә.

Шушы ике дәфтәрдә теркәлгән алыш-биреш әйберләре, халыкның моннан ике гасыр һәм ике гасыр ярым әүвәлге көнкүрешен күзалларга ярдәм итә. Аларда теркәлгән кеше исемнәре генә дә кызыклы бер туплам дияргә мөмкин. Православие динендә саналган керәшен исемнәренең шул чордагы халык телендә кулланылышы ономастика җәһәтеннән дә игътибарга лаек. Мәсәлән, Бәчели, Йәпим, Җәкәү, Җәким, Җәпим, Илҗә, Мекетә, Микәйлә, Микипар, Пәчили, Пәчкә, Питруш, Турыфим, Ылука һ.б.

Китапта урын алган текстларда «керәшен» дип язылган кешеләрнең бер өлеше «яңа керәшен» дип исәпләнгән һәм соңрак ислам диненә кире кайткан төркем вәкилләре булган. Мәсәлән, Үти авылы кешесенең дәфтәрендәге исемнәре

дә шуңа ишарә итә: Бәшир керәшен Мөслим улы, Мөхәммәт керәшен Бәймәт улы һ.б.

Тупланган алыш-биреш язмаларыннан күренгәнчә, мөселман татарлар белән берлектә христиан динендәгеләр, кайбер очракларда башка халык вәкилләре дә (мәсәлән, чувашлар, удмуртлар) көнкүреш мәсьәләсендә үзара тыгыз бәйләнештә гомер кичергәннәр.

***

Алыш-биреш язмаларында алынган бурычны түләү вакыты итеп еш кына православие бәйрәмнәренең берәрсе язылган дип алда әйтеп үткән идек. Мөселман татар кешеләренең үзара килешкән язмаларында чит дин бәйрәме һәм изгеләренә бәйле көннәрне күрсәтү – гайре табигый күренеш. Әмма моның сәбәбе, безнең уебызча, XVIII гасыр башында рус дәүләтенең төрле хокукый мөнәсәбәтләрне язма рәвештә мәҗбүри теркәүне керткән кануннарына бәйле булган. Алар нигезендә гамәлгә куелган рус телендәге канцелярия документлары татар хосусый актларына да турыдан-туры тәэсир иткән.

Россия империясендә яшәгән татарлар үзара килешүләрен күпчелек очракта татар телендә язарга гадәтләнгән булсалар да, аларның хокукый көче дәүләт кануннары буенча сирәк очракта гына танылган. Шул сәбәпле, хосусый хокук мөнәсәбәтләрен – төрле килешү язмаларын татарлар да дәүләт оешмаларында – губерна һәм өязләрдәге канцелярияләрдә рус телендә яздырганнар. Аларда рәсми рәвештә документ яздыру өчен пошлина түләүләре каралган.

Андый оешмалардагы хезмәткәрләр – тәрҗемәчетылмач, язучы-писарьлар рус кешеләре буларак, алыш-биреш язмаларында билгеләнгән вакыт-срокларны еш кына христиан бәйрәмнәренә тиңләштерергә күнеккәннәр. Шундый ук күренешнең ике татар кешесе килешүләрендә дә кулланылган мисалларын Мәскәү шәһәрендәге Россия дәүләт борынгы актлар архивында шактый күрдек, кайберләрен күчереп

тә алган идек. Мәсәлән, Аккуҗа[12] авылы кешесе Нияз Корманай улының хатыны Мәрҗән Темәс кызы Казан татары Илкә Иштирәк улыннан 1709 елның 25 июлендә 100 сум акча алган һәм «Успение Пресвятой Богородицы»[13] көнендә кайтарырга тиеш булганлыгы Уфа өязенең Каракулино канцеляриясендә теркәлгән. Шул ук оешмада 1712 елның 5 мартында татар кешесе Ураз Янмурзин икенче бер татар Юныс Кадышевтан 3 сум алып, «Алексей көне»ндә («Алексеев день»)[14] кайтарырга ризалашулары теркәлгән. Шул ук елның 6 апрелендә татарлардан Тенибай исемлесе Троица[15] бәйрәменә кайтару вәгъдәсе белән Үрмәт исемле берәүдән 12 сум бурычка алганлыгы, 28 сентябрьдә исә бер рус кешесе Бикчура исемле татардан «Дмитрий көне»нә кайтару вәгъдәсе белән 5 сум алганы теркәлгән. Мондый мисаллар шактый. Гомумән, Каракулино канцеляриясендә XVIII гасырның беренче яртысында теркәлгән рәсми язуларда татар белән татар, татар белән рус яисә русларның үзара алыш-бирешләре документларында акчаны кайтару вакыты еш кына православ бәйрәмнәре яки христиан изгеләренең көннәре белән тәгаенләп теркәлгән. Нәкъ менә шундый рәсми канцелярияләрдә рус телендә төзелгән документлар татарларның туган телләрендә үзара язышкан килешүләренә дә тәэсир иткән дигән нәтиҗәгә килдек.

Дәүләт оешмасында язылган русча документлардан татар хосусый актлары бары тик язган өчен пошлина акчасы түләнмәве белән генә аерылып торган. Ә рус һәм татар телләрендәге килешү язмалары текстларының төзелешләрендә формаль аермалар юк диярлек. Мәсәлән, Каракулино канцеляриесендә язылган бер документка мөрәҗәгать итик һәм аны бу китаптагы татарча алыш-биреш язмасы белән чагышты-

[12] Татарстан Республикасының Әгерҗе районы территориясендә элек булган, хәзерге вакытка беткән Иске Аккуҗа авылы.

[13] *Успение Пресвятой Богородицы* – хәзерге календарь буенча 28 августка туры килә торган христиан бәйрәме көне.

[14] *Алексеев день* – элекке календарь буена 30 мартка туры килгән.

[15] *Троица* – хәзерге календарь буенча 31 май көненә туры килә.

рып карыйк. 1712 елда теркәлгән рус телендәге документ:

«Апреля в 23 день Казанского уезду Арские дороги деревни Назяр татарин Асян Уразметев занял деньги в Каракулине Уфинского уезду Казанские дороги деревни Салауш у Ишалея Сартыкова пятнатцеть рублёв до сроку до Петрова дни[16] сего ж году.

А порукою ручатся нижеподписавшиеся.

Заимшик Асян знамя приложил.

Порутчик Казанского уезду тоеж деревни Назяр татарин Усман Досаев знамя приложил.

*Толмачил Гаврило Калашников.*

*Свидетель Иван Каракулин.*

*Писал Григорей Гурьев.*

*За письмо и от записки деньги взяты».*

Бу документта аталган Назяр һәм Салауш – хәзерге Әгерҗе районының Наҗар һәм Салагыш авыллары. «Порутчик» дигәннәре «поручитель», ягъни татарча язмалардагы «йөкче», «знамя приложил» гыйбарәсе «тамга салды» дигәнне белдергән. (Документта тамгалары да куелган).

Чагыштыру өчен татар телендәге алыш-биреш язмасы текстына (бу китапта №26) мөрәҗәгать итик:

«Тарих мең дә йите йөз дә алтмыш йитенче елда ирде, Зөя өязенең [кенәз Аккылыч] сутнәсенең Кужак авылының Шабай Хөсәен угылы алдым түрүт сум акча Үти авылының Мөхәммәд мулла Хаҗи угылындин.

Түләр вәгъдәм – Зимли Микулыдыр.

Мин – Шабай Хөсәен угылы түләмәкче булып тамгам салдым.

Мин – Яһүдә Мостай абыз угылы түрүт сум акчаны Мөхәммәд мулла Хаҗи угылына түләмәкче булып, йөкче булдым һәм тамгам салдым».

Бу тексттагы «Зимли Микулы» дигәне православиенең «Кышкы Никола» көне.

Менә болардан хөкүмәт оешмасында рус телендә

---

[16] *Петров день* – хәзерге календарь буенча 12 июль көненә туры килә.

язылган һәм татарлар тарафыннан теркәлгән алыш-биреш килешүләренең текст калыплары бер төрле үк булганлыгы ачык күренә. Русча документның курсив белән бирелгән өлеше генә татарча текстта юк. Бу мисаллар – очраклы гына хәл түгел, чөнки андый үзенчәлек күпчелек текстларга хас. Шунлыктан, татар телендәге алыш-биреш язмалары XVIII гасыр башындагы хөкүмәт оешмаларына куелган таләпләргә тәңгәлләштереп язылганнар дигән нәтиҗә ясадык. Андый тәңгәллек, беренче нәүбәттә, әгәр дә ихтыяҗ чыкса, мәхкәмә өчен документны рус теленә тәрҗемә иткәндә артык мәшәкать тумасын өчен эшләнгән булуы ихтимал. Бәлки гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган алыш-биреш язмаларының бер өлеше хөкүмәт канцелярияләре өчен махсус алдан әзерләп куелган нөсхәләр булгандыр. Һәрхәлдә, татарча килешүләрнең рус телендәге шундый ук документлар калыбынча (үзенә күрә унификацияләнеп) теркәлгән булуы шик уятмый.

Килешүне дәүләт канцеляриясендә яздырудан татар кешеләрен тоткарлаган сәбәпләрнең беренчесе – чит телдә яздыру кыенлыгы булса, икенчесе – аның өчен акча түләргә кирәклеге һәм өченчесе – канцеляриягә күп чакрымнар үтеп бару мәҗбүрияте булган.

Югарыда китерелгән русча документны язган өчен «деньги взяты» дип кенә күрсәтелгән булса да, башкаларында төгәл бәяләре теркәлә торган булган. Мәсәлән, 1720 елда ике татар кешесе арасындагы 25 сумлык алыш-биреш документында канцеляриягә түләнгән акча күләме мондый рәвешле: «С тои заёмной пошлины осмнатцать копеек, в том числе за письмо и за переписку пятнатцать копеек, от записки три копейки».

Монда мисал итеп китерелгән рус телендәге архив материаллары Россия Дәүләт борынгы актлар архивындагы 615 нче фонд («Каракулинская крепостная контора») эшләреннән алынды. Шул ук архивтагы 529 нчы фонд («Мензелинская воеводская канцелярия») эшләрендә дә XVIII гасырда русча язылган килешү документларын шактый күргән идек. Әлеге фондларда саклана торган, татарларга бәйле хокукый килешүләр төрле

мәсьәләләргә караган: күпчелеге бурычка акча алуныкы булса, хезмәткә яллану язмалары да байтак, шулай ук солыхнамә, җир сату, мәһәр түләтү һ.б. бар.

### Васыятьнамәләр

Бу төр документлар башкаларыннан текстларының зур күләмле булуы белән аерылып тора.

Татар кешесе ерак сәфәргә (мәсәлән, хаҗга) чыгар алдыннан, кинәт көчле сырхауга дучар булып савыкканнан соң яисә, гомумән, сәбәпсез генә, шәригать таләбенчә васыятьнамәсен язган (яки яздырган). Еллар узгач аны яңартып, үзгәртебрәк һәм төзәтеп язган очраклар булган. Яңартылган васыятьләр язылган очракларда да, элеккеләрен саклаганнар. Мәсәлән, тарихчы Ризаэтдин Фәхретдин данлыклы Эстәрлебаш авылында имам һәм мөдәррис булган Дәүләтшаһ Гаделшаһ улының 1788 һәм 1806 елларда язылган ике васыятьнамә текстларын бастырган[17]. Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә 1970 нче елларда иске нөсхәсеннән күчерелгән бер васыятьнамә саклана (саклану шифры – «7127т»). Ул – Гайнулла Сәидевнең 1926 елда хаҗга китәр алдыннан язылган васыяте. Әйтеп үтелгәннәр кебек үк, бу китапта текстлары басылган кайбер васыятьнамәләр дә үз ияләренең иң соңгы васыять вариантлары булмаска мөмкин.

Китапта барлыгы 9 васыятьнамә тексты бирелде. Иң элеккесе – васыятьнамәнең формуляры (36 нчы санлы текст) XVIII гасыр ахырына карый[18]. Бу текст «ошбу тәзкирәдер» дип башланып китүе белән дә әһәмиятле, чөнки «тәзкирә» сүзе – рәсми

---

[17] Фәхреддин Р. Асар: мәмләкәтемездә улан ислам галимнәренең вә мәшһүр кемсәләренең тәрҗемә вә табакаләре, тарихе виладәт вә вафатлары вә башка әхвальләре хакында язылмыш китаптыр. Беренче җилд, алтынчы җөзъэ. – Оренбург: М.-Ф.Кәримев матбагасы, 1904. – Б. 280–283; Фәхреддин Р. Асар. 1 том / төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: «Рухият» нәшр., 2006. – Б. 133–135.

[18] Җ.Миңнуллин хезмәтендә тикшерелгән иң элекке васыятьнамә формуляры 1834 елга нисбәтле (Миннуллин З. Татарские частные акты..., 2020. – С. 55).

документ дигән мәгънәгә ия. Формулярның ахырында «тәхрире мәүлана мулла Габдеррахман әл-Кирмәни» («остазыбыз мулла Габдеррахман әл-Кирмәнинең язуы») диелгән мәгълүматы игътибарга лаек. «Тәхрир» сүзе – әлеге текстны язган кеше дигәнне белдерә. Текстны күчереп язучыны белдергәндә татар кулъязмаларында «кәтәбә», «кәтәбәһә» сүзләре яисә «язды» диелгәнлеге мәгълүм. Өстәвенә, бу китапның текстын башка кеше күчергән һәм аның исеме аерым күрсәтелгән[19]. Ихтимал, чынлыкта да, васыятьнамәнең татар телендәге мондый калыбы Габдрахман Кирмәни тарафыннан хәзерләнгән булгандыр. Аның гарәп телендәге калыпны татарчага тәрҗемә итеп язганлыгы текстологик үзенчәлекләреннән аңлашылып тора. Һәрхәлдә, бу мәсьәләне галимнәр махсус өйрәнеп ачыклык кертә алыр. Бу китапта урын алган XIX гасырдагы бер (№107) һәм 1920 елга караган ике (№№117, 118) васыятьнамәдә Кирмәни язган калыпның гарәп телендәге варианты өлешчә чагылыш тапкан.

Бу текстның авторы буларак күрсәтелгән мулла Габдрахман әл-Кирмәни – Оренбург янындагы Каргалы авылында имам булып торган Габдрахман Мөхәммәт улы Кирмәни (1743–1826) булса кирәк. Аның турында Ш.Мәрҗани болай дип язган: «Тумышы белән Ханкирмән шәһәреннән. Оренбург Каргалысына килеп, ... гыйлем алып, Каргалыда имам, хатыйб һәм мөдәррис булган. Шәкертләре күп булып, озын гомер сөреп, шөһрәт белән дәрес әйтеп, 1242 (1826) елда, сиксән өч яшендә Каргалыда вафат була. Заманының иң шөһрәтле галиме иде»[20]. Ризаэтдин Фәхретдин шулай ук Габдрахман Кирмәнине зурлап: «Бу зат мәмләкәтебездә булган галимнәрнең иң гыйлемле һәм укымышлыларыннан» дип бәяләгән һәм өч дистәгә якын

---

[19] Бу китап өчен кулланылган васыятьнамә калыбы текстында Кирмәнинең «мәүлана – остазыбыз» дип аталган булуына караганда, аны Габдрахман Кирмәни шәкертләреннән берсе күчергән.

[20] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б. 269–270.

шәкертләренең исемнәрен теркәгән, үз уллары һәм оныклары да имамнар булганлыгын әйткән[21].

Шундый ук диярлек васыятьнамә формуляры Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең «852г(719)» шифрлы, XIX гасырга караган кулъязма җыентыкта да бар. Анда васыятьнамә калыпларының өч төрле тексты теркәлгән. Беренчесе – «Васыять бәянидыр» диелгәне (кулъязмада 26а–28а кәгазьләрдә) – Г.Кирмәни варианты кебек диярлек, фәкать кайбер сүзләрдә зур булмаган аермалары бар. Анда васыять иясенең исеме язылачак урын буш калдырылган. Ә китапта бирелгән 36 нчы текстта «Фәлән фәлән угылы» диелгән. Әлеге текстта шәргый бурычлар өчен мең сум сарыф итү турында әйтелгән, тик хаҗга кеше җибәрү турындагы сүзләр юк (күчерүче тарафыннан төшереп калдырылган булгандыр). «852г...» кулъязмасындагы формулярда исә хаҗга кеше җибәрү, шулай ук мәчет чыгымнары турында, кеше исемнәрен дә күрсәтеп язылган һәм «егерме мең сум» билгеләнгәнлеге әйтелгән. Шул ук кулъязма китапның 28а–29б кәгазьләрендәге һәм 10а–11б кәгазьләрендәге «Васыять язуы» дип аталган текстлар беренчесеннән аермалырак. Димәк, мөселман-татарлар арасында васыятьнамә язуның берничә варианттагы калыбы-формуляры кулланылышта йөргән.

Васыять язуның ислам тәгълиматыннан һәм борынгы дини китаплардан килгән гомуми формулярын күздән кичерик. Васыятьнамәне язучы (яздыртучы) кешегә сәламәт хәлендә һәм төзек акылында, үз ихтыярында булуы шарт ителгән. Васыятьнамә таләбе буенча ул үзенең иманын шәһадәт сүзләре белән тәгаенләгән, тәүбә иткән һәм Алладан ярлыкау сораган. Гаиләсен, балаларын һәм якыннарын ислам дине

---

[21] Фәхреддин Р. Асар. 1 том..., 2006. – Б. 116–117. Габдрахман Кирмәнинең вафат елы бу китапның әүвәлге басмасында һәм Мәрҗанидә һиҗри белән 1242 дип кенә язылган. Ә соңгы басмаларда: Ш.Мәрҗани китабында миладига 1826 ел дип, ә Р.Фәхретдин хезмәтендә 1827 ел дип күчерелгән. Моның хикмәте һиҗри 1242 елның беренче яртысы 1826 елга һәм икенче яртысы 1827 елга туры килгән булуга бәйле.



*Васыятьнамә формуляры (Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «852г(719)» шифры белән саклана)*

өйрәткәннәргә тугрылык сакларга һәм кушканнарын җиренә җиткереп үтәргә өндәгән.

Аннан соң васыять язуында үзе вафат булгач шәригать тәртибенчә соңгы юлга озату хәстәрен күрү зарурлыгы әйтелгән. Васыять итүченең укылмыйча калган намазлары, тотылмаган уразалары, түләнмәгән зәкят һәм гошерләре, шулай ук башка фарыз гамәлләре өчен махсус сәдакалар бирү, хаҗга бармаган булса, кеше яллап җибәрү өчен күләмен билгеләп акча билгеләү, кече яшьтәге балаларын тәрбия итәр өчен акча

тәгаенләү кебек нәрсәләр язылган. Үзе әйткәннәрне тормышка ашыру өчен васыять иясе якын кешеләренең берсен җаваплы итеп билгеләгән.

Васыятьнамәнең ахырында авторы үзе һәм шаһитлар имзаларын куйганнар, васыять документын язган кешенең исеме теркәлгән.

Төп калыбыннан тыш, һәр васыятьнамә текстының аерым үзенчәлекләре булганлыгы күренә. Мәсәлән, бу китапта бирелгән текстлардан Минуш мулланың XIX гасырның беренче яртысына караган васыятендә (№83) гаилә әгъзаларының бер-берсен ныклап кайгыртуларының зарурлыгы гаять үтемле һәм тәфсилле рәвештә нәсихәт ителгән. Минуш мулла үз васыятьнамәсен бүлекләргә бүлеп, хатынына, өлкән улына һәм башкаларына махсус мөрәҗәгать итеп язган.

Казан сәүдәгәре Мөхәммәтшакир Мусинның 1886 елгы васыятендә (№98), ике мәчет, ике мәдрәсә төзергә, коесыз авылларга ике кое казытырга дип, акча тәгаенләнгән.

Имам һәм мөдәррис Габделгали ишан Бәйрәкәвинең XIX гасырның икенче яртысына нисбәтле васыяте (№107) тулы түгел, аның динне тоту, саклау һәм яклау турындагы өлеше бар. Ул васыятен «балаларына, хатынына, оныкларына, дин кардәшләренә, ишаннарга, мәдрәсәдәге шәкертләргә һәм үзенең әмерен тотканнарга» багышлаган. Шәригать кысасына сыешмаган «сабантуй һәм тәкә җыены» кебек нәрсәләргә бармаска өндәгән, аларда гыйбрәт алырлык берни дә юк, дигән.

Гатаулла Габбаси үзенең диндарлык белән сугарылган васыятендә китаплар укырга киңәш иткән. Әмма шигырь, шаһнамә һәм сугышлар турындагы китапларны укудан тыелырга өндәгән, чөнки аларның файдасына караганда зарары күбрәк, дигән ул. 1920 елда язылган бу васыять китапта 117 саны астында урын алды.

1877 елда рус-төрек сугышына алыну ихтималы чорында запастагы солдат Насыйрҗан васыятендә (№96) һәм Ибраһим Әмин улының 1895 елгы васыятендә (№102) гаилә әгъзаларын кайгырту, мал-мөлкәт бүлү турында язылган. Хәбибҗамал

Госман кызының XIX гасырның икенче яртысына караган васыятьнамәсендә (№106) үзен соңгы юлга озату мәрасименә бәйле нәрсәләр бәян ителгән.

Шагыйрь Даут Гобәйдинең васыять-мөрәҗәгате (№116) дәһшәтле ватандашлар сугышы вакытында – 1919 елда язылган һәм авылдашларына адресланган. Ул васыятен язганнан соң өч атна узгач колчакчылар тарафыннан вәхшиләрчә җәзалап үтерелгән.

Шул рәвешчә, васыятьнамәләрнең һәрберсенең үзенчәлекләре аерым мәгънәгә һәм кыйммәткә ия.

***

Татар кулъязмалары арасында «Мөхәммәт пәйгамбәр васыятьнамәсе» дигән (исеме, гадәттә, «Васыятьнамә» дип кенә яки башкача да аталган) дини эчтәлекле текстлар күп очрый. Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә генә дә андыйларның XVIII гасырдан алып 1990 нчы елларга кадәрге чорга караган кырык берәмлеккә якын күчермәсе саклана. Әлбәттә, башка китапханәләрдә дә алар бик күп. Мондый төр васыятьнамәләрнең күпчелеге совет чорында (бигрәк тә 1930–1970 нче елларда) күчерелгән. Шуңа күрә, кайбер галимнәрдә һәм дини белемгә ия руханиларыбызда да «Пәйгамбәр васыятьнамәсе» совет чорында барлыкка килгән дигән ялгыш караш бар.

Совет хакимияте чорында аларның бик күп күләмдә күчерелгән булуы илдәге тарихи вазгыятькә – диннең тыелуына һәм эзәрлекләнүенә бәйле. Болар бит халыкның дәүләт сәясәте белән ризалашмаганының, газиз ислам диненә тугрылыгын сакларга тырышуының ачык бер дәлиле. Андый төр васыятьнамәләрнең әһәмиятле ягы шуның белән дә билгеләнергә тиеш. Ә археографик яктан караганда, әлеге васыятьнамәләрнең нөсхәләре һаман да табылып торуы – татарларда кулъязма күчерү традициясенең XX гасырда да дәвам иткәнлеге ягыннан игътибарга лаек.

«Пәйгамбәр васыятьнамәләре»нең текстлары элекке

кульязмаларда да бар. Мәсәлән, Милли китапханәдәге иң әүвәлге кульязма нөсхәсе 1782 елгы кәгазьгә язылган (ягъни, су билгесендә-филиграненндә шундый ел төшерелгән). Бу кульязманың китапханәдә саклану шифры «4341т». Шулай ук 1830, 1838 һ.б. елларга караганнары да бар. Ә 1930 елгы бер текст («6529т») үзеннән бер гасыр элеккеге – 1831 ел кульязмасыннан күчерелгән булуы белән игътибарга лаек. Шулай ук, 1933 елгыдан 1970 елда күчерелгән нөсхәне дә («6874т») искә алырга кирәк. «Пәйгамбәр васыятьнамәсе»нең элекке типография басмаларыннан күчерелгән нөсхәләре дә саклана. Мәсәлән, 1940 нчы еллардагы бер кульязма 1882 елгы басмадан күчерелгән («7284т»).

Халкыбызда гасырлар дәвамында күпләп күчерелгән һәм таралыш алган «Пәйгамбәр васыятьнамәсе»н дин галимнәребез тәфсилләп өйрәнергә, һичшиксез, форсат табарлар дип ышанабыз. Гасырдан-гасырга бер үк текст язып йөртелгәнме яисә ул үзгәрешләр кичергәнме – менә шундый текстологик хасиятләрен тикшерү белән бергә, аларның мәгънәви һәм рухи әһәмиятләре билгеләнер.

## Никах шартлары һәм хәлегънамәләр

Элекке татар кульязмаларында никахлашу язмалары һәм аның шартлары, ир белән хатынның аерылышуына бәйле текстлар еш очрый.

Никах турындагы берсенә тукталыйк. Мәшһүр Сәгъдинең фарсы телендә язылган «Гөлстан» әсәре теркәлгән, XVIII гасырның икенче яртысына нисбәтле, Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклан торган кульязма китапның ахыргы битендә никах тәртибе турында кызыклы бер язма бар. Анда борынгыча рәвештә «Изиемез, бер вә бар Тәңре Тәгаләнең ярлыгы торур» дип, Аллаһы Тәгаләнең боерыгы икәне әйтелеп, Мөхәммәт пәйгамбәрнең «сөннәте торур, Әбү Хәнифә Куфи вә Әбү Йосыф әл-Казый вә Мөхәммәд бине Хәсән Шәйбанинең иттифакы берлә... бу ултырган олуг вә кечекләрнең, җәмигъләрнең таныклыгы берлә ... мәһәр

берлә Хәсән кызы Фатыйманы Әхмәд угылы Мәхмүдкә алты йөз сум кябен хакы берлә хәләл вә җефетлеккә мөселманлык никахы үзрә сез кем вәкил булып бирдеңезме, ... кабул кыйлып алдыңызмы тиб өч мәртәбә сорагайлар» рәвешендәге никах тәртибе теркәлгән[22]. Әлеге текст язылган кульязма истәлек XVIII гасырның икенче яртысына нисбәтле булса да, никах тәртибенең тасвиры, тел үзенчәлекләренә (мәсәлән, *Изи, Тәңре, ярлык, танык* сүзләренә һ.б.) караганда, әүвәлгерәк чордан ук килгәнлеге аңлашыла.

Китапта барлыгы сигез аерылышу язмасы (хәлегънамә) һәм формуляры текстлары бирелде. Аларның иң элеккесе 1760 елга[23] карый (№17). Бу хәлегънамә формулярының тексты 1768 елгы бүтән кульязмадагы (№30) текст белән тулаем диярлек тәңгәл килүе ягыннан игътибарны җәлеп итә. Алардагы кайбер сүзләрдә генә аерма бар. Һәрхәлдә, әлеге ике текстның бер үк формуляр-калып икәнлеге шик уятмый. Бу исә татар телендәге хәлегънамә язуы үрнәгенең тагын да элеккерәк чорда гамәлгә кергән һәм таралыш алган булуына бер дәлил.

1768 елгы башка бер «хәлегъ язуы»н (№29) иске китаптан күчереп алган галимә Зәйнәп Максудова татар хәлегънамәләренә карата мондый искәрмә теркәгән: «1768 нче елларда әле муллаларга указ бирү, рәсми метрикә язулар йөкләтелмәгән. Гражданнар арасындагы хокук мәсьәләләрен шул авылларның муллалары шаһитлар белән бергәләп хәл кылганнар. Шул хөкем эшләренең карарларын, гакыйдләрен (акт) күбрәк кулда йөри торган китапның буш битләренә язып куя торган булганнар – З.М.»[24] Шушы кечкенә генә язмасын-

---

[22] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «95ф(18)» шифры белән саклана торган кульязма, 78а кәгазь. Шул ук китапның ахыргы битләрендә китапны бүләк итү һәм сатуалу язмалары да бар.

[23] Җ.Миңнуллин китабында тикшерелгән хәлегънамә формулярларының иң элеккесе 1787 елгы (Миннуллин З. Татарские частные акты..., 2020. – С. 54).

[24] Татарстан Республикасының Милли музеенда «ГОМРТ 13-9, №18369-554» шифры белән саклана торган дәфтәрдән.

да З.Максудова «гакыд» һәм «акт» сүзләренең тәңгәллеген дә белдергән.

Бу китапта бирелгән хәлегъномәләр үзләрендә төрлечә: *хәлегънамә, хәлегъ хаты*, *хатты хәлегъ, әрәм хаты* рәвешләрендә аталганнар. Хәлегъ язмаларында ир һәм хатын үз ихтыярлары белән ризалыкларын, бер-берсенә карата шәригать буенча һәм башка дәгъвалары калмавын белдергәннәр.

Ир кеше вәгъдә кылынган мәһәрне түләмәгән очракта ахун яки муллалар тарафыннан түләтү турында карар ителеп, махсус язып куелган хосусый актлар да булган. Мәсәлән, 1781 елгы шундый документта мулла һәм җирле хакимият вәкилләре бер иргә мәһәр хакын (өч ат: берсе колынлы бия; ике сыер) түләргә боерганнар. Ә 1819 елгы бер документта ир үз ихтыяры белән ахунга барып, мәһәрне түләячәген белдереп документ язган. Ул мәһәр хакына яши торган өйләрен бирергә вәгъдә иткән, шулай ук сыер, сарык, җилән һ.б. әйберләр алырга сүз биргән.

Никах һәм аерылу документларын элегрәк муллалар аерым теркәп барган булсалар, 1828 елдан Diния Нәзарәте тарафыннан мөселманнарга махсус метрика кагыйдәләре буенча мәхәлләдә ел саен язып бару гамәлгә кертелгән[25]. Рәсми метрика кысаларына сыешмаган очракларда аерым кәгазьләргә язу традициясе дә дәвам иткән. Мәсәлән, бу китапта урын алган 1840 елгы тәгаллекънамә язуында ир үзенең дүрт шарт белән никахлануын белдергән: 1) җәй һәм кыш фасылларында хатынын әти-әнисе янына берәр мәртәбә китерергә, 2) хатынына сукмаска-ормаска, җәфаламаска һәм әти-әнисен катыштырып сүкмәскә, 3) хатынның шәхси әйберен үз теләгеннән башка сатмаска, 4) өч көнлек җиргә киткәндә ризык белән тәэмин итәргә. Моңа охшаш текстлардан Алабуга өязе авылларының берсендәге 1848 елгы метрикада «ормак-сукмак булмам һәм икенче хатыным белән икесен дә бердәй гаделләмәк булдым – кунагын

[25] Метрика кагыйдәләрендә мәһәрнең күләмен (ничә сум икәнлеген) язу шарты булса да, кайбер муллалар «түшәк-ястык, яулык, комган, сандык» һ.б. бөтен нәрсәләрне күп еллар дәвамындагы метрикаларда түкми-чәчми теркәп барганнар.

да, ризыгын да, киемен дә, тынычлыгын да һәм берсенә чәй эчерсәм, икенчесенә дә эчермәк булдым, һәм сыерны икесенә дә бердәй саудырмак булдым» кебек шартларны да искә алыйк.

Миңнуллин үз китабында 1828 елгы карар белән Россия мөселманнарына метрика кенәгәләре язу кертелгәннән соңгы вакытка караган бер генә хәлегънамә формуляры да күрмәдек дип язган[26]. Ләкин безнең шушы китапта хәлегънамә формулярының 1898 елга караган тексты урын алды. Ул документның үзендә «әрәм хаты» (ягъни, «хәрәм язуы») дип аталган. Хәлегънамәнең ни өчен шундый исем белән аталган булуының аңлатмасы Җ.Миңнуллин хезмәтендә бар.

***

Хәлегънамә формулярларыннан 1692 елгы кулъязма җыентыкта теркәлгән берсен искә алу урынлы булыр. Археограф Альберт Фәтхи анда кеше исемнәре урынына җанвар исемнәре язылган булуына тукталган: «Аю угылы Бүре, Сусар йүҗүне Тиен». Шулай ук шаһитлары да җанвар исемнәре белән аталганын, «йүҗүн» сүзенең «кыз» мәгънәсен белдергәнен искәрткән[27].

Альберт Фәтхи мәкаләсендәге «йүҗүн» сүзенең мәгънәсенә тукталып, ачыклык кертергә тиешбез. Иске язмаларда еш кына «ч» урынына «җ» хәрефе язылганлыгы мәгълүм һәм бу сүз, чынлыкта, «йүчүн». Борынгы татар кабер ташларын өйрәнгән галим Гали Рәхим 1611 елгы эпиграфик истәлектәге «йүчүне» сүзе «кардәшенең кызы» яки «оныгы» дигән мәгънә белдергән дип (Касыйм ханлыгы чорындагы татар ташъязмаларын өйрәнгән башка галимнәрнең тикшеренүләренә нигезләнеп) язган[28]. Татар эпиграфикасы белгече Һарун Йосыпов, Г.Рәхим

---

[26] Миннуллин З. Татарские частные акты..., 2020. – С. 45.

[27] Фәтхи А. Мирас хатирәләре эзләп: Сергачка экспедиция // Социалистик Татарстан. – 1965. – 24 сент.; Шул ук // Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Тамга» нәшр., 2007. – Б. 48.

[28] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз.: Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 220–221.

фикеренә нигезләнеп, әлеге сүзне «оныгы» буларак кабул иткән[29].

Гали Рәхим тикшергән, хәзерге вакытта Әтнә районының Иске Өҗем авылы зиратындагы 1611 елгы кабер ташын без дә өйрәндек. Г.Рәхимнең «йүчүн» сүзе турындагы фикерләре һәм дәлилләре нигезле булса да, төрле гасырлардагы татар ташъязмаларында мәрхүмәнең исеме кемнеңдер кардәшенең кызы яисә оныгы буларак тәгаенләнмәгәненә күрә, күңелебездән ризалашып бетмәгән идек. Чөнки татарларда мәрхүмнең яки мәрхүмәнең исемнәрен әтиләренә нисбәт итеп, «фәлән улы» яки «фәлән кызы» дип язу гадәте урнашкан. Шунлыктан, без ул кабер ташындагы Үлмәс дигән хатын-кыз исемен «кыз туганы» яки «оныгы» дип тәгаенләүдән һәм «кызы» дип атаудан да тыелдык[30]. Чөнки ул вакытта дәлилләребез юк иде.

Соңгы елларда үзебез өйрәнгән, чагыштырмача борынгы чор татар шигъри истәлекләрендә һәм мөнәҗәтләрендә «йүчүне» сүзен күреп, аның татар җирлегендә тәгаен «кызы» мәгънәсендә кулланылган мисалларын очраттык. Мәсәлән, XVIII гасырга нисбәтле иске кулъязмаларның берсендә «Мөхәммәтнең йүчүне Фатыймадыр, аны хәзрәти Галигә рузи кыйлды» дип, пәйгамбәрнең кызы күздә тотылган[31]. Һәрхәлдә, Идел-Урал буйларындагы татар кулъязмаларында «йүчүн» сүзенең аермачык «кызы» мәгънәсендә кулланылганлыгы аңлашылды. Димәк, татар ташъязма истәлекләрендә дә шул ук мәгънәне белдергәнлегенә шик юк.

---

[29] Юсупов Г. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: «Наука», 1960. – Приложение: табл. 71. Замандашыбыз А.Гайнетдинов «йүчүн» сүзен шулай ук «оныгы» дип яза (Гайнетдинов А. Әтнә районы эпиграфик истәлекләре. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-ты, 2017. – Б. 84; Гайнетдинов А. Яшел Үзән районы эпиграфик истәлекләре. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих ин-ты, 2019. – Б. 86–87).

[30] Мәрданов Р., Һадиев И. Әтнә төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2018. – Б. 164.

[31] Казан дәүләт (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «2185т» шифры белән саклана торган кулъязма, 117а кәгазь.

Хосусый акт формулярларының күбесендә «фәлән фәлән улы» һәм «фәлән фәлән кызы» дип язылган булса, А.Фәтхи мәкаләсеннән күренгәнчә, әүвәл абстракт «фәлән» диясе урынга, җанвар исемнәре дә кулланылган икән. Бу, бер яктан караганда, татар халык әкиятләрендәге «кәҗә – команда, саескан – сотник, үрдәк – үрәтник» гыйбарәсен искә төшерә. Икенчедән исә, аларга аваздаш язмалар татар кешеләренең соңгырак чордагы текстларында да күренгәли. Мәсәлән, бабабыз Фатыйх Вәлиевнең (1893–1969) XX гасыр башындагы бер җыентыгында төрле килешү язмалары, документ язу калыплары бар. Анда 1914 һәм 1917 еллар белән даталанганнарында шартлы-уйдырма исемнәр теркәлгән. Мәсәлән, 1917 елның март аена караган бер формулярда поручительләр дип «Имән Тимеров, Урман Чытыров һәм авыл старостасы Алдай Алданов» рәвешендә язылган булуы кызыклы.

## Мирас бүлү турындагы язмалар

Васыятьнамә текстларының аерым өлешләре мирас бүлүгә багышланган. Алдарак солдат Насыйрҗанның мал-мөлкәтен бүлү васыяте турында әйтеп үттек.

Андыйлардан тыш, «тәхареҗнамә» дип аталган махсус язма документлар да булган. Бу китапта алар берничә. Берсе – Казан шәһәренең Яңа Бистәсендә Шәмсетдин Гомәр улының йорт-җир урынын варислары – ике ир һәм ике кыз балалары үзара бүлешүе турындагы 1864 елгы документ (№91). Әлеге язма, текстының әһәмияте белән бергә, Яңа Бистәдәге Иске Таш мәчетенең шул вакыттагы имамы Хөсәен Әмирхан улы тарафыннан кәгазьгә теркәлгән булуы һәм бу документның Каюм Насыйри кульъязмалары белән бергә саклануы ягыннан да кызыклы.

Мирас бүлешү турындагы 1870 елгы язма (№92) дүрт бертуганның үз әтиләре мөлкәтен килешеп бүлүләренә багышланган. Анда 11 кеше, шаһит булып катнашып, имзаларын куйганнар һәм тамгалар салганнар. Гомумән, бу документта барлыгы 14 кешенең исемнәре язылган, имзалары һәм тамгалары белән расланган.

Казан сәүдәгәрләре Исхак һәм Ибраһим Юнысовларның варисларыннан 1889 елда мал-мөлкәт бүлешүгә караган игъланнамә һәм вәкаләтнамә (№№99, 100) – «потомственный почётный гражданин» Мөхәммәтрәхим Исхак улы Юнысов исеменнән язылган булулары җәһәтеннән әһәмиятле документлар.

Татар кульязмалары арасында вафат булган кешедән соң калган мал-мөлкәтне бүлүгә багышланган тәфсилле исемлекләр һәм аларда һәр әйбернең бәясен күрсәтеп язылган вариантлар да бар. Андыйлардан 1847 елга караган берсе археограф галим Марсель Әхмәтҗанов китабында басылып чыкты[32].

## Башка төр язмалар

Китапта шулай ук баланы тәрбиягә бирү, хезмәткә яллану, гаһеднамә, солыхнамә, җир сату, китап сату, ат сату, игъланнамә һ.б. төр килешү-хокук язмалары бар.

1730 нчы еллардагы крепостной коллыктан азат итү турындагы язмалар һәм игъланнамәләр фәнни яктан, формаль караганда, ихтимал, хосусый актлар кысасына сыешып җитмидер. Шулай да, алар татар телендәге тарихи язмалар буларак әһәмиятле.

Алпавыт бәйлелегеннән азат итү турындагы документлар (№№1–4) – морза Котлыгмөхәммәт Тәфкилевнең (1674–1766) Тирсә волостендагы кол-крепостной крестьяннарын (өчесе хатын-кызлар һәм берсе ир-ат) азат итү турында. Алар һәммәсе дә «Котлыгмөхәммәт морзаның әмере берлән» иреккә җибәрелгәннәр. Әлеге документлардан күренгәнчә, ир-атның азат ителүе өчен 10 сум 50 тиен акча түләнгән (№2) булса, хатын-кыз өчен шуның яртысы – 5 сум 25 тиен (№1) түләнгән. 4 нче язмада исә хатын-кыз өчен 5 сум түләнгәнлеге теркәлгән. Чагыштыру өчен ул замандагы авыл хуҗалыгы әйберләренең

[32] Әхмәтҗанов М. Татар кульязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 109–112.

бәяләрен искә алсак, уртача зурлыктагы өй 1 сум 70 тиен, иске мунча – 25 тиен, яшь ат – 2 сум 30 тиен, сыер – 1 сум 50 тиен, сарык – 20 тиен, балта – 6 тиен булган.

1730 нчы еллардагы игъланнамәләр (№№5–14) Уфа өязендәге түрәләрнең башбаштаклыкларын, җирле халыкны талауларын тикшерүгә бәйле рәвештә архивта тупланып калган.

Нинди дә булса тикшерү-хөкем эшләрендә җавап тотучы яки шаһит тарафыннан Коръән белән ант итү сүзләре «гаһеднамә» (№37) дип аталган.

Үзара дәгъвалашкан кешеләрнең килешүләре турындагы «солыхнамә» калыпларының бу китапта 1794 елга караган өч варианты (№35) урын алды. Шулай ук 1829 елгы (№75) һәм 1871 елгы (№93) солыхнамә текстлары да бар. Соңгысы Шиһабетдин Мәрҗани кулы белән язылган нөсхә буларак аеруча әһәмиятле.

Ятимә кыз бала Бәдигыльҗамалны, туганнары булмаганлыктан, тәрбиягә бирү турындагы 1824 елгы язма (№45) сирәк очрый торган булуы ягыннан үзенчәлекле.

Хезмәтче булып яллану документларында (№№31,73, 76, 77) нинди эшкә икәнлеге, вакыты һәм бәясе күрсәтелеп, анык рәвештә язылган. 1833 елгы бер документта (№76) улын хезмәткә ялчы итеп бирүче буларак әнисе күрсәтелгән. Бу язмалар 1779, 1825 һәм 1833 елларга карыйлар. Шуны да искәртеп китик, Ж.Миңнуллин да үзе өйрәнгән хосусый актларның дүртесе хезмәткә яллануга багышланган булуын әйткән[33].

Яллану турындагы татар телендәге язмаларның текст төзелеше XVIII гасырда дәүләт оешмаларында русча теркәлгән шундый ук эчтәлектәге документларныкы кебек үк дияргә мөмкин. Рус телендәге архив документларыннан Каракулино конторасында теркәлгән бер төркем кешенең хезмәткә яллангынын белдергән берсен искә алыйк. Мәсәлән, 1708 елның июль аенда Пьяный Бор авылы крестьяннары Федот Иванов һәм иптәшләре (барлыгы 20 кеше) Баржы-Омга авылының

[33] Миннуллин З. Татарские частные акты..., 2020. – С. 106.

татары Туймәт Әзмәт улының йөк төялгән каегын[34] Чулман елгасы буйлап югарыга һәм аннан Агыйдел буенча Уфага хәтле алып барырга килешкәннәр. Хуҗаның кушканнарын төгәл үтәргә, аның милкенә кагылмаска, качып китмәскә сүз биргәннәр, башка шартларны һәм акча түләү мәсьәләсен анык-лап язганнар.

Китап сату-алуга багышланган язмалар бу җыентыкта берничә. Алар да хосусый актларга хас рәвештә: бәяләре, кемнән сатып алынуы һәм кем алганлыгы, шаһитлары языл-ган, имзалар куелган. 86–87 нче саннар белән билгеләнгән язмаларда нәсел тарихына караган мәгълүматлар күзаллана. Аларда кулъязма китапның 1841 елда 86 урыны ертылган бу-луы, ә 1861 елда ертыклары 95 икәнлеге искәртелгән. 88 нче санлы язмада шул ук китапның вәкыйф ителүе әйтелгән. Баш-ка бер язмада (№114) авыл мәчетенә Коръән китабы вәкыйф ителүе һәм вәкыйф итүченең шартлары белдерелгән. Китап са-ту-алу һәм вәкыйф итү язмаларын, гадәттә, китапның алдында-гы яисә ахыргы битләренә, төп тексттан буш калган урынна-рына теркәгәннәр.

Ат сату һәм алу турындагы килешү язмаларының иң әүвәлгесе 1781 елга карый (№89) һәм соңгысы 1900 ел белән даталанган (№109).

Китапта җир сату-алу һәм файдалануга бирү турындагы алты килешү язмасы тәкъдим ителде. Аларның иң элеккесе 1800 елгы, ә соңгысы 1915 елга карый. Бу төрдәге документлар җирле атамалар (кыр, болын һ.б.) кулланылып язылган. 1898 елгы документ (№104) Казан өязенең Ташсу авылы җәмәгате карамагындагы гомуми куллану җирен ике авылдашлары-на сатып бирү турында. Алар икесе дә танылган Максудилар

[34] Бу документтагы Барҗы-Омга – хәзерге Әгерҗе районындагы авыл, ә Пьяный Бор шул ук райондагы Красный Бор авылы. Каек дип ул заманда елгаларда йөрер өчен ясалган, йөк ташый торган зур судноларны атаганнар. Алар гадәттә, ишкәкле һәм җилкәнле булган. Озынлыгы 25 метрга җиткән һәм 25 потка кадәрге йөк алган. Су агымына каршы бурлаклар тарафыннан тартып менгерелә торган зур көймәләр дә «каек» исеме белән йөртелгән.

нәселеннән: берсе – педагог һәм журналист, җәмәгать эшлеклесе Әхмәтһади Максудиның бертуган энесе – Сәлахетдин Низаметдин улы. Икенчесе аларның этиләренең бертуган энесе Мөхәммәтҗан Гайнетдин улы.

Совет хакимлеге чорында – коточкыч ачлык вакытында – йорт сату турындагы килешү элекке хокук документлары үрнәгендә язылган. Чынлыкта, ул йорт инде таланып беткән булуы өстенә, бәясе дә шул заман афәтенә дәлил булып тора – «30 фунт арыш оны һәм 8 фунт тоз, 10 фунт алабута оны»!

Китапта хронологик яктан иң соңгы – 1923 елда – язылган «Могаһадә» (№120) үзенең тексты белән игътибарга лаек. Ул, беренчедән, электән килгән хосусый актларга охшаш булса, икенчедән, анда яңа заман үзенчәлекләре дә бар. Бу документ – 1921 елгы ачлык вакытында ятим калган ир бала белән аны тәрбиягә алган туганы арасында язылган килешү. Авыл советы шуны раслап мөһерен баскан, авыл советы рәисе белән секретаре имзаларын куйганнар. Әмма алар документта «башлык» һәм «язгы» дип теркәлгән, «авыл советы раслый» мәгънәсендә «авыл киңәше хаклый» гыйбарәсе кулланылган. Мондый сүзләр – яңа тормыш төзүнең башлангыч чорында татар телен сафландыру һәм камилләштерү омтылышының мисаллары.

Бу урында тагын бер фактны искә алырга кирәк. Милли китапханәнең 2006 елгы археографик экспедициясе табышлары турында Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәре Ильяс Мөстәкыймов Лениногорск районы газетасында мәкалә бастырган иде. Анда шул төбәктәге Туктар Урдалысы авылы кешесенең 1902 елда җир сату турындагы килешү тексты да бирелгән[35].

---

[35] Мөстәкыймов И. Халкыбыз тарихына караган яңа табышлар // Заман сулышы. – 2007. – 7, 11 апрель. Бу мәкалә археографик сериянең 30 нчы китабында да урын алды: Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2022. – Б. 155.

## Имзалар һәм тамгалар

Татар телендәге хокук-килешү язмаларында имза куючының исеме теркәлеп, «кулым куйдым» дигән сүзтезмәне язу гадәте булган. Шул ук вакытта, әүвәлдән үк килгән традиция буенча, имза урынына нәсел тамгасын салу киң кулланылган. Аны грамотасыз кешеләр генә түгел, кайчакта муллалар да куйганнар. Ә татар хатын-кызлары бер төрле үк – «хатыннар өчен махсус» киләпсыман[36] тамга салганнар.

Кулъязмаларда сирәгрәк булса да хатын-кызларның имза куйган очракларын да күрергә мөмкин. Мәсәлән, бу китаптагы 1824 елгы хосусый актта (№42) «әнкәсе Гайшә кулым куйдым» дигән, шулай ук 1871 елгы язмада (№93) «Хәбибҗамал Әхмәд кызы кулым куйдым» дигән һәм 1895 елгы васыятьнамәдә (№102) «Бибикамилә разый булып кулым куйдым» дигән юллар бар.

Китаптагы текстларда керәшен татарларының да нәсел тамгалары куелган мисаллар күренә. 1824 елга караган бер алыш-биреш язмасында (№68) керәшен татары Иван, тамгасын куюы белән бергә, хәтта гарәп хәрефләре белән «Ибан» дип тә имзалаган.

Килешү-хокук язмаларында, гадәттә, берничә шаһит катнашкан. Әмма кайберләрендә бер дистә чамасы, ә авыл җәмәгатенең караларында дистәләрчә кеше имзаларын куйган һәм тамгаларын салган.

Төп нөсхә документларда кешенең исеме теркәлеп, «тамгам салдым» диелсә дә, тамга куелмаган (ягъни, тамга рәсеме төшерелмичә калган) очраклар шактый.

Нәсел тамгалары фән әһелләренең дә, гомумән, тарих белән кызыксынучыларның да игътибарын аеруча җәлеп итә. Шунлыктан, бу китапта туплап бирелгән текстларда куелган

---

[36] *Киләп* –җеп чорный торган кәтүк кебек җайланма. Бу китапта 84 нче сан астында бирелгән хәлегънамәдә Җәмилә Атнагол кызы нәкъ шундый тамга куйган. Андый тамга, гадәттә, горизонталь куелган, ләкин аны төрлечә – авыш яисә вертикаль итеп тә ясаганнар.

146 тамга рәсемен (безнең тарафтан күчереп ясалган рәвештә) төп чыганаклардагы урыннарына тәңгәл итеп урнаштырдык.

Археография сериябезнең 23 нче китабында тамгалар мәсьәләсенә тукталып үткән идек. Анда «Чыңгызнамә» дастанындагы ыру тамгалары турында сүз барды һәм төрле текстларда бер үк кешенең тамгасы төрлечә булганлыгы әйтелде. Хәтта Чыңгыз ханның үз тамгасы ук җиде чыганакта алты төрле рәвештә булганлыгы искәртелеп, дастанның төп каһарманының тамгасы төрлечә булу факты башка тамгаларның ышанычсызлыгын белдерә диелде. Шулай ук тамгалардан ниндидер тирән мәгънәләр эзләү урынсыз дип язылды[37]. Заманалар үтү белән иҗтимагый үсешнең ыруглык чорыннан ераклашкан татарларда һәм башка халыкларда тамгаларның элекке хокукый мәгънәләрен югалткан булуы табигый.

***

Тамгалар тарихы борынгы дәверләрдән үк килә. Нәселыруларга бүленеш ир-атларга нисбәт ителеп, һәр ыруның, гаиләнең үз тамгасы булган. Төрки бабаларыбызда иң әүвәлге тамгалар V гасырда ук кулланылганы билгеле. Менә шул ерак чорлардан алып татарларда егерменче гасырга кадәр куелган тамгаларны галимнәр борынгы төрки рун алфавитына бәйле дип язалар. Ягъни, төрки рун язуына алмашка уйгур һәм гарәп әлифбалары кергәннән соң, элекке руник әлифба хәрефләре тамга-билге ролен үти башлаган, алар гасырлар дәвамында, нәсел тамгасы буларак, төрле үзгәрешләр кичергән, диләр. Ә кайбер белгечләр бөтен халыкларның да язулары тамгабилгеләрдән башланганын күздә тотып, алфавитлар үзләре тамгалардан барлыкка килгәндер дип фаразлый.

Нәсел тамгалары элек-электән шәхси һәм хосусый мөлкәтне билгеләү өчен кулланылган. Җир-биләмә чикләре, урмандагы чолык (умарта) урнашкан агачлар, мал-туар, сәүдә

[37] «Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2019. – Б. 79–81.

товарлары, эш кораллары һәм башка нәрсәләр үз хуҗаларының нәсел тамгасы белән билгеләнгән. Алда әйтелгәнчә, нәсел тамгалары имза урынына да куелган. Ягъни, нәсел тамгасы юридик көчкә ия булган дигән сүз.

Тамганың хокукый әһәмияте Алтын Урда дәүләте чорында аеруча рәсми төс алган һәм аннан соңгы дәвердә дәвам иткән[38]. Алтын Урда вакытында товар сатудан алынган салым (пошлина) «тамга» дип аталган. Ул эш өчен җаваплы махсус тамгачылар сәүдә товарларына билге-тамга салганнар. Тамга сүзеннән алынган «таможня» атамасы һәм салым хезмәте шул заманнардан килә.

Алтын Урда чорында нәсел тамгаларының милек хокукын белдерү хасияте рәсмиләшкән булуына ачык бер дәлил барлыгын искәртик – XVIII–XIX гасырлардагы язма документларда (хәтта XX гасыр башына кадәр) Россия империясенең төрле төбәкләрендә яшәгән мөселман татар хатын-кызлары бер үк төрле («киләп» рәвешендәге) тамга куйганнар. Мөселман-татар метрикаларындагы талак (аерылышу) турындагы язмаларда хатыннар «хатын-кызларга махсус киләп тамга салдым» дип, тамга сурәтен ясаганнар.

Иске текстларда аны «хатыннарга махсус киләп агач тамга» дип тә атаганнар. Бу китаптагы 84 нче санлы язмада «үз кагыйдәмезчә, хатыннар тамгам салдым» дигән сүзләр дә аның кагыйдә дәрәҗәсендә булганлыгын раслый.

Тарихчы Җәүдәт Миңнуллин хезмәтендә барлык хатын-кызларның бер төрле үк тамга куюы мәсьәләсе Казан ханлыгы чорында рәсмиләшкән булу ихтималы белдерелгән[39]. Ләкин, безнең уебызча, бу мәсьәлә әүвәлдәнрәк – Алтын Урда чорыннан ук килгәндер. Казан ханлыгы территориясеннән читтәге

[38] Элекке язма чыганакларга нигезләнеп болгар-татар тарихын язган Минһаҗетдин Җәбәли: «...Чыңгыз хан чыгып Болгарны, Мәскәүне басып алып, тамга салу гадәтен керткән», – дип искәрткән (Җәбәли Минһаҗетдин. Тәварихы Болгарийә вә татарийә. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2023. – Б. 94, 95, 136, 159).

[39] Миннуллин З. Татарские частные акты... 2020. – С. 82–83.

һәм хәттаерактагы төбәкләрдә дә хатын-кызлар тамгасының шундый ук булганлыгына бүтәнчә аңлатма табылмый.

Нәсел-ыру тамгаларының Алтын Урда заманында ныклап гамәлгә кертелгән булуын аларның Идел-Урал буендагы башка халыкларда, хәтта русларда да кулланылганлыгы дәлилли. Төрле халыкларда, шулай ук керәшен татарларында бер төрле үк нәсел тамгаларының булуы да гаҗәп түгел. Ләкин төрле халык вәкилләре кулланган тамгалар охшашлыгы – алар арасында һич тә кардәшлек һәм уртаклык бар дигәнне аңлатмый.

Иске кулъязмалардагы һәм архив документларында очраган тамгаларны өйрәнгәннән ачыклануынча, нәселнең төрле буыннарындагы тармаклары бер төрле үк яисә охшаш тамгалар кулланган. Ләкин бу даими һәм тотрыклы булмаган. Чөнки бер үк кеше дә төрлечә тамгалар куйган. Төп гаиләдән аерылып башка чыккан кешенең нәсел тамгасы әтисенекеннән аермалырак – өстәмә берәр сызык яки башкача элемент арттырылып, ә кайчакта киметелеп, бераз үзгәртелгән.

Татарларда укый-яза белмәүчеләр әле 1930–1940 нчы еллардагы төрле документларда имза урынына тамга куйганнар. Бу күренеш, сирәк булса да, 1960 нчы елларга хәтле дәвам иткән. Нәсел тамгалары сугылган эш кораллары (балта, көрәк, сәнәк һ.б.) әле 1980 нче еллар башында да күренгәли иде.

## Документлар кайсы төбәкләрнеке?

Килешү һәм хокук язмалары үзләрендә теркәлгән географик атамалар җәһәтеннән дә, археографлар тарафыннан табылган урыннары ягыннан да татар дөньясының шактый киң даирәсенә нисбәтле. Документларда Казан шәһәре, хәзерге Татарстанның Азнакай, Актаныш, Апас, Арча, Әгерҗе, Әтнә, Балтач, Биектау, Буа, Саба, Теләче, Тукай, Кукмара, Мамадыш, Тәтеш, Чистай, Ютазы районнарындагы, Чувашстанның Батыр районындагы, Мари Республикасының Бәрәңге районындагы, Оренбург өлкәсенең Абдуллин һәм Северный районнарындагы, Самара өлкәсенең Камышлы районындагы һ.б. төбәкләрдәге авылларның исемнәре атал-

ган. Кульъязма истәлекләрнең табылган урыннары – югарыда әйтелгән төбәкләрдән тыш, Татарстанның Сарман районына, Чувашстанның Козловка районына, Свердловск өлкәсенең Красноуфим районына кергән татар авыллары, Уфа шәһәре һәм Удмуртиянең башкаласы Ижевск.

Китапта тупланган текстларда күрсәтелгән төбәкләр кульъязмаларның табылган урыннарына һәр очракта да тәңгәл килми. Хәтта Казан артында табылган кульъязма чыганак шактый ерак бер төбәкнеке булган очраклар да бар. Мәсәлән, Пермь ягына бәйле язма Кукмара районыннан, ә Башкортстан территориясенә караган язмалар Арча районында табылган. Мондый хәл, беренче карашка, бик гаҗәп кебек тоелса да, татар кульъязмаларының халкыбыз яшәгән бер төбәктән икенчесенә күчкән мисаллары бик күп һәм археография тарихында билгеле күренеш. Аларның һәркайсының үз сәбәпләре булган. Әйтик,ерактан килеп мәдрәсәдә уку яисә башка төбәккә мулла итеп билгеләнү, кардәшлек, сату-алу һ.б. бәйле рәвештә кульъязма китаплар кулдан-кулга күчкән һәм ил гизгән.

Бу китаптагы текстларда барлыгы 150-дән артык географик атама булуын да искәртик. Аларның тулы исемлеге китап ахырында җыеп бирелде.

## Язмаларның теле, кайбер палеографик һәм текстологик үзенчәлекләре

Татар хосусый актларының теле, документның төренә карап, төрлечә рәвештә. Мәсәлән, никах һәм аерылышу, васыятьнамә кебек, шәригать тәгълиматына нигезләнгән хокукый язмаларда дини китаплардагы гыйбарәләр, гарәп телендәге җөмләләр һәм сүзләр аеруча күп кулланылган. Ә сату-алу, мирас бүлү һ.б. документларның текстлары татар теленең үз чорындагы гади сөйләм телендә диярлек. Андыйлар хәзерге татар кешесе өчен дә җиңел аңлаешлы.

Кайбер текстлардагы берничә сүздә борынгы палеографик үзенчәлек сакланган булуын искәртергә кирәк. Мәсәлән, «илүе», «тигрүә», ошбуа». Бу сүзләр, чынлыкта, «илүү» (ягъ-

ни «иле»), «тигрүү» (тигре), ошбуу (ошбу) буларак укылырга тиешле. Әлеге сүзләрнең яңгырашларында ахыргы авазлары, борынгы төрки телгә хас булганча, озын авазлар булган. Әлеге үзенчәлек борынгы чорда гарәп графикасында озын аваз «әлиф» һәм «йа» хәрефләре ярдәмендә белдерелгән.

Китапта бирелгән документларның төп чыганаклары барысы да Россиядә эшләнгән гади кәгазьләргә язылганнар. Фәкать берсе – 1864 елгы тәхарежнамә (№91) герблы кәгазьгә теркәлгән. Текстларның күбесе ашыгыч язылган булуы сәбәпле, аларда орфографик хаталар бар, кайбер хәрефләре, сүзләре һәм кушымчалары төшеп калган. Чыганакларның саклаunion дәрәҗәләре һәм язулары турындагы мәгълүмат һәрберсенә карата аерым искәрмәләрдә язылды.

Язма документларның электән үк «тарих мең дә йите йөз дә утыз алтыда ирде», «тарих мең дә йите йөз дә алтмыш түртенче елда ирде» рәвешендәге башламнары тора-бара үзгәрсә дә, хосусый актларда, нигездә, иң алдан ук даталары язылган. «Тарих мең дә... ирде» дигән дата калыплары башка татар язма чыганакларында – XIV–XVIII гасырлардагы кабер ташларында, шулай ук XVI гасырдан хәзерге вакыткача килеп ирешкән сирәк архив документларында да кулланылган[40].

«Тарих» сүзеннән башланган традицион язылыш 1820 нче еллардагы хосусый актларда да теркәлгән. Мәсәлән, «тарих мең дә сигез йөз дә егерме икенче елда», «тарих мең дә сигез йөз дә егерме бишенче елда» кебек язмалар бар.

Текстлардагы даталарның барысы да диярлек милади ел

---

[40] Мәсәлән, хәзерге Теләче районының борынгы зиратларында һәм каберлекләрендә сакланган, 1399, 1443, 1472, 1527, 1531, 1532, 1542, 1544, 1547, 1551, 1677 һәм 1685 елларга нисбәтле кабер ташларының текстларындагы язылышлар (Һадиев И., Мәрданов Р. Теләче төбәгенең борынгы ташъязма истәлекләре // Безнең мирас. – 2022. – №12. – Б. 10–12, 14–19) һәм 1569 (1570) елга караган бер архив документындагы «бителде тарих тукуз йөз йитмеш йитедә ирдекем» дигән юллар шуңа дәлил (Биккинин И. Мордовиядә татар утравы: ләмберә һәм түбән татарлары, эрзәләр // Безнең мирас. – 2022. – №6. – Б. 5).

исәбе белән бирелгән. Бары тик 1902 һәм 1920 елларга караган ике документта (№№110, 118) һиҗри һәм милади еллар параллель рәвештә күрсәтелгән.

Милади еллар элеккерәк документларда (1736–1768, 1800, 1822–1825 елларда[41]), нигездә, сүзләр белән язылган. Ел саннарының сүзләр белән язылган иң соңгы очрагы – бу китаптагы документлар арасында, түгәрәкләп әйткәндә, бер гасырдан соң – «бер мең дә тукыз йөз екерменче елда» рәвешендә (№119) кулланылганлыгы күренә. Ә 1779–1781, 1794, 1815 һәм аннан соңгы елларга караган язмаларда еллар, нигездә, саннар белән белдерелгән.

Текстларда еллар күрсәтелеп тә, төгәл көне һәм ае язылмаганнары шактый.

XVIII гасырдагы килешү язмаларының кайберләре (№№29, 35) «бителде» дигән сүз белән башланган. «Язылды» мәгънәсендәге борынгы «бителде» сүзе әүвәлдән үк килгән һәм ул да тора-бара кулланылышта сирәгәеп, төшеп калган[42]. Шулай да бу гыйбарә XIX гасырның икенче яртысындагы документта да очрый – Габделгали Бәйрәкәви васыятьнамәсе (№107) «Бу әүвәл васыятьнамәдер кем, бителде...» дип башланган.

Хосусый актларның аерым төрләрендә үзенчәлекле гыйбарәләр кулланылган. Мәсәлән, килешүләрдә мондый калып очрый: «хаҗәт йирендә хөҗҗәт көнендә сүзем ялган, дәгъвам батыйль булсын өчен ошбу язуны яздырып бирдем»

---

[41] Бу китапта 1–30 нчы саннар белән билгеләнгән, 1736–1768 елларга нисбәтле документлар барысы да милади ел исәбе белән язылганнар. Бу исә Җ.Миңнуллинның, татар хосусый актлары XVIII гасыр уртасына кадәр, нигездә, һиҗри ел исәбе белән даталанып, аннан соң христиан календаре буенча язылган һәм бу патшабикә Екатерина II-нең империядәге мөселманнарга карата йомшаграк мөнәсәбәтенә бәйле, дигән нәтиҗәсенә (Миннуллин З. Татарские частные акты... 2020. – С. 57) туры килми.

[42] Җәүдәт Миңнуллин, үз күзәтүләре нигезендә, бу сүзнең XVIII гасырның икенче яртысында һәм XIX гасырның беренче яртысында бик сирәк кулланылганын искәрткән (Миннуллин З. Татарские частные акты... 2020. – С. 59).

(№№17, 29, 30), «соңгы көн аслан сүз-өн итмәз өчен бу солыхны икенче имамлара дәфегъ кыйлмаз өчен, хаҗәт вакытында хөҗҗәт улсын өчен вә һәм хакимнәр хозурында телем киселеп сүзем йөрмәсен өчен...» (№35). «Хаҗәт җирендә (вакытында) хөҗҗәт» дигәндә – язылган килешүнең юридик көчкә ия, тулы хокуклы документ булуы күздә тотылган.

Хокук-килешү язмаларында шаһит буларак катнашкан кешеләр элегрәк (1736 елгы язмада) «танык» дип аталган булса, аннан соң шул ук мәгънәдәге «гүаһ» дигән фарсы сүзе белән белдерелгәннәр. Җ.Миңнуллин, үз күзәтүләренә нигезләнеп, «гүаһ» термины 1770 нче елларда кулланыла башлаган дип белдергән[43]. Бу китапта урын алган документларның 1760–1768 елларга караган унөчендә «гүаһ» сүзенең шактый киң кулланылган булуы күренә. Алардан элеккерәк татар хосусый актлары ачыкланып, тәфсиллерәк тикшерелгән очракта, бу терминга бәйле мәсьәлә тагын да ачыклана төшәр.

«Гүаһ» сүзенең киң кулланылыш алуы, ихтимал, татарларның Урта Азия мәдрәсәләрендә белем алуының күбәя баруы йогынтысы белән бәйле булгандыр дип фаразларга мөмкин. Билгеле булганча, империянең үз максатлары белән XVIII гасырның беренче яртысында Оренбург тирәсенә шактый татарлар күчереп урнаштырылган һәм Урта Азия мәмләкәтләре белән аралашу көчәйгән. Ә Төркестанда һәм Урта Азиядә, билгеле булганча, фарсы теле өстенлек иткән.

Китапта тупланган документларда «гүаһ» термины соңгы мәртәбә 1898 елгы язмада (№105) кулланылган. «Шаһит» сүзе исә бу китаптагы текстларда иң беренче тапкыр XVIII гасыр ахырына нисбәтле васыятьнамәдә (№36) бар. Аннан соң 1829 елгы солыхнамәдән (№75) алып XX гасыр башына кадәрге документларда шактый язылганын күрәбез.

Килешү-хокук документларында «көн элгәре» дигән сүзтезмә дә очрый. Бу гыйбарә хәзерге татар теленең кайбер сөйләшләрендә «бер көн алдан» дигән мәгънәгә ия булса да,

[43] Миннуллин З. Татарские частные акты... 2020. – С. 105.

элекке язма текстларда ул «моннан соң» дигән мәгънәдә кулланылган.

Документлардагы кайбер гыйбарәләрнең тискәре төзелешле сүзтезмәләр рәвешендә булганлыгы да игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, «сорамак булмадым», «мәхкәмә урыннарына барышып йөрешмәкче булмадык», «сүкмәк булмадым», «куеп китмәгә булмадым» дип раслаулар һәм вәгъдә сүзләре хәзерге тел кагыйдәләре таләбенчә «сорамаска булдым», «...йөрешмәскә булдык», «сүкмәскә булдым», «куеп китмәскә булдым» дигәнне белдерәләр.

Язмалардагы кайбер башка үзенчәлекләр (мәсәлән, «йөкче» һәм бурычка алган акчаны түләү вакыты-вәгъдәсе) турында алдарак язып үткән идек.

Җ.Миңнуллин үзе өйрәнгән вакыт чикләрендәге 17 алыш-биреш язмасының бары тик икесендә генә «йөкче»ләр язылганлыгының сәбәбен моның әһәмияте зур булмауга бәйләгән[44]. Ләкин безнең бу китапта тупланган документларда тарихчы галим тикшергән чорга (XIX гасыр уртасына кадәр) караган «йөкче» гыйбарәсе шактый кулланылганлыгы күренә. 1760 нчы еллардагы язмаларда «йөкче»ләр шактый, шулай ук 1824–1825 еллардагы күп документларда да алар язылган. Ә инде 1825 елдан соңгы язмаларда «йөкче» термины бөтенләй очрамый.

Кайбер алыш-биреш язмаларындагы «түли алмасам, саттым бурамны», «саттым атымны» кебек гыйбарәләр бурычны түли алмаган очракта, саткан булып исәпләнергә тиешлекне күздә тоткан.

Әүвәлге килешү һәм хокук язмаларында рус сүзләре дә шактый кулланылган. Кайбер язмаларда алар аеруча күп. Мәсәлән, XVIII гасыр уртасындагы бер түрә язмасын (№16) күздән кичергәндә, аның хәзерге чордагы кайбер татар җитәкчеләренең телевидениегә биргән интервьюларына охшашлыгы ачык тоемлана. Патша заманындагы татар түрәсенең

[44] Миннуллин З. Татарские частные акты... 2020. – С. 104.

бер җөмләсендәге рус сүзләренең саны-исәбе татар сүзләре кадәр үк дияргә мөмкин.

Тупланган текстларда ономастика тарихы өчен дә мәгълүматлар шактый. Мәсәлән, XVIII гасыр документларында теркәлгән татар кеше исемнәре бик күптөрле һәм аларның сирәк очрый торганнары да бар. Мәсәлән, Аккөбәк, Әбдәсем, Бигәнәй, Биктүеш, Дүскә, Игәч, Илек, Ирмәш, Исәммәт, Минкә, Сабай, Сабанай, Карай, Кәләй, Киекбай, Килкә, Кормый, Кормыш, Кунаккуҗа, Ракәй, Тайгын, Талмай, Тимкә, Токымәт, Төткәй, Тукбай, Туксан, Урмач, Чура, Шакмамай, Шәммәт, Ырысай, Ямансарый.

Гомумән, татар кулъязма чыганакларындагы лингвистик үзенчәлекләр фәнебездә шактый өйрәнелгән булса да, электә татар текстларында кызыклы мәгълүматлар табылырга мөмкин әле.

## Китапның төзелеше

Бу китапта тупланган килешү-хокук документлары хронологик нигездә – иң искеләреннән башлап, соңгырак чорга таба килү тәртибендә урнаштырылды. Шул сәбәпле, төрле темадагы хосусый актлар аралаш бирелде. Һәр документ аерым сан белән билгеләнеп, иң алда нәрсә икәнлеге һәм елы (яисә якынча вакыты) күрсәтелде. Бер үк чыганактан алынган һәм тематикасы уртак булганнары, даталарына күрә (аерым саннар белән билгеләнсәләр дә), гомуми исем-атама астындагы туплам рәвешендә урнаштырылды. Берничә варианттан торган язмалар бер номер астында урнаштырылып, «а, б, в» хәрефләре белән билгеләнде. Андыйлар китапта икәү (№№35, 103).

Кереш мәкаләнең ахырында хокук язмаларының тематик исемлеге тәкъдим ителде һәм, шул темаларга бәйләп документларның китаптагы шартлы номерлары туплап күрсәтелде.

Һәр документның яки берничә документтан торган текстлар тупламының ахырларында кулъязма чыганакның кыскача

тасвирламасы һәм текстка карата кайбер искәрмә-аңлатмалар язылды. Тасвирларда һәр документның гарәп язуының теге яки бу төрендә теркәлгәнлеге турындагы мәгълүматлар аермачык каллиграфик хасиятне белдерми. Аларның берникадәр өлеше нинди язу төренә якын булуларын исәпкә алып, якынча һәм шартлы рәвештә нисбәт ителде.

Хокук-килешү язмасы төп чыганакның кайсы кәгазендә булганлыгы ике кыек сызык белән аерып (*//2а кәгазь*) күрсәтелде, кайберләре искәрмәләрдә белдерелде.

Документларның төп кулъязмаларында төшеп калган хәрефләр, иҗекләр, шулай ук кайбер танылып җитмәгән яисә төшеп калган дип фаразланган сүзләр квадрат җәяләр эчендә өстәп бирелде. Сакланышлары начар булган кулъязма чыганакларның кәгазьләре дефектлы булулары сәбәпле, танылмаган сүзләр урынына күпнокталар куелды һәм өлешчә укылган сүзләр һәм кеше исемнәренең тәгаен ышанычлы булмаганнары янәшәсендәге җәяләр эчендә сорау билгесе белән бирелде.

Иске кулъязма чыганакларда бер үк сүзләрнең төрлечә язылышлары (мәсәлән, *бән–мән–мин, дүрт–дүрд–түрт–түрүт, йир–җир, йәй–җәй, Җәнәй–Янәй, өю–эү* һ.б.) үзгәртелмичә сакланды. Шулай ук *агыр, алмаклыг, анлар, әйткүче, берлән, биләгүче, дәгел, дәю, дөшереп, егач, илән, ирде, иткүче, йомыртка, озынлыг, саг, сач, сән, сыгыр, тагъ, торгучы, улгучы, үгрәт* кебек архаик сүзләр төп текстлардагыча бирелде. *Авыст, агуст, април, вирдем, дикәбер, җак, җарый, йитмәз, купис, кыйлмаз, нуябер, синтәбер, тәнкә, улмаз, үктәбер, фибрал, ырастлык, ырасхут, ырыксәт, ыстарыста, эрәвешчә, юкары* һ.б. шундый язылышлар үзгәртелмәде. Кайбер текстларда *б/п* күчешләре очрый. Мәсәлән, выбыт/быбыт, бура/пура.

Кайбер сүзләрдә «уау» хәрефе белән белдерелгән «ы» һәм «е» авазлары, шулай ук «йа, йә», «йу, йү», «йы, йе» язылышлары бу басмада «я, ю, е» дип, хәзерге орфографиягә яраклаштырып бирелде. «Аннан» «миннән» кебек сүзләрдәге

элеккечә кушымчалар (андан, миндән) хәзерге орфографиядә тәкъдим ителде. Ә документлардагы хәзерге татар теле орфографиясеннән аермалы кушымчаларның бер өлеше текстларда сакланды. Мәсәлән, *абзыйгә, ашлыкга, әткәмгә, Габдуллагә, догагез, карчыгымга, квартирдә, расльыкына, сатканлек, угланнарынын, угылыга* һ.б.

Текстлардагы барлык тыныш билгеләре дә безнең тарафтан куелды.

Китапның ахырында сүзлек һәм географик күрсәткеч тәкъдим ителде. Географик атамаларның кайсы текстта булуларына ишарә итеп, китаптагы документларның саннары язылды.

***

Китапны басмага әзерләгәндә биргән киңәшләре һәм күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директор урынбасары Ирек Һадиевка, китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллинга, Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге мөдире Энже Сабировага, милли тарихчыларыбыз Рәмзия Абзалинага һәм Эльмира Сәлаховага ихлас рәхмәтләремне белдерәм.

# КИТАПТА ТУПЛАНГАН ЯЗМАЛАР

1) алыш-биреш, сату-алу – №№18–28, 41–44, 46–49, 51–71, 74, 79–80
2) ат сату – №№33, 50, 89, 106
3) баланы тәрбиягә бирү – №45
4) васыятьнамә – №№36, 83, 98, 102, 107, 108, 116–118
5) вәкаләтнамә (тәүкилнамә) – №№ 39, 82, 100, 110, 111
6) вәкыфнамә – №88, 114
7) гаһеднамә – №37
8) җир сату һәм файдалануга бирү – №№38, 97, 101, 104, 113, 115
9) игъланнамә – №№5–14, 99
10) инабәт язуы – №103
11) йорт сату – №119
12) китап сату-алу – №№81, 86–88, 90, 94, 95
13) крепостнойлыктан азат итү язмалары – №№1–4
14) мәһәр түләтү – №34
15) мирас бүлү (тәхарежнамә) – №91, 92
16) милек васыяте – №96
17) могаһадә – №120
18) мохәйяр язуы – №40
19) өй салу турындагы килешү – №72
20) паспорт сорау язмалары – №№15, 16
21) солыхнамә – №№35, 75, 93
22) тәгаллекъ язуы – №85
23) хәлегънамә – №№17, 29, 30, 32, 39, 84, 105, 109
24) хезмәткә яллану – №№31, 73, 76, 77
25) шартнамә – №112

## 1–4. Крепостной коллыктан азат итү язмалары. 1736–1739 еллар.

1

Тарих мең дә йите йөз дә утыз алтыда ирде, Котлыгмөхәммәд морзаның крәстияне Исәммәт кызы Көбраны ирек кылдым. Котлыгмөхәммәд морзаның әмере берлән бирелгән икән Өфе өязенең Байлар илүенең Иске Байларның Заид Бакый угылына.

Биш сум егерме биш тиен выбыт акчасын алдым, утпусен бирдем.

Ырыс авылының Сабанай Бидәй угылы бу эшкә кулым куйдым.

Вә янә шул ук авылның Хаҗи Уразай угылы бу эшкә танык булдым.

Бурмис Рахманкол угылы кулым куйдым.

2

Тарих мең дә йите йөз дә утыз сигезенче елында ирде, алдым мин бурмис Рахманкол, Котлыгмөхәммәд морзаның әмере берлән, Казан өязенең Бакый сутнәсенең Әгерҗе авылының Ишәйдән ун сум илле тиен выбыт акчасы.

Бу көннән соң һичкем сүзен әйтмәсен дип, мин – фисер Максуд ошбу утпускыны яздым вә һәм кулым куйдым.

Мин Рахманкол кулым куйдым.

3

Тарих мең дә йите йөз дә утыз тукызынчы елында ирде, Котлыгмөхәммәд морзаның әмере берлән утпис бирдем Игәч кызы Борна өчен Ямәмәт Килкә угылына. Бу көннән соң һичкем сүзен әйтмәсен.

Выпут өчен йибәрдем иркенлеккә китеп.

Выбор Максуд [яздым] вә һәм кулым куйдым.

Прикәшкә Мәүлекәй Сәмән угылы кулым куйдым.

4

Мин – бурмис, Котлыгмөхәммәд морзаның әмере берлән, булус Тирсә Балтач авылының Исәммәт кызы Гөлназның биш сум быбут акчасын алдым Тәкермәннең Токымәт угылы Дауддин.

Бу утпискә мин – Рахман кулым куйдым.

Өфе өязенең Казан юлының Байлар илүенең Тәкермән авылының Туктагол камандасының мин – Дауд Тукмәт угылы тамгам салдым

***

Әлеге язмаларны Россия дәүләт борынгы актлар архивындагы (Мәскәү) 248 фонд, 5 тасвир, 263 саклану берәмлегенең 44 нче кәгазеннән 2004 елда күчереп алган идек.

Текстлардагы «бурмис» сүзе «бургомистр» дигәннән үзгәртелгән һәм ул коллар биләүче алпавытның идарә эшләрен алып барган җаваплы хезмәткәр дигәнне белдергән. «Бургомистр» дигән вазифа Россия империясендә нәкъ шул мәгънәдә дә кулланылган. 3 нче язмадагы «прикәшкә» – ягъни, «приказчик» атамасы – да шул ук мәгънәгә ия булган.

3 нче текстлагы «иркенлекә китеп» гыйбарәсе «бәйлелектән азат булып» мәгънәсендә. Шунда ук язылган Мәүлекәйнең әтисе исеме, ихтимал, Сәймән булгандыр. Рус телендәге архив документларында ул кеше Семенов дип кенә язылган, кайбер татарча документларда «Симун угылы» дип тә кул куйган.

Язмалардагы Ырыс авылы – Хәзерге Татарстан Республикасының Әгерҗе районы территориясендә булган, хәзерге вакытка беткән Рыс авылы; Тирсә һәм Балтач – шул ук районда; Әгерҗе – хәзерге Әгерҗе шәһәре; Иске Байлар һәм Тәкермән – Тукай һәм Минзәлә районнарындагы авыллар.

## 5–14. Игъланнамәләр. 1737–1739 еллар.

5

// (*543б кәгазь*) ... Йите йөз дә утыз йитенче елда Өфе өязенең Казан юлының Янәй илүенең Кадыбаш авылының

сутник Үрәзмәт Йосыф угылы, юлдашлары берлә, йите өюле кешедән ыстарыста Ирмәш Урмач угылы, сутник Мәчтәй Әбзәй угылы, Иштүк Иткенә угылы алдылар иллешәр тиен акчамызны.

Ошбу юкарыда язылган акчаны ант буенча мин – сутник Үрәзмәт Йосыф угылы тамга салдым

6

... Янә шул ук елда шул ук илүнең Песләк авылындин унйите өюле кешедин ыстарыста Ирмәш, сутник Мәчтәй, янә Иштүк алдылар иллешәр тиен акчамызны.

Ошбу юкары язылган сигез сум илле тиен акчаны ант буенча Әбдәсем яздырдым, үз кулым [белән] тамгам салдым

7

... Шул ук тарихта шул илүнең Үтәгән авылындин, янә шул ук [елда] ...[1] авылындин [12] сум алты эүдин юкары язылган Ирмәш, янә сутник Мәчтәй Әбзәй угылы, Иштүк ике авылдин алдылар иллешәр тиен акчамызны. Буш йирдә куркытыб.

Ошбу юкары яз[ылган] ике авылдин унике өюле кешедин алты сум акчаны яздырдык ант буенча Үтәгән авылының Балтай Сабай угылы, тамгам салдым

Шул ук авылның Бигәнәй Туеш угылы тамгам салдым

8

... Шул ук тарихта шул ук илүнең Куян авылының Әбзәй Әблә угылындин, юлдашларым берлә, сигез өюле кешедән алдылар ыстарыста Ирмәш Урмач угылы, сутник Мәчтәй Әбзәй угылы, Иштүк Иткенә угылы иллешәр тиен акчамызны.

Ошбу юкары язылган акчаның алганлыкларыраслыклары өчен ант буенча Әбзәй Әблә угылы тамга салдым

[1] Төп чыганакта авылның исеме язылмаган.

9

... Шул ук ел Исәнбай авылының выбор Ишәй Сәймәк угылы, үземнең юлдашларым белән, өч өюле кешедән ыстарыста Ирмәш Урмач угылы, янә сутник Мәчтәй Әбзәй угылы, Иштүк Иткенә угылы алдылар, буш йирдә, иллешәр тиен акчамызны.

Ошбу юкарыда язылган өч өюдән илле тиен акчаны выбор Ишәй Сәймәк угылы ант буенча яздырдым, тамгам салдым

10

Узган йите йөз дә утыз сигезенче елда Өфе өязенең Казан юлының Җәнәй илүенең Куян авылының Әбзәй Әблә угылындин кансәләрис Ибан Әләкчәйч куркытып алды унбиш сум акчамны.

Юкары язылган унбиш сум акчаны ант итеп рас иттем – Әбзәй Әблә угылы, тамгам салдым

11

... Мең дә йите йөз дә утыз йитенче елларда, утыз сигезенче елларда, утыз тукызынчы елларда йәнаралдин килде урыс. Әүвәл Нарат авылының, Куян авылы, Шулык авылы – өч авылдин биш тәкә, дүрт каз, тукыз үрдәк, кырык ике тавык, түрүт йөз алтмыш биш йомыртка, вә янә пот та ун грүнкә җон, ике чирек читләвек, бер пот мәк, утынны булса һәм печәне, чыралык булса – барчасыны бирдек.

Ошбу юкары язылган нәрсәләрне ант итеп, рас иттем – Нарат авылы Шакмамай Исмәгыйль угылы, тамгам салдым

Куян авылының Әбзәй Әбләй угылы тамгам салдым

Вә янә шул ук авылның Хөсәен Бигәнәй угылы тамгам салдым

12

...Мең дә йите йөз дә утыз тукызынчы елда Үтәгән авылының Тукбай Бикмәт угылыннан правшик Шәфи куркытып алды бер кара ат, бәһасе – алты сум.

Тукбай Бикмәт угылы ант итеп, рас итеп тамгам салдым

13

// *(542б кәгазь)* ... Мең дә йите йөз дә утыз тукызынчы елда Өфе өязенең Казан юлы Янәй илүе Көчек авылының Арслан Илек угылындин алды Шәфи бер бүз юрга, бәһасе – унбиш сум.

Ошбу юрганы ант буенча яздырдым Арслан Илек угылы, тамгам салдым ꭓ

14

// (*679б кәгазь*) ... Әгерҗе авылының Бикәй антым буенча мәгълүм кыламын: алды Шәфи йөз сум акчамны.

***

Бу игъланнамәләрне Россия дәүләт борынгы актлар архивындагы (Мәскәү) 248 фонд, 5 тасвир, 251 саклану берәмлегеннән 2005 елда күчереп алган идек.

Текстларда телгә алынган Кадыбаш, Песләк, Үтәгән, Исәнбай, Нарат, Куян, Шулык – хәзерге Татарстан Республикасының Әгерҗе районындагы татар авыллары. Песләк дигәне – хәзерге Иске Эсләк, ә Куян һәм Шулык – Девятернә авылының элекке чорда атап йөртелгән аерым өлешләре, Әгерҗе авылы – хәзерге Әгерҗе шәһәре.

10 нчы язмада «кансәләрис Ибан Әләкчәйч» – канцелярист Иван Алексеевич.

11 нче язмадагы «йәнарал» дигәндә генерал Леонтий Яковлевич Соймонов күздә тотылган. Ул 1737 елның гыйнварында татар-башкорт восстаниеләрен тикшерү комиссиясенең җитәкчесе итеп билгеләнгән һәм аңа халыкның күтәрелешен бастыру йөкләнгән. Комиссиянең штаб-квартирасы Минзәләдә урнашкан. 1737 елның май аенда Соймонов шунда килгән. Ул 1737–1739 елларда Уфа воеводасы Шемяканың ришвәт алу эшләрен һәм авылларны талап, бөлгенлеккә төшереп бетерүен дә тикшергән. Генерал Соймонов үзе дә халыкны шактый талаган. Аның һәм башка җирле түрәләрнең азгынлыклары Уфа вице-губернаторы Пётр Аксаков җитәкчелегендә 1740 нчы

елларда тикшерелгән. Типтәр катлавына кергән татар авылларына кагылышлы, монда тәкъдим ителгән мәгълүматлар нәкъ шул тикшерү белән бәйле булган.

Шул ук 11 нче язмадагы «йәнаралдин килде урыс» дигәндә Соймонов тарафыннан җибәрелгән рус гаскәриләренең авылларны талап китүләре күздә тотылган. Гомумән, югарыда китерелгән язмаларга бәйле, хәзерге Әгерҗе төбәгенә кергән, патша чорында типтәр катлавына нисбәтле булган татар һәм берничә чирмеш авылларының старшинасы Нияз Ибраһим улы карамагында барлыгы 317 хуҗалык булган. Шулардан 1737–1739 елларда акча, терлек-туар (ат, сыер, сарык), чал төлке тиресе, кош-корт (каз, үрдәк, тавык), печән, утын, чыралык агач, йөк-йөк солы, киндер сүсе, чикләвек, сатучылардан тукымалар һәм бүтән товарларын көчләп тартып алганнар. Әлеге архив эшендәге старшина Нияз Ибраһим улы язмасындагы «әүвәл урыс чыкарып йыйдырды Соймонов йәнарал хәляикътан сикез батман чикләвек: алты батман Соймонов йәнаралга, ике батманны Шәфигә» кебек җөмләләреннән дә рус хәрбиләренең мал-мөлкәтне кабат-кабат, мәҗбүриләп җыйганлыгы аңлашыла.

12 нче язмадагы «правшик Шәфи» дигәндәге «правшик» сүзе рус телендәге «переводчик», ягъни тәрҗемәче. Бу очракта югарыда әйтелгән комиссиянең тәрҗемәчесе, Зөя өязе татары Шәфи Янайдаров күздә тотылган. Ул түрәләрне төрлечә куркытып, аларга янап, ришвәт һәм мөлкәт җыйган, талаган.

14 нче язмадагы Бикәй – Әгерҗе авылының Бикәй Акманай улы бу төбәкнең эре сәүдәгәрләреннән берсе булган. 1679 елда вафат булган әтисенең кабер ташы Әгерҗе зиратында хәзергәчә сакланган. Бу китапта 16 нчы сан белән билгеләнгән документтагы сотник – аның улы (Тимкә Бикәй угылы). Архивта (Мәскәүдә) Бикәй Акманай улына бәйле кызыклы документлар бар. Мәсәлән, аның Чабаксар өязенең чуваш кешесе Юпрай Тебякин белән рус телендәге 1734 елгы килешү документы сакланган. Юпрай бурычка Бикәйдән 30 сум акча алып торган һәм үз кызы Силихбияне закладка салган. Вакытында

бурычын түләмәсә, кызы Бикәйгә милек булып калачак һәм Бикәй аны теләсә сатып җибәрә алачак дип килешенгәннәр. Әлеге документтан күренгәнчә, морза-алпавыт булмаган һәм крепостнойлар биләмәгән ясаклы крестьян катламындагы бер татар түрәсе коллар тоткан һәм сата алган икән.

## 15–16. Паспорт сорау язмалары. 1755 ел.

15

// *(66а кәгазь)* Ул олуг падишаһ әгъзам хәзрәтләренең указы буенча, үзе камил биләгүче җөмлә урыс мәмләкәтене

Казан өязенең Җөри юлының Яңа Әгерҗенең Мөхәммәд сутнәсенең Малай Өч Имәннең Морзапулат Габдекәй угылы теләде ... Ык буенда Урсай авылында торып, угланнар укытырга ...

Язылды 1755 сәнә җөмәдиәлахыр аеның бишенче көне ирде.

Сутник Мөхәммәд Сөләйман угылы үз кулым берлән тамгам салдым ✕

16

// *(131 кәгазь)* Тарих мең дә йите йөз дә илле бишенче елның эчендә ирде. Казан өязенең Арча юлының Бакый сутнәсенең, бу вакытта править иткүче сутник мин – Тимкә Бикәй угылы үз илемдин йибәрдем Умга авылының ясаклы татар Мәүлекәй Бикчура угылыны.

Буе – ике аршун да ике биршук ярым, күзе – куе, саче – кара, йөз[е] – кызыл, сул йөзендә борыны катында миңе бар һәм сул кулында тишелеп аккан йир бар.

Мин – сутник бирдем видымыс падушнай ызбурдин пичатнай пашпурт алмак өчен Казан өязләр вә һәм үзгә өязләргә указ боерылган пыркурмления йөрмәк өчен көн элгәре бер ел срок берлә.

Ошбу утпускка инанмак өчен сутник Тимкә Бикәй угылы кулым куйдым.

***

15 нче санлы документта аталган Яңа Әгерҗе – хәзерге Татарстан Республикасының Әгерҗе шәһәре.

Ул вакыттагы сотня җитәкчесе Мөхәммәт Сөләйман улы (үзе Әгерҗенеке) карамагындагы «Малай Өч Имән» авылы – хәзерге Менделеев районындагы Татар Сарсазы авылы.

Урсай – хәзерге Азнакай районындагы авыл.

1755 елның 5 нче җөмәдиәлахыр көне милади буенча шул ук елның 19 мартына туры килгән.

Ясаклы татар авылларының сотня башлыгы булган Тимкә Бикәй улы (1710–1772) Әгерҗе авылының бай сәүдәгәрләр нәселе вәкиле булган.

Умга – хәзерге Татарстан Республикасының Әгерҗе районындагы Барҗы-Омга авылы.

Бу документта рус сүзләре аеруча күп кулланылган: *видымыс* – ведомость (исемлек), *падушнай ызбур* – подушный сбор (җан башыннан салым), *пичатнай пашпурт* – печатный паспорт (басма паспорт), *пыркурмления* – прокормление (тамак туйдыру), *срок* – вакыт.

Әлеге язмалар Россия дәүләт борынгы актлар архивындагы (Мәскәү) 529 фонд, 1 тасвир, 1527 саклану берәмлегеннән 2009 елда күчереп алынган иде.

## 17. Хәлегънамә формуляры. 1760 ел.

Тарих мең дә йите йөз дә алтмыш елның эчендә Казан өязенең фәлән юлның фәлән авылның фәләнә фәлән кызы ирем фәләннең фәләнчә сум тәкабеленә хәлегъ кыйлган мәҗлесендә хәлегы иҗабны кабул кыйлдым вә һәм көлли никах хакларындин бизмәк булдым. Ягъни гыйддәт нәфәкаседин бирелмәгән мәһәр хакында бизмәк булдым. Хәлегъ тәкабеленә фәләнчә сум кәнди ризам илә нәкъде кабз кыйлдырдым вә һәм баламны тәрбия өчен дәгъва кыйлмамдыр[2] дәю икърар кыйлып, хәзанә

[2] Кулъязмада: кыйлмадымдыр.

хакы сакыйт кыйлдым. Вә янә бу мәзкүр хаккы карздан вә һәм хаккы тәрбиядән гайре һичбер вәҗеһлә көн элгәре дәгъвам юктыр дәю икърар кыйлып, хаҗәт йирендә хөҗҗәт көнендә сүзем ялган, дәгъвам батыйль һәм булсын өчен телемдин ошбу язуны яздырып бирдем вә һәм кулым куймак урынына тамгам салдым гадел гүаһлар алдында. Вәссәлам.



*Хәлегънамә формуляры (уртадагы текст)*

***

Бу формуляр теркәлгән кулъязма китапның төп тексты – гарәп телендәге «Мөхтәсарел-Коддури» исемле фикъһ әсәре. Кулъязма китапның башындагы һәм ахырындагы битләрендә хәлегънамә калыбыннан тыш, татар телендә тыйбби язмалар,

XVIII гасыр татар шагыйре Әбүбәкер Рәхимкол улының шигыре, Пугачёв явы турындагы тарихи язма[3] да бар.

Кульязма истәлек Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «182г(149)» шифры белән саклана. Кәгазендәге «1751» датасына караганда, китапның төп тексты 1750 нче елларда күчереп язылган. Китапның зурлыгы 21х34 см, күләме исә 199 кәгазьдән тора.

Хәлегъnамә формуляры 198б кәгазьдә кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача.

Бу китап Милли китапханәгә Чувашстанның Козловка районы Кармыш (Янгильдино) авылында яшәүче Әхмәт Мифтахетдиновтан 1996 елның 19 сентябрендә китапханә хезмәткәрләре Ирек Һадиев һәм Айрат Заһидуллин тарафыннан алынган.

## 18–28. Алыш-биреш килешүләре. 1764–1767 еллар

18

// *(10а кәгазь)* [Тар]их мең дә йите йөз дә алтмыш түртенче елда ирде, Зөя өя[зенең] кенәз Аккылыч сутнәсенең Бик авылының Мусай угылы алдым түрүт капка утызар тиен, тукыз пот ун герәнкә көзлә[веккә] куясы, Үти авылының Мөхәммәд Хаҗи угылындин.

Янә ул ... Үти авылының Кадер(?) Сәгъди угылы көзләвеккә.

Вә янә Байтирәк авылының Дүскә угылы.

Вә янә алды Әлки авылының Тимер алты ... капка ...шәр тиен. Көзләвеккә куясы тукыз пот ун герәнкә. Ул төштә [гүаһ] шул ук авылның Сөлти Искәндәр угылы. Вә янә гүаһ шул ук [авылның] Вәлит(?) Байтуган угылы.

Вә янә гүаһ шул ук авылның Шәриф Сө... угылы.

---

[3] Тексты басылды: Мөстәкыймов И., Мәрданов Р. Пугачев күтәрелеше тарихыннан бер чыганак // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1998. – №3/4. – Б. 220–224.

Вә янә алды Әлки авылының Мөхәммәд керәшен Бәймәт угылы.

Вә янә Морат(?) Тимер угылы алды түрүт капка егерме йитешәр тиен, көзләвеккә куясы тукыз [пот]. ... тамгаларын салдылар✓

Ул төштә гүаһ Бик авылының Абдул Шәммәт угылы.

Вә янә алды Әлки авылының Кәләй Җармәкә угылы ике капка утызар тиен, көзләвеккә түләсе тукыз пот ун герәнкә.

Ул төштә гүаһ шул ук авылның Габдери мулла Җармәкә угылы.

Вә янә гүаһ Мөрсәлим Сөләйман угылы.

Вә янә алды Әлки авылының Мусай Ырысай угылы бер капка утызар тиен, көзләвеккә куясы тукыз пот ун герәнкә. ✕ Йөкчесе ...

19

//*(10б кәгазь)* [Тарихе румия] берлә мең дә йите йөз дә алтмыш түртенче елда ирде, Зөя өязенең кенәз Аккылыч сутнәсенең Әлки авылының Төткәй алдым унике сум акча, ике пот көзге ашлык бирмәкче булып [Үти] авылының Мөхәммәд мулла Хаҗи угылындин. Вәгъдәсе – алтмыш бишенче түртенче[4] елның көзге Микулында.

Мин – юкарыда язылган Нәүрүзгали Әсфәндияр угылы ошбуңа йөкче булып, … булып кулым куйдым.

Ул төштә гүаһ Үти авылының Габделкәрим сутник(?) гүаһ.

Вә янә Бик авылының мулла Морадбакый мулла Калмәт угылы гүаһ...

20

// *(10б кәгазь)* [Тарихе] румия берлә мең дә йите йөз дә алтмыш түртенче елда ирде, Зөя өязенең [кенәз Аккылы]ч сутнәсенең Чачкаб авылының Җәрми Җәким угылы алдым

---

[4] Кульязмада шулай ике сан язылган.

биш сум акча Үти авылының Мөхәммәд мулла Хаҗи угылындин.

Түләр вәгъдәм – алтмыш түртенче елның саратанның әүвәл көне берләдер ⨱

Ул төштә гүаһ Бик авылының Колмәмәт Килтәк угылы ⩛

## 21

// *(10б кәгазь)* Тарих берлә мең дә йите йөз дә алтмыш түртенче елда ирде, Зөя өязенең кенәз Аккылыч сутнәсе Чачкаб авылының Бикбау Бикәй угылы алдым унбиш(?) сум акча Үти авылының Мөхәммәд мулла Хаҗи угылындин. Түләр вәгъдәм – ... язып тамгам салдым ⨯

Ул төштә гүаһ Чүпрәле авылының Габделҗәлил Минкә угылы.

Янә гүаһ Чүпрәле авылының Әлмөхәммәд Кормый угылы.

## 22

// *(11а кәгазь)* Вә янә алдым Бик авылының Даут Ягъкуб угылы бер сум акча. Вәгъдәсе – бу ... җарусының җир урасы түрүт көн, печән чабасы. Үзе булмасам, түрүт ... икешәр кеше печән чабасы.

Ул төштә гүаһ Бик авылының Рәхмәтулла Бикмән(?) [угылы].

Янә алдым Бәшир керәшен Мөслим угылы бер сум да егерме тиен акча, бер җир уракның алты көн печән чабасы.

Вәгъдәсене түләр булмаса, мин – йөкчесе шул ук авылның ... Колмәмәт угылы.

Ул төшдә гүаһ Мөрсәлим(?) Туксан угылы.

Вә янә Әлки авылының Ниязмәмәт Гадел абыз угылы бер сум акча. Вәгъдәсе – сөбә(көбә-?) бәйрәме. [Җир у]расы түрүт көн, печән чабасы.

Вә янә алды Үти авылының Әлмәкәй керәшен ... [угылы] ... сум акча. Вәгъдәсе – Нуба(?) бәйрәме. Бер җир урак урасы.

Вә янә алды Кормыш керәшен Ырыс(?) угылы түрүт сум печән чабарга ⨯

Янә алды шул ук авылның Мусул(?) ... түрүт сум печән чабарга ×

Янә алды шул ук авылның Йүр[инә] угылы ун сум түрүт көн печән чабарга

Бер-берсенә йөкче булдылар.

23

// *(7а кәгазь)* Тарих мең дә йите йөз дә алтмыш бишенче елда ирде, кенәз Аккылыч сутнәсенең Әлки авылының Сали Илмәк угылы алдым ике сум алтмыш(?) тиен акча Үти авылының Мөхәммәд мулла Хаҗи угылындин.

Түләр вәгъдәм – алтмыш бишенче елныңураштывасыдыр.

Түләмәкче булып тамгам салдым

24

// *(6б кәгазь)* Тарих мең дә йите йөз дә алтмыш алтынчы елның ... [Зөя] өязенең кенәз Аккылыч сутнәсе Әлки авылы Әбкә керәшен Шәйх... угылы алдым унике сум кырык тиен акча Үти авылының Мөхәммәд мулла Ха[җи] угылындин.

Вә янә алдым мин – Сахиясәрви Эсмәгыйль кызы угыл[ым] Атлас берлә унике сум акча кырык тиен. Ул унике сум кырык тиен акчадин бирәсе булдым алты сум акча Сәгыйдкә, бирәсе булдым чутка ... бирәсе булдым. Вә янә Сахия бирәсе булдым Атласка ... Вә янә түләсе вәгъдәм алтмыш [йитенче ел]ның сәвернең унбиш көне.

Җугар[ыда] ...итәрмез, кару итмәмез һәм хатыны боерса, угылы боерса, мин – Сәгыйд энкәсенең гү[а]һ булдым һәм ... бу калган акчаны түләмәкче булдым. Мин Сәгыйд Сәедкол угылы тамгам салдым ⌄

Ул төштә гүаһ Казан өязенең Үти(?) авылының Ягъкуб Талмай угылы гүаһ булып тамгам [салдым].

25

// *(3б кәгазь)* [Тарих мең дә йите йөз дә ал]тмыш йитенче елда ирде, Зөя өязенең [Чачкаб авылының] Габдеррәшид

Бикмәт угылы алдым ун сум акча Үти авылының Мөхәммәд мулла [Ха]җи угы[лындин].

Түләр вәгъдәм – Пукараудыр.

Ул ун сум акчаны алтмыш йитенче елның Пукара[уда] түләмәкче булып тамгам салдым

Бу юкарыда язылган Чачкабның [Габде]ррәшид Бикмәт угылы әмере берлә мин – Бик авылының Телмәт Ярмәк угылы ... яздым.



*Мөхәммәт мулла Хаҗи улы дәфтәренең 3б кәгазе*

## 26

// *(3б кәгазь)* Тарих мең дә йите йөз дә алтмыш йитенче елда ирде, Зөя өязенең [кенәз Аккылыч] сутнәсенең Куҗак авылының Шабай Хөсәен угылы алдым түрүт сум акча Үти авылының Мөхәммәд мулла Хаҗи угылындин.

Түләр вәгъдәм – Зимли Микулыдыр.

Мин – Шабай Хөсәен угылы түләмәкче булып тамгам салдым ϟ

Мин – Яһүдә Мостай абыз угылы түрүт сум акчаны Мөхәммәд мулла Хаҗи угылына түләмәкче булып, йөкче булдым һәм тамгам салдым ϫ

## 27

// *(4а кәгазь)* Вә янә алды Әлки авылының келәүле керәшен Алмәк угылы ике капка утызар тиен. Көзләвеккә куясы тукызар пот ун герәнкә Y

Вә янә алды Тәүгелденең Иманкол Биктүеш угылы өч капка.

Вә янә алды Тәүгелденең Хамидә Биккол кызы түрүт капка егерме сигезәр тиен. Көзләвеккә куясы – тукыз пот ун герәнкә ᚹ Йөкчесе шул ук авылның Иманкол Биктүеш угылы ν

Вә янә шул ук авылның ыстарыста Бикмулла угылы Y Йөкчесе Ракәй Сөләйман угылы н Вә янә йөкчесе Моксин(?) Сөләйман угылы Ͷ Вә янә йөкчесе Сәфәр Абдул угылы × Вә янә йөкчесе Рахман мулла ᛏ Вә янә йөкчесе мулла Солтангали Y

Вә янә алды Тәүгелденең Иманкол Биктүеш угылы түрүт кабка утызар тиен. Көзләвеккә куясы – тукыз пот ун герәнкә. Йөкчесе шул ук авылның Хамидә Биккол кызы.

Вә янә алды Аксуның Мөслим ике капка утызар тиен. Көзләвеккә куясы тукыз пот ун герәнкә. Ул тө[штә] гүаһ Шыгырдан(?) авылының Алмыш угылы Чубук.

## 28

// *(6а кәгазь)* Вә янә Гали Үсәй угылы бер җир урак урасы.

Вә янә Морадхан Ак… угылы бер җир урак урасы.

Вә янә Бәшир керәшен бер җарым биш урак урасы.

Даут Ягъкуб угылы бер җарым биш урак урасы.

Вә янә Байтирәк авылының Алса(?) керәшен ике җир урак урасы.

Вә янә алды Бик авылының Бәшир керәшен Мөслим угылы ике сум акча. [Түлә]р вәгъдәсе – буз(?) бәйрәмедер. Йөкчесе шул ук авылның Ибрай Илмәт угылы.

Янә ... авылының [Сәйдәш] Сөйкә угылы, мин – Ибрай Илмәт угылы, вә янә Сәйдәш Сөйкә угылы ике сум акчаны түләмәкче булып тамгаларымызны салдык 

***

Югарыда китерелгән, 18–28 саннары белән билгеләнгән текстлар 16х21,5 см. зурлыгындагы 11 кәгазьдән торган таркау битләргә кара һәм көрән төстәге язу каралары белән теркәлгән. Кәгазьләрнең сакланышы шактый начар: кәгазьләре гаять таушалган һәм ертылган, читләре тетелгән, язулары уңган.

Бу язма битләрдә теркәлгән алыш-бирешләрнең вакытлары чыкканнан соң алар бер-берсенә ябыштырылып башка бер кульязма китап тышлыгы өчен кулланылган.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «543т» шифры белән саклана. Ул Казан шәһәренең I татар гимназиясеннән китапханә хезмәткәрләре Айрат Заһидуллин һәм Ильяс Мөстәкыймов тарафыннан 1995 елның 24 февралендә алынган иде.

Язмалардан аңлашылганча, алар Үти авылының Мөхәммәт мулла Хаҗи улының алыш-бирешләр язып барган дәфтәрендә теркәлгән булган. Текстларда язылган авыллар: Бик, Үти, Әлки, Чачкаб, Тәүгелде, Аксу – хәзерге Буа районында һәм алар бер тирәдәрәк урнашканнар. Болардан Бик һәм Үти – хәзерге вакытта кушма авыл Бик-Үти буларак билгеле. Чачкаб дигәне – Яңа Чәчкап булса кирәк. Кужак – хәзерге вакытта Буа районындагы Әхмәт авылының бер өлеше. Шыгырдан дигәне, ихтимал, хәзер шул ук районга керә торган Кече Шыгырдан авылыдыр. Байтирәк – хәзерге Чувашстанның Яльчик

районындагы чуваш авылы. Болардан тыш, Чүпрәле атамасы да бар.

Язмалардагы «көзләвек» сүзе көзлектә (көз көне) дигәнне белдерә.

19 нчы санлы язмадагы «көзге Микул» – 11 август көнендә үткәрелә торган православие бәйрәме.

20 нче язмадагы «саратан» – июнь ае.

22, 28 нче язмалардагы «бер җир урак урасы» дигәндә иген үскән имана җирен уру күздә тотылган.

23 нче язмадагы «ураштыва» дип язылган сүз «Раштуа»ны (православларның Рождество бәйрәмен) белдерә.

24 нче сандагы «сәвер» – апрель ае.

25 нче язмада «Пукарау» – 14 октябрь көнендә билгеләнә торган православие бәйрәме («Покров»).

26 нчы язмадагы «Зимли Микулы» – Зимни, Зимний (ягъни, Кышкы) Микул – 19 декабрьдә үткәрелә торган православие бәйрәме.

27 нче язмада «Әлки авылының keләүле керәшен» дигән гыйбарәдәге «keләүле керәшен», күрәсең, чуваш кешесе булгандыр. Тау ягындагы аерым авылларның бер өлешендә татарлар һәм икенче өлешендә чувашлар яшәве электән үк килгән. Әлки авылының башка кешеләренә карата «keләүле» дигән сыйфатлама кулланылмыйча, бары тик берсе генә шулай дип аталган булуына һәм «keләү» сүзенең, гадәттә, мәҗүси инануларына бәйлелегенә күрә шундый фикергә килдек.

## 29. Хәлегъ язуы. 1768 ел.

Бу әүвәл хәлегъ хаты торыр

Бителде имин, могтәмәд мөселманнар хозурында мөштәмил бу мәгънәнең бәян үзрә мең дә йите йөз алтмыш сигезенче елда маһе рамазанның бишенче көнендә Казан өязенең Алат юлының Җәмәк авылының Сөбханкол Иштирәк угылы үз ихтыярым берлән хәләл җефетем Хәдичә Сәләй кызыны хәлегъ кылдым, егерме ике сум тәкабеленә гыйддәт нәфәкасен вә һәм

гайре хокукы никахларны ибраэ кылмак шарты берлә вә һәм ул мәзкүр егерме ике сум акчаны нәкъде кабз кылып алдым.

Хаҗәт йирендә хөҗҗәт өчен телемдин ошбу хатны язып бирдем, кәнди риза берлә тамгам салдым.

***

Текстта язылган 1768 елның 5 рамазан көне 25 гыйнварга туры килгән.

Җәмәк – хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районындагы Чәмәк авылы.

Бу хәлегънамә Татарстан Республикасы Милли музеенда Зәйнәп Максудова фондында (ГОМРТ 13-9, №18369-554) саклана торган дәфтәрнең 24а кәгазеннән күчереп алынды. Аны З.Максудова 1960 нчы елларда күчереп теркәгән. Текст астында аның мондый искәрмәсе бар: «Бу хат күчереп алынды кульязма «Мөхтәсарел-викая» китабының тышыннан. Китапны 1182 һиж[ри] 1768 елда Казаклар авылында Ибраһим мулла мәдрәсәсендә укучы Баттал ибне Җуртай исемле кеше язган. Бу китап миндә саклана. – (З.М.)».

Шушы кульязма китап турындагы мәгълүмат, аның бетем өлеше (205б кәгазе) белән хәлегънамә тексты теркәлгән 206а кәгазенең фоторәсемнәре басылган: Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. – Мәскәү, 2019. – С. 57–58.

## 30. Хәлегънамә формуляры. 1768 ел.

Хатты хәлегъ

Тарих мең дә йите йөз дә алтмыш сигезенче елда Казан [өязе]нең Алат юлының фәлән авылның мән – Гөлбостан Габди кызы ирем Габделкәрим Хәсән угылының түрт сум тәкабеленә хәлегъ кыйлган мәҗлесендә хәлегы иҗабны кабул кыйлдым вә һәм көлли никах хакларындин бизмәк булдым. Ягъни, гыйддәт нәфәкаседән вирелмәгән [мәһәр] хакыннан бизмәк булдым. Хәлегъ тәкабеленә түрт сум акча ризам илә нәкъде кабз кыйл-

дырдым вә һәм кызым Гөлбагыйдә, угылым Галине тәрбия өчен дәгъва кыйлмамдыр дәю икърар кыйлып, хәзанә хакыны сакыйт кыйлдым. Вә янә бу мәзкүр хокукы никахдан вә һәм хаккы тәрбиядән гайре һичбер вәҗеһлә көн элгәре дәгъвам юктыр дәю икърар кыйлып, хаҗәт йиирендә, хаҗәт көнендә сорса[лар] ялган вә дәгъвам [батыйль] булсын өчен телемдин ошбу язуны яздырып бирдем вә һәм кулым куймак урынына тамгам салдым галәи гүаһлар алдында.

***

Бу текст 21x34 см. зурлыгындагы, 1771 елгы кулъязма китапның 1б кәгазенең буш калган читенә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуның тәгълик төрендә теркәлгән. Саклanышы уртачадан түбән: кәгазь читләре шактый таушалган.

Кулъязма китапның гомуми күләме 198 кәгазьне тәшкил итә һәм аның күчерелгән урыны һәм вакыты үзендә бу рәвештә язылган: «кәтәбтү һәзиһи ән-нөсхәтиш-шәрифәти фи вилайәти Казан вә фи тарикати Алат вә фи карьяти Урбар вә фи мәдрәсәи мулла Бикчәнтәй бине Ибраһим фәкыйрелхәкыйрь Идрис бине Арслан... фи тарихи мәсихия 1771 сәнә вә фи маһе сәфәрнең 10 йаумендә» (бу изге нөсхәне күчереп язды фәкыйрь, кимчелекле Идрис Арслан улы Казан өязенең Алат юлындагы Урбар авылында мулла Бикчәнтәй Ибраһим улы мәдрәсәсендә милади 1771 елда, сәфәр аеның 10 көнендә[5]).

Урбар – хәзерге Татарстанның Балтач районындагы Арбор авылы.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1220г(1031)» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Шәүкәт Фәйзрахмановтан 1997 елның июль аенда алынган.

---

[5] 1771 елның 10 сәфәр көне милади буенча 25 майга туры килгән.

## 31. Көтүче булып яллану турындагы килешү. 1779 ел.

Ош[бу д]угавар язылды 1779 елында җөмәдиәләүвәл аеның егерме бишенче йаумендә мән ялландым Сенбер өязенең Ишмәкәй сутнәсенең Кималау авылының Иван Чирникау угылы ыстаршина Киекбай Ямансарый угылы камандасының өч авыл кешеләренә сарык көтүенә, маһе рамазан ае беткүнчә, биш сум хакы илән вә һәм бер кием ослы күн катасы хакыннан тыш.



*Көтүче булып яллану килешүе*

Мәзкүр ялланган байлардан арадан сарык югалып, үләксәсе табылса, түләмәкче булмадым. Янә табылмаса, түләмәкче булдым. Тамак нәфәкасе үзләре өстеннән буласы булды.

Ошбу ялланмаклыкымныңраслыгына вә һәм риза булмаклыкыма мән – Кималау авылының Иван Чирникау угылы тамгам салдым +

Ошбу дугавар язуына гүаһ булып мән – Монасыйб Бигәш угылы кулым куйдым.

Вә һәм мән – ил мулласы Баязид мулла Таеш угылы гүаһ булып кулым куйдым.

***

Бу килешү язуы һәм аннан соң 32–34 нче саннар белән урын алган хосусый актлар Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең 2023 елгы (июль аенда), Арча районына оештырылган археографик экспедициясе вакытында Хәсәншәех авылында яшәүче Искәндәр Солтановтан алынган.

Текстларына күрә, алар үз вакытында старшина Киекбай Ямансарый улының дәфтәреннән калганлыгы аңлашыла. Кулланылыштан чыкканнан соң ул кәгазьләр башка кулъязма китап тышлыгына ябыштырып файдаланылганнар. Шул сәбәпле сакланышлары уртачадан түбән: язулары уңган, кәгазь читләре таушалган һ.б.

Монда тупланган документларда старшинаның әтисенең һәм улының да исемнәре (Ямансарый Җәббар улы һәм Вәлит Киекбай улы) теркәлгән.

Тарихи хезмәтләрдә язылганга караганда, Оренбург ягындагы Суун-Кыпчак (Сөн-Кыпчак) волостенең 1768 елдан алып поход старшинасы дәрәҗәсендәге Ямансарый Җәббар улы, үзенең улы Киекбай белән бергә 400 кешелек башкорт гаскәре белән пугачёвчыларны бастырырга баргач, баш күтәрүчеләр тарафына күчкән. Анда ул полковник дәрәҗәсендә булган. Өлкән яшьтәге Ямансарый да, Киекбай да хөкүмәт гаскәре ягына да чыгып, төрле якта сугышканнар. Ямансарыйның шул вакыттагы гамәлләренә бәйле ике архив документы басылган

иде[6]. Ямансарый Җәббаров һәм аның улы Киекбай турында башка хезмәтләрдә дә мәгълүматлар бар. Мәсәлән, Салават Таймасов китабында Киекбайның 1816 елда исән булганлыгы һәм 71 яшендә 9 нчы кантон башлыгының ярдәмчесе сыйфатында хезмәт иткәнлеге әйтелгән[7].

Башкортстанның Коергазы районындагы Ямансары (Ямансарово) авылының исеме әлеге Ямансарый Җәббар улына турыдан-туры бәйле. Монда текстлары басылган документлар да нәкъ шул авылда язылганнар булса кирәк.

1779 елгы килешү документы китапханәдә «7494т» шифры белән саклана. Әлеге текст 16,3х21 см. зурлыгындагы кәгазьгә кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

Текстта язылган 1779 елның 25 җөмәдиәләүвәл көне 21 май көненә туры килгән.

## 32. Хәлегъnamә. 1780 ел.

17[80] нче елда Суун-Кыпчак илүенең ыстаршина Киекбай Ямансарый у[гылы] камандасының пахутнай ыстаршина Әмкәч Аккөбәк угылы үземнең хә[ләлем] Йобар Бохар кызыны үзенең әйтеп теләмәке өчен мән – мәзкүр Әмкәч утыз [биш] сум тәкабеленә хөлугъ кыйлдым. Ик[әвемез ихтыя]рымыз берлә.

Мән – мәзкүр Йобар Бохар кызы мәзкүр утыз биш сумны ... тулган заманында түләмәкче булдым.

Мән – мәзкүр пахутнай ыстаршина Әмкәч [Аккөбәк] угылы ошбу хөлугъ хатыны бирмәклегемнең раслыкына [инан]мак өчен [кулым] куйдым.

Ошбу эшкә мән – ыстаршина Киекбай Ямансарый угылы

[6] Воззвания и переписка вожаков Пугачевского движения в Поволжье и Приуралье / сост. М.А.Усманов, С.Х.Алишев, И.А.Гилязов, Ф.М.Хисамова. – Казань: изд-во ун-та, 1988. – С. 173–174, 419–420.

[7] Таймасов С. Восстание 1773–1774 гг. в Башкортостане. – Уфа: Башкирское изд-во «Китап», 2000. – С. 196–197.

гүаһ булып [тамгам] салдым

Вә янә шул ук ыстаршина авылының бән – Бикҗан Тайгын угылы [гүаһ бу]лып тамгам салдым

Сәнә 1780 елда маһе шәгъбанның 11 нче көн[ендә].

Ике тарафдин, әмерләренчә, ил мулласы Баязид Чура угылы язып кулым куй[дым].

Бу хөлугънамәне күчереп алдырып калдым бән – Вәлид Киекбай угылы.

Баязид мулланың язылганыны Муса Иманкол угылына йибәрдем, теләмәсе сәбәпле, Азнабай артындин.

***



*Вәлид Киекбай улы язган документлар*

Бу кульязмага бәйле гомуми мәгълүмат 31 нче санлы килешүгә бирелгән искәрмәдә язылды. Ул китапханәдә «7493т» шифры белән саклана. Әлеге текст 16,5х21 см. зурлыгындагы кәгазьгә сыек көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

Тексттагы хатынның Йобар дигән исеме чынлыкта Җөфар (Гөлҗөфар) булгандыр.

Документ ахырындагы «теләмәсе» сүзе «теләве» мәгънәсендә.

1780 елның 11 нче шәгъбан көне 12 августка туры килгән.

## 33. Ат сату турындагы килешү. 1781 ел.

17[81] сәнә маһе шәгъбанның 7 нче көнендә мән – Мортаза Ураз угылы алды[м] көрән а[т] Суун-Кыпчак илүенең ыстаршина Киекбай авылының шул ук авылның Габделваһһаб Сәй… [угы]лыннан. Хакы унбиш сумнан.

Әлхаль бирәсе булдым бер сум, янә калды унтүрт сум. Түләр [вакыты а]кчаны – кыш уртасында.

Ошбуның ыраслыгына мән – Мортаза Ураз угылы кәндү әлем илән тамгам [сал]дым 

Ошбуның ыраслыгына мән – Кунаккуҗа Түрә угылы гүаһ булып тамгам салдым 

[Ик]е тарафның әмеренчә, писерлык эшен әда кылгучы Вәлид Киекбай угылы язып кулым куйдым.

***

Бу кульязмага бәйле гомуми мәгълүмат 31 нче санлы килешүгә бирелгән искәрмәдә язылды.

Әлеге текст китапханәдә «7492т» шифры белән саклана торган кульязманың 1б кәгазендә теркәлгән. Ул 16х21 см. зурлыгындагы кәгазьгә ачык көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

1781 елның 7 нче шәгъбан көне 29 июльгә туры килә.

## 34. Мәһәр хакын түләтү турындагы язма. 1781 ел.

Сәнә 1781 маһе шәгъбанның 7 нче йаумендә без – приказда язылган хөкемчеләр – Солтанморат Габдеррәшид(?) угылы, вә янә мулла – сутник Байкилде Карай угылы, ыстаршиналык эшен әда кыйлгучы Морад Туктар угылы Сөнбелә (?) ...й кызына [т]үләгән мәһәр хакыны бирмәккә боердык.

Әүвәл – бер колынлы бия, янә ... бәһасе, ике бия, вә янә ике тув сыгыр.

Ошбу [эш] хакында ... үтәгән аставнай ыстаршина Ямансарый Яббар угылы гүаһ булып, тамга[м сал]дым

Вә янә шул ук эшкә сутник Сөбханкол Аксарый угылы [гүаһ] булып, кәндү әлем илән тамгам салдым

Вә янә шул ук эшкә Бикҗан Тайгын угылы гүаһ булып, тамгам салдым

Вә янә шул ук эшкә мән – мулла Имамколый Корбангали угылы гүаһ булып, кулым [куйдым].

[Гүа]һларның әмеренчә, писерлык эшен әда кыйлгучы Вәлид Киекбай угылы [язып] кулым куйдым.

***

Бу кулъязмага бәйле гомуми мәгълүмат 31 нче санлы килешүгә бирелгән искәрмәдә язылды.

Әлеге текст китапханәдә «7492т» шифры белән саклана торган кулъязманың 1а кәгазендә теркәлгән. Ул 16х21 см. зурлыгындагы кәгазьгә ачык көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

1781 елның 7 нче шәгъбан көне 29 июльгә туры килгән.

«Тув сыгыр» дигәндәге «тув» (ту) – еллар буенча савылмаган сыерны белдергән.

## 35. Солыхнамә формулярлары. 1794 ел.

«а»

// *(5б кәгазь)*

Бу намә әүвәл солыхнәмәседер

Бителде түбәндә йад уласы имин могтәмәд галәйһи гадел гуаһлар алдында һәр ике могайин ризалыгы берлән сәнә 1794 нче елда ма[һе] рамазанның 5 йаумендә фәлән округының фәлән авылның мөддәгый фәлән бине фәлә[н] дәгъва кыйлынмыш йөз илле сум акча солых кыйлдым фидаи ямин вә катыйг хосумәт өчен кәнд үзем ризалыгым берлән биля икраһ бу солых бәдәленә җаиз күреп, соңгы көн аслан сүз-өн итмәз өчен бу солыхны икенче имамлара кыйлмаз өчен, хаҗәт вакытында хөҗҗәт улсын өчен вә һәм хакимнәр хозурында телем киселеп, сүзем йөрмәсен өчен тамгам салдым



*Солыхнамә формулярлары*

«б»

Бителде түбәндә йад уласы имин могтәмәд галәйһи кемсәнәләр хозурында һәр ике могайин ризалыгы берлән сәнә 1794 нче елда маһе рамазанның 5 йаумендә фәлән округының фәлән авылның мән – мөддәгый галәйһи фәлән фәлән угылы түбәндә йад улачы мөддәгый фәлән фәлән угылы дәгъва кыйлмыш йөз илле сум мөддәгый биһи шәйдин солых кыйлдым 80 сум сәмәнгә фидаи ямин вә катыйг хосумәт өчен кәнди ризалыгым илән биля икраһ вә биля җәбер бу солых бәдәленә кабз иттердем бу солыхны икенче имамлара дәфегъ кылмаз өчен, хаҗәт вакытында хаҗәт улсын өчен вә һәм хакимнәр хозурында телем киселеп, сүзем йөрмәсен өчен үз кулым берлән тамгам салдым

«в»

// *(6а кәгазь)* 1794 нче елда маһе рамазанның 6 йаумендә без ки, мөддәгый фәлән фәлән угылы вә мөддәгый галәйһи фәлән фәлән угылы һәр икемезнең арамызда вакыйг улган дәгъвамызны катыг кылырга хөкем төздек фәлән авылның фәлән фәлән угылына нә кем би-вәҗһиш-шәргъ хөкеменә разый улып мән мөддәгый – фәлән фәлән угылы тамгам салдым

Вә һәм мән – мөддәгый галәйһи фәлән фәлән угылы би-вәҗһиш-шәргъ хөкеменә разый улып тамгам салдым

Хазирел-мәҗлес фәлән фәлән угылы гүаһ булып кулым куйдым.

***

Солыхнамә текстлары 13 кәгазь күләмендәге, 17х21,5 см. зурлыгындагы, төрле текстларны үз эченә алган кульъязма җыентыкның 5б–6а кәгазьләрендә көрән төстәге язу карасы белән теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбәнрәк: бит читләре таушалган һәм дымланып пычранган.

Кульъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «7132т» шифры белән саклана. Аны китапханәгә Татарстанның Теләче районындагы Урта Мишә авылыннан Рафаэль Яруллин табып, 1996 елның август аенда тапшырды.

Текстта язылган 1794 нче елның 5, 6 рамазан көннәре 6, 7 апрельгә туры килгән.

## 36. Васыятьнамә формуляры. XVIII гасыр ахыры.

Вәдгу васыяти мәктүбәти тәхтәр-рәэси тәхамийән һөҗү-мәл-мәүти дүнәһа вә йәтүбү ганиз-зөнуби. Мин китаби «Гай-нел-гыйлем» фил-бабис-сабигый.

Васыятьнамә

Ошбу тәзкирәдер шул хосуста, васыять иттем бән – габдез-зәгыйфь, фәкыйрь фәлән фәлән угылы файда вә зарарыма тәсаррыфым дөрест заманда.

Әүвәлән, мәгълүм ула халис игътикадым илә гүаһлык бирәмән – хакыйкатьтә эш будыр: һичбер мәгъбүд, бер Хак бар [дәгелдер] вә һәм мөмкин дәгелдер, мәгәр Аллаһы Тәгаләдер ялгыздыр вә шәрике юктыр, вә тугырылмады вә тугырмады, вә вәләддән вә барча носканнан мөнәззәһтер вә барча сыйфаты кәмаль илә мәүсуфтер.

Вә дәхи халис игътикадым илә гүаһлык бирәмән – хакыйкатьтә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлләм Аллаһы Тәгаләнең колы вә рәсүле вә дәхи вәхи үзәренә әминедер.

Вә дәхи гүаһлык бирәмән: хакыйкатьтә җәннәт – хак, вә тәмуг – хак, вә мизан – хак, вә сират – хак, вә газабе кабер вә сөале Мөнкир вә Нәкир – хак, кыямәт көне килгүчедер, аңарда шик юк, әһле кобур кобурдан купмакы – хак.

Вә дәхи тәхкыйк риза булдым Аллаһы Тәгаләнең Раббы-лыгына вә ислам диненә вә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлләм нәбүвәтенә вә Коръәннең имамлыгына, вә Кәгъбәнең кыйблалыгына вә мөэминнәрнең кардәшлегенә. Ошбу мәзкүр игътикад үзә тереклек кыйлдым вә дәхи, Аллаһы Тәгалә теләсә, үләрмән вә кабердән кубарылырмән ошбу игътикад үзәренә.

Вә дәхи тәзаррыг илә сораймән ул важибел-вөҗүд Аллаһы Тәгаләдән миңа үлем килгүнчә бәнем үзәремә нигъмәтне тәмам итмәкене вә мәзкүр игътикад үзәренә хатимәмне кылып, вә бәңа һибә вә бәннән мөхкәм кылган игътикаде сахихемне

салып калмаслыкыны. Аның өчен – хакыйкатьтә аңа махсус Малик вә дәхи аның иләдер хәер, вә дәхи ул барча нәрсәләргә Кадыйр.



*Васыятьнамә формуляры*

Вә дәхи тәүбәи нәсух илә тәүбә кыйламән вә үкенәмән Аллаһы Тәгаләнең әвамир вә нәваһисендә тәкъсыйр итмәкемә вә ярлыкайу эстәймән көлли гөнаһымнан вә хатамнан вә өмид идәмән Халикымнан вә Разыйкымнан Тәбарәкә исмиһи тәүбәм кабуллыгыны вә гафу идеп ярлыкамакыны. Аның өчен – үзе вәгъдә кыйлды, ошбу мәзкүрләр илә колларына үзенең нәбие Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәссәлләмгә индергән Кәлям Шәрифендә әйтте: «Вә Һуа әлләзи йәкъбәлү әт-тәүбәтә гань гыйбадиһи вә йәгъфү гани әс-сәйәати». Аллаһы Тәгаләнең сүзе раст, вәгъдәсе хактыр. Вә дәхи рәхмәте көлли нәрсәне сыгдырды вә газабыннан сәбкать итте, вә Һуа әл-Гафурур-Рәхим.

Вә, саниян, васыять кыйламән кәминә фәлән фәлән угылы балаларыма вә әһлиямә[8] вә тугмаларыма вә карибләремә вә шунлара – бәнем сүземе кабул идәрләр, шул нәрсәләр берлә васыять кыйлды, ул нәрсәләр берлә Ибраһим галәйһиссәлам вә Ягъкуб галәйһиссәлам угланнарына әйттекләре хәлләрендә: «Йә, бәнийә! Иннә Аллаһә әстафә ләкүмү әд-динә фә-лә тәмүтүннә иллә вә әнтүм мөслимунә», ягъни: «Әй, бәнем угланнарым, Хакыйкатьтә Аллаһы Тәгалә бирде сезләрә диннең сафусыны, ул – ислам динедер. Вә дәхи сезләрә тәүфыйк бирде ул динне тотмак өчен. Бәс, сезнең үлемеңез улмасын, мәгәр улсын ислам үзрә сабит улган хәлдә».

Вә дәхи васыять кыйламән – барчаңыз Аллаһы Тәгаләдән сакланасыз хак сакланмак илә! Вә дәхи Аллаһы Тәгаләгә мотыйг уласыз яшерендә вә әшкярәдә, сүзеңездә вә фигылеңездә. Вә каим идәсәз дине исламны, ул диндә мөтәфәррика улмаясыз, вә беләсез шул нәрсәләр кем васыять кылдым, һич кемсәнә анлардан моңсыз дәгелдер.

Вә дәхи васыять кыйламән бәнем әмваль мәтрүкәмнән әүвәлән муафыйкыс-сөннәт тәкфин вә тәҗһиз вә дәфен кыйлына вә моннан соң бирәчәк дөюнем, каза вә алачакларым икътиза вә рәдде вадигъ вә әманәт кыйлына. Вә дәхи кырык ел гомерем улып, мин вакътел-бөлуг шул кырык ел эчендә вә һәм Аллаһы

[8] Кульязмада бу сүз «әһемлә» дип, хаталы язылган.

Тәгаләгомер вирсә, дәхи шул кырык елдан зиядә улан мөддәттәге саләтем вә зәкятем вә әгъшарем вә кәффарәте ифтар, гамд вә кәффарәте иманым вә гайре нафилә көллиһи хәйрат өчен бәнем мәтрүкә-әмвалемнән һәркаю нәүгъдән булсын – игъна, кирәк халис нөкуд, вә кирәк халис каими нәрсәләр вә кирәк катыш улсын, каими нәрсәләрне мөкавиме гадил кыймматләмәге бәгъдендә бәкый акча бәһасе илә бең сумлык мал сарыф иделә. Ошбу мусый биһи бең сум малны фокарадан вә әгъниядан һәркемне васыем теләр вә ни микъдар вирмәкне ихтыяр идәр – аның раэи савабына тәфвизъ кыйлдым. Мәгәр фидия вирдектә дикъкате нәзар илә нәзар идеп, мәсърафы зәкят улдыкы кемсәнә улдыкы беленеп вирелә. Янә фидия вирелән мал микъдаре шәргыйгә васыйл улмадыкы өчендер, уйлә икмаль ителә.

Вә, салисән, мәгълүм ула ошбу вәсаяны тәнфизгә вә дәхи вафатым бәгъдендәге барча өмуремә вә әүляде сыйгарым өмуренә васый кылдым үземнең бертугма кардәшем – мулла фәлән фәлән угылыны, әманәтен вә диянәтен вә кифаятен вә шәфкатен игътикад итеп.

Вә дәхи бән – кәминә фәлән фәлән угылы, Аллаһы Тәгаләнең иганәтенә игътикад итеп, ошбу васыятьне кабул кылдым кабулән сахихән вә мөшафәһәтән.

Вә дәхи бән – мусый фәлән фәлән угылы вә бән – васый фәлән фәлән угылы гүаһ кылдык мәзкүр ирзага вә мәзкүр кабулга түбәндә исемнәре мәзкүр шаһиде гадилләрне.

Тәхрире мәүлана мулла Габдеррахман әл-Кирмәни.

***

Бу текст теркәлгән кулъязма китап Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «58г(50)» шифры белән саклана.

1791 елда Фәйзулла Йосыф улы тарафыннан күчерелгән, гарәп телендәге «Җамигыйр-рөмуз» китабы 21х33 см. зурлыгында, 417 кәгазьдән тора. Сакланышы уртача. Ул китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Нәкыйп Гасыймовтан 1992 елның 27 октябрендә алынган иде.

Васыятьнамә формуляры китапның 415б кәгазендә кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Текст башындагы «Васыятьнамә» дигән атамасы кызыл кара белән язылган.

Әлеге китапны сату-алу турындагы язмалары әлеге җыентыгыбызда 86–88 саннары астында бирелде.

Кулъязманың үзендә васыятьнамә тексты өстендә гарәп телендә «Гайнел-гыйлем» китабының җиденче бүлегенә ишарә ителгән. Андагы гарәпчә язылган «Вәдгу васыяти мәктүбәти тәхтәр-рәэси тәхамийән һөҗүмәл-мәүти дүнәһа вә йәтүбү ганиз-зөнуби. Мин китаби «Гайнел-гыйлем» фил-бабис-сабигый» гыйбарәсенең мәгънәсе бу рәвешле: «язылган васыятьне үлем һөҗүменнән сакланып баш астына салырга һәм гөнаһларга тәүбә кылырга. «Гайнел-гыйлем» китабының җиденче бүлегеннән». Чынлыкта, әлеге китапның төп текстында мондый сүзләр юк. Ихтимал, бу җөмлә китапның шәрех-комментарийларының берәрсеннән алынгандыр.

«Гайнел-гыйлем тәрҗемәсе» китабының 7 нче бүлегендә васыятьнамәнең кирәклеге мәсьәләсе бу рәвешле язылган: «Рәсүлуллага иярүнең хакы – васыять әйтмәклектер малның өчтән бере белән, дәхи намаз фидиясе берлән, дәхи рузә фидиясе берлән. Бәс бер кеше үлсә, ул васыятьтән башка изен бирелмәс ул кешегә сөйләшүгә кабердә кыямәт көненә кадәре...»[9].

Тексттагы «Коръәннең имамлыгына» гыйбарәсе «Коръәннең юлбашчылыгына» дигән мәгънәгә ия.

Тексттагы архаиклашкан сүзләрдән «калмаслыкыны» – «калмавын», ә «кыймматләмәге» – «бәяләве» дигәнне белдерә.

Башлангычтагы асыл тексты гарәп телендә булган васыятьнамәнең татарча вариантын хәзерләгән кеше – Габдрахман әл-Кирмәни булган дип кереш мәкаләбездә яздык.

---

[9] Гайнел-гыйлем тәрҗемәсе / мөтәрҗим – Шәйхелислам бине Әсәдулла Хәмидуллый әт-Төкеви. – Казан: матбагаи Кәримия, 1902. – Б. 125.

## 37. Гаһеднамә формуляры. XVIII гасыр ахыры.

Гаһеднамә вәгъдәседер

Бән, түбәндә исемләнмеш, Кадыйр Аллаһның исеме илән Коръән Шәриф алдында ант вә гаһед вә ямин итеп, шул хосуста кем, хәзердә бер төрле эш хакында бәндин соралыр булса, шул хәлдә бән һичбер якны якламаенча, барчасын тугрылык илән әйткүче булырмән. Нитәккем, Хак Сөбханәһә вә Тәгалә хәзрәтенең дәргяһендә һәм аның хәвефле хөкеме үзәрендә даимел-әүкат җавап вирмәккә кадыйр улгай ирдем. Амин.



*Гаһеднамә*

Ошбу антны тәмам итеп, Коръән Мәҗидне үбәмен. Йа, Могыйн!

***

Текст 16,5х21,5 см. зурлыгындагы өч кәгазьдән торган кулъязманың 1а кәгазендә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача.

Әлеге кулъязманың 3а кәгазендә Вәлид бине Сәгыйдьнең Габделҗаббар муллага язган хаты бар. Хатның авторы Оренбург Каргалысында имамлык иткән мәшһүр мөдәррис һәм ахун Вәлид хәзрәт 1806 елда вафат булган. Аның турында тарих китапларында язылган[10].

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «7509т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Уфа шәһәрендәге Диния Нәзарәте мәчетеннән бу юлларның авторы тарафыннан 1998 елда алынган иде.

## 38. Ышна җирен файдалануга бирү язмасы. 1800 ел.

Мең дә сигез [йөзе]нче елның эчендә Казан округы Төбъязның ясаклы кеше Габдессәлам Аптый угылы түрт иманалык ышна йирен бирдем шул ук Төбъязның Исмәгыйль Габдерраззак угылына. Янә Кара күл бу... иске Битаман юлында ике шобага йирен ... болын пае бирмәкче булдым.

Бу рәвешчә язды[р]ганлыкымның раслыкына мин – Габдессәлам Аптый угылы үз кулым берлән тамгам салдым

[10] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б. 248; Фәхреддин Р. Асар. 1 том / төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: «Рухият» нәшр., 2006. – Б. 60–61.

***

Бу текст 15х14 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән, чөнки бу кәгазь кулъязма китап тышлыгы өчен кулланылган булган.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «6381т» шифры белән саклана. Ул китапханәнең 2022 елда (7 сентябрьдә) Арча районына оештырылган археографик экспедициясе вакытында Мәмсә авылында яшәүче Нурсөя Низамовадан алынган.

Төбъяз – хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районындагы Дөбъяз авылы, Битаман – шул ук райондагы Зур Битаман авылы.

## 39. Вәкаләтнамә һәм хәлегъ хаты. 1815 ел.

// *(1а кәгазь)* 1815[11] нче ел июньнең 23 нче көн ирде, без – Минзәлә өязедәге[12] 11 нче кантуннай нәчәлник капитан [Бая]зид Солтанов кул астында булгучы юртавай ыстаршина Фәйзулла Биктимер угылы камандасы Чебенле [авылыны]ң хатын Сәрвиҗамал Габделмәҗид кызының вәкиле Габделмәҗид Ибраһим угылы мөддәгый вә һәм Чебенле авылы[ның] Сөендек Хуҗи угылы угылым Гайнулла тарафыннан вәкил мөддәгый галәйһи һәр икемез бер иттифакта, хөсне [и]хтыярымыз илән вәкил кыйлдык Малтабар авылының указной мулла Фазлулла Ишәй угылыны вә һәм ыстаршина [Фә]йзулла Биктимер угылыны вә һәм Сәгъди мулла Илкәй угылыны вә һәм Морадхуҗа Гали угылыны.

Кайсыдыр кем Гайнулла Сөендек угылының хатыны Сәрвиҗамал Габделмәҗид кызыны биргән мәһәрне кайтарып бирмәгәнне бәхилләмәк шарт үзәренә хәлегъ кыйлышмакга риза булганымыз бәгъдендә, мәһәргә бирелгән ун сум акча вә

[11] Кулъязмада елы ялгыш «18015» рәвешендә теркәлгән.

[12] Кулъязмада шулай язылган.

һәм ике басма күлмәк, бер кара кытат камзул юк булып, хатын ир кулында, ир хатын кулында низаглашмакымыз сәбәпле, мәзкүр вәкилләремез һәркаюмызның файда яки зарарымызга куеп, солхән җа... ...ләр риза булмак булып, түбәндә тамгаларымызны салдык:



*Вәкаләтнамә һәм хәлегъ хаты*

Габделмәҗид [Ибраһим угылы тамгам] салдым Ψ

Сөендек Хуҗи угылы тамгам салдым +

Мин – Малтабар авылының мулла Фазлулла Ишәй угылы ыстаршина Фәйзулла Биктимер угылы, памушник Бикмөхәммәд Бигәнәй угылы, Сәгъди Илкәй угылы, Морадхуҗа Гали угылы югарыда мәзкүр мөддәгый Габделмәҗид угылы берлә мөддәгый галәйһи Сөендек Хуҗи угылының хәлегъ кыйлышмакга риза булып низаглары хакында [сол]хән дәгъваларын катыг кыйлмага вәкил итүләре буенча ун сум акчаларын, ашаган-эчкән ...н һич тарафка салмадык, калган ике басма күлмәкне ун сумга куеп, камзулны биш [сум] га куеп, солхән сигез сум акча Габделмәҗид кызының зарарына, Гайнулла Сөендек угылы [фа]йдасына бирмәккә боердык.

Мин – Сөендек Хуҗи угылы югарыда мәзкүр хакимнәрнең [бәнем фа]йдама сигез сум боермакларын кабул итеп, хәзер мәзкүр сигез сумны кабз кыйлдым [вә һәм] тамгам салдым + Вә һәм хәлегъ хаты бирдек.

Габделмәҗид Ибраһим угылы тамгам салдым Ψ

// *(1б кәгазь)* Үткән бәндә мәзкү[р]чә солхән дәгъваларын катыг кыйлмага хөкем итүләре буенча илзам кылдым, растлыгына мин – Малтабар [авылының] Фазлулла Ишәй угылы кулым куйдым.

Ыстаршина Фәйзулла Биктимер угылы.

***

Бу текст 18х21,5 см. зурлыгындагы кәгазьнең ике ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазь читләре таушалган-ертылган, урталай бөкләнгән урыны тетелгән.

Татарстанның Сарман районындагы Саклаубаш авылында яшәүче Алмаз Фарукшиннан 2001 елның 1 июнендә сатып алынган бу кульязма истәлек Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2884т» шифры белән саклана.

Текстта исеме теркәлгән кантон башлыгы Баязит Солтанов мәшһүр татар дворяннары Солтановлар токымыннан

– майор дәрәҗәсендә булган Баязит Әбҗәлил улы Солтанов (1774–1823).

Чебенле – хәзерге Татарстан Республикасының Минзәлә районы территориясендә булган авыл, хәзер юкка чыккан.

Малтабар – хәзерге Татарстанның Тукай районындагы авыл.

## 40. Мохәйяр язуы. 1819 ел.

// *(1а кәгазь)* 1819 нчы елда дикәбернең 9 нчы көнендә кем, бән – Кызылъяр өязенең типтәрыскуй каманданың Яман Елга авылында торгучы Солтанбик Әҗмән угылы кәндү[13] ихтыярым илән, язу илән, багландым ахунд хозурында, каю кем үземнең никахе сахихемдә улгучы хатыным Рабига Хәмид кызының мәһәренә бирдем үземнең тора торган өюемез кырык сумга. Янә хәзер ошбу елда рабигыль-ахир аеның ахырында бозаулардай тана сыгыр алып бирмәк улдым. Янә бер сарык алып бирергә улдым. Янә ошбу елда, кеше Эрбеттән кайткач, бер кытат җилән алып бирмәк улдым, эче – Бохар басмадан улыр. Янә бер мамык билбау алып бирмәк улдым. Янә киләсе көзгә бер түшәк-ястык ясатып бирергә булдым. Янә нәфәкагә вә гайре зарури булган нәрсәләрдә мохтаҗ итмәскә улдым.

Әгәр дә бән – Солтан Әҗмән угылы ошбу йад иделмеш эшләрнең көллисене йә бәгъзесене мохаләфәт кыйлсам, тапшырдым хатыным Рабига Хәмид кызының кәндү үзенә ихтыярны – теләгән урында теләгән заманда ихтыяр кыйлырга дәю, бән – Солтанбик Әҗмән угылы тәләффыз кыйлып, кәндү әлем илән тамгам салдым.

Бән – Фазыл Габделлатыйф угылы гүаһ булып кулым куйдым.

// *(1б кәгазь)* Габделвәли Габделгазиз угылы гүаһ булып тамгам салдым.

Нәби Мерәкәй угылы гүаһ булып тамгам[14].

---

[13] Кулъязмада бу сүз «кәндүә» рәвешендә язылган.

[14] Кулъязмада «салдым» сүзе язылмаган.



*Мохәйяр язуы*

Мәзкүр Әҗмән угылының үтенүе илән ахунд Хөсәен угылы язып[15].

Копиядер.

***

Текст 17x21,5 см. зурлыгындагы кәгазьнең ике ягына кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача.

---

15 Кулъязмада җөмләнең ахыры – «кулым куйдым» сүзләре язылып бетмәгән.

Кулъязма Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «4347т» шифры белән саклана. Ул Казан дәүләт университетының 1980 елгы археографик экспедициясе вакытында Свердловск өлкәсенең Красноуфим районындагы Биеш авылында Мөхәммәт Габделхаковтан алынган.

Текстта язылган рабигыль-ахир аеның ахыры 1820 елның феврале ахырына туры килгән.

«Типтәрыскуй каманда» – типтәрләр командасы.

Яман Елга – хәзерге Свердловск өлкәсенең Красноуфим районындагы авыл.

«Кеше Эрбеттән кайткач» дигән сүзләрдә сәүдәгәрләрнең Эрбет ярминкәсеннән кайтулары күздә тотылган.

Текст ахырындагы «копиядер» сүзе бу нөсхәнең төп документ күчермәсе икәнлеген белдерә.

Бу кулъязма документ Җ.Миңнуллин китабында телгә алынган: Миннуллин З. Татарские частные акты XVII – первой половины XIX в.: источниковедческая характеристика. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. – С. 51.

## 41–43. Алыш-биреш килешүләре. 1822–1824 еллар.

41

// *(11а кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме икенче елда Мамадыш өязенең Казан губернасының Киличшинески вулусның Сатылган Клич авылының Пидур Микәйлә угылы саттым дүрт пот бал, хакы – унберәр сум.

Шул ук Мамадыш өязенең Казан губернасының Киличшинески вулусның Сиритни Мишә авылының Хәмзә Максуд угылы алдым шул дүрт пот балны мәзкүр бәһасенә.

Мин мәзкүр Пидур Микәйлә угылы ошбу[16] дүрт пот бал-

[16] Кулъязмада бу сүз «ошбуа» рәвешендә язылган.

ны Урта Ыспасда бирмәкче булып үз кулым берлә тамгам салдым

Вә һәм мин Ибан Мекетә угылы ошбу эшнең раслыкына үз кулым берлә тамгам салдым

Вә һәм мин – ил имамы Һибәтулла ошбуларның үтенече буенча кулым куйдым.

42

// *(11а кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме икенче елда Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Баландыш авылының Габдессәлам Көбәш угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан, әнкәмез Гайшә берлән бергә килеп, алтмыш ике сум акча алдым.

Түләр вәгъдәсе – Турчинда бирмәкче булып алдым.

Әгәр шул вәгъдәддә түләй алмасам, саттым пурамны сиксән сум бәһасе берлән.

Ошбу пурамның сатылганның раслыкына тамгам салдым Габдессәлам Көбәш угылы үз кулым берлән

Ошбу сүзнең раслыкына әнкәсе Гайшә кулым куйдым.

43

// *(10б кәгазь)* 1824 нче елда гыйнварның икенче көнендә мин Фәтхулла Сәлимҗан угылы алдым иманама егерме сум акча шул ук авылның Хәмзә Максуд угылыннан.

Вә шуның мөкабәләсенә бер келәтемне сатмак булып, гүаһлар алдында тамгам салдым

Ошбуның раслыкына гүаһ булып мин – Габделлатыйф(?) ... угылы тамгам салдым

Вә кинә ошбуның раслыкына гүаһ булып мин – Һибәтулла Гайса угылы язып кулым куйдым.

***

Бу текст һәм шулай ук моннан соңгы 45–72, 74, 76–80 саннары белән билгеләнгән текстлар Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1047т» шифры белән саклана торган,

1822–1833 еллардагы төрле килешүләр, алыш-бирешләр һ.б. язмалар теркәлгән дәфтәрдән алынды.

Кульязма 17х22 см. зурлыгында һәм 12 биттән гыйбарәт. Текстлары кара, көрән һәм сыек көрән төсләрдәге язу каралары белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Җыентыкның сакланышы уртача диярлек: кәгазь читләре таушалган һәм пычранган.

Дәфтәр хуҗасы Урта Мишә[17] (Кече Яңавыл, Иске Яңавыл) авылының (хәзерге Татарстанның Теләче районында) Хәмзә Максуд улы булган. Язмалар шул ук авылда һәм, нигездә, күрше-тирә төбәктәге башка авылларда яшәгән кешеләр белән бәйле.

Дәфтәрдәге алыш-биреш язмаларының бөтенесе дә бу китапка кермәде. Анда шулай ук башка мәгълүматлар (югалган әйберләр исемлеге, хуҗалык эшләре һ.б.) да теркәлгән. Дәфтәрдәге төрле язмалар һәм төрле еллардагы мәгълүматларның тәртипсезрәк рәвештә, аралаш терәкәлгән булуының сәбәбе – башта буш калган битләргә яңалары өстәлеп барганга бәйле.

Кульязма истәлекне китапханәгә Татарстанның Теләче районындагы Урта Мишә авылыннан Рафаэль Яруллин табып, 1996 елның 19 августында тапшырды.

41 нче язмадагы «Киличшинески вулус» – Ключище волосте, Сиритни Мишә – Урта Мишә атамалары. Сатылган Клич – дөресе «Сатылган Ключ» – хәзерге Саба районындагы Көек авылының элекке атамасы.

[17] Дәфтәр иясенең авылы исеме дәфтәрдә күбрәк Яңа Авыл дип кенә язылган. Яңа Авыл дип, гадәттә хәзерге Теләче районындагы Олы Мишә авылын атаганнар, ә Урта Мишәне Иске Яңа Авыл дигәннәр. Иске кульязма дәфтәрдә, күрәсең, «Иске» дигән сүзне язып тормаганнар. Чөнки дәфтәрнең хуҗасы Хәмзә Максуд улы тәгаен Урта Мишәнеке булган. Ул кайбер язмаларда (мәсәлән, №41) «Сиритни Мишә» (ягъни, Средний – Урта Мишә) авылы кешесе диелгән һәм башкаларында (№№54, 78, 80) «Сиритни Мишә» авылы «шул ук Яңа Авыл» дип тә белдерелгән.

Шундагы ук «Урта Ыспас» – 19 август көненнән башлап үткәрелә торган православие дине бәйрәме.

42 нче язмадагы «Турчин» (татарлар арасында «Тройчын» дип тә йөртелгән) – «Троица» бәйрәме, ул 31 май көнендә уздырыла.

Шул ук тексттагы «пура» язылышы – дөреслектә «бура».

Баландыш – хәзерге Татарстан Республикасының Теләче районындагы авыл.

## **44. Алыш-биреш килешүе. 1824 ел**.

[1824] елда июньнең 12 нче көнендә Минзәлә өязенең Байлар илүе[нең] тифтәр ыстаршина Гали Биктаһир угылы камандасы Малтабар авылының тифтәр Әмир Сорым угылы [вә] Мөхәммәдрәхим Әмир угылы алдык егерме сум акча үз хаҗәтемез өчен үз авылымызның указной мулла Фазлулла Ишәй угылыннан.

Мәзкүр акчаның ике сум тәкабеленә ярты пот яхшы бал бирмәк булдым. Калган унсигез сум акчасын үктәбрәнең әүвәл көнендә һичбер хәҗәтсез түләмәк булдык.

Мәзкүр рәвешчә бер-беремезгә йөкче булып, егерме сум акча алуымыз[ның]раслыкына түбәндә тамгаларымызны салдык.

Бән – Әмир Сорым угылы тамгам  салдым.

Бән – Мөхәммәдрәхим Әмир угылы тамгам  салдым.

Юкарыда мәзкүр Әмир һәм Мөхәммәдрәхимнең әмере берлән яздым бән – шул ук авылның тифтәр Зәйнелбәшәр Зөбәер угылы вә һәм кулым куйдым.

***

Бу текст Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2665т» шифры белән саклана торган кульязма китапның 15,5х19,5 см. зурлыгындагы 157а кәгазендә ачык кара төстәге язу карасы белән теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазь читләре тетелгән, язуы өлешчә уңган. Әлеге

алыш-биреш килешүе берничә әсәрдән торган (иң әүвәлге тексты 1787 елга карый) кулъязма җыентыктан алынды. Җыентыкның 96–99 кәгазьләрендә Дәвек авылының Хөсәен һәм хатыны Фатыйма Морадым кызы арасындагы низагны тикшерү эше язмалары да теркәлгән.

Кулъязма китапханәгә Казан шәһәрендә яшәгән галим Әнвәр Хәйридән 1998 елда алынган.

Текстта «типтәр» сүзе «тифтәр» дип язылган. «Үктәбрә» дигәне – октябрь.

## 45. Кыз баланы тәрбиягә бирү турындагы язма. 1824 ел.

Без – Минзәлә өязедәге типтәрләрдән дүртенче каманда-га ыстаршина Гали Биктаһир [угылы] камандалары Малтабар авылының картлары (кемнәрдер исемнәре түбәндә йад улы-ныр) асрамага бирдек үз авылымызның ятимә Бәдигыльҗамал Сәйфулла кызыны, ата вә анасы юклыктан, тәрбия кыйлырдай кардәше юклыктан, шул ук каманда Гөлек авылының Бикбикә Габделмән хатынына – көн элгәре ул кыз өчен бездән нәфәка сорамас шарт үзәренә вә һәм ул кыз хезмәт иясе булса, хезмәт хакы дип хак сорамаслыкымыз өчен түбәндә тамгаларымызны салдык.

Вә һәм мин – Бикбикә Габделмән хатыны мәзкүрә Бәдигыльҗамал Сәйфулла кызыны тәрбия кыйлмага алдым. Ходай өчен тәрбия кыйлмак булып, көн элгәре [тәрбия] хакы вә һәм нәфәка хакы сорамак булмадым, раслыгына тамгам сал-дым

Мин әүвәл ... Рахманкол Арслан угылы тамгам салдым

Рәхмәтулла Габдессәлам угылы тамгам салдым

А... Биктәй угылы тамгам салдым

Әмир Морадым угылы тамгам салдым

Фәтхулла Корбанай(?) угылы тамгам салдым

Яманай Имангол угылы тамгам салдым

Төхфәтулла Корбанай угылы тамгам салдым



*Баланы тәрбиягә бирү язмасы*

Хисамеддин Габдессәлам угылы тамгам салдым
1824 ел июньнең 25 нче көн.

***

Текст Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2665т» шифры белән саклана торган кулъязма китапның 155а кәгазендә ачык кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Әлеге кулъязма җыентыкның башка мәгълүматлары 44 нче санлы документның искәрмәсендә язылды.

## 46–71. Алыш-биреш килешүләре. 1824–1825 еллар.

46

// *(4б кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елында шәгъбан аеның унбишенче көнендә Керәшен Саурышының Йәпим Турыфим угылы алдым сигез сум акча язгы имана тугрысына Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан.

Җәкәү Питруш угылы йөкче булып, бергә алышып бирдем үзем түләмәкче булып, ул түләй алмаса.

Йәпим Турыфим угылы үземнең кызыл сыгырымны, түләй алмасам, унбер сумга саттым.

Һәм Йәпим Турыфим угылы Җәкәү Питруш угылы тамгам салдым

47

// *(3а кәгазь)* Мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче [елда] шәүвәл аеның өченче көнендә Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Төбәк авылының Туктагол Атнагол угылы алдым унбиш грүнкә җитен орлыгы, унбишәр тиен грүнкәсе, Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан биш пот он бирмәкче булып.

Тамгам салдым гүаһлар алдында раслыкына

48

// *(5б кәгазь)* 1824 нче елда маһе шәүвәлнең ундүртенче көнендә Төбәкнең мин – Хәмид Сәгыйд угылы алдым Яңа Авылның Хәмзәдән акча, яңа арыш оны [бирмәкче булып], илле пот. Ошбу онның бәһасе егерме бишәр тиен.

Ошбуның раслыкына гүаһ булып мин – Хәмид Сәгыйд угылы тамгам салдым

Вә кинә мин – Мөхәммәдәмин йөкче булып һәм гүаһ булып тамгам салдым

49

// *(6а кәгазь)* 1824 нче елда маһе зөлкагъдәнең егерме бишенче көнендә мин – Сәлимҗәүһәр алдым Хәмзәдән егерме сум акча моның мокабәләсенә: бер келәт – унбиш сум, янә ике сарык – биш сум.

Ошбуның раслыкына гүаһ булып мин – Сәлимҗәүһәр тамгам салдым

Вә янә мин – мулла Һибәтулла Гайса угылы язып кулым куйдым.

50

// *(2а кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елда Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Керәшен Саурышының Пәчили Пидыр угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан бер ат, бәһасе – кырык биш сум, төсе – көрән.

Атына Әликси Ибан угылы йөкче булып тамгам салдым

Шул атның бәһасе[нә] йөз илле мунчала бирмәкче булдым бу озынлыгы – өч карыш, киме – ярты арыш, янә арыштан илле пот он бирмәкче булдым. Янә арыш йиткәч, һич тә нәрсә бирә алмасам, илле пот он янга арыш йиткәч.

Раслыкына тамгам гүаһлар алдында: Пәчили Пидыр угылы

Янә Пәчили Ибан угылы агай-энегә бер-беремез түләмәкче булып тамга салдым.

51

Мин – Әликси Ибан угылы, Саурышның, алдым бер тәнкә Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан сигез пот он бирмәкче булып.

Ошбуның раслыкына үз кулым берлә тамгам салдым

52

Тарих мең дә сигез йөз дә егерме түртенче елда мин – Мамадыш укругының Казан губернасының Киличшинески

вулусның Елыш авылының Кирила Вачили угылы алдым сигез сум акча Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан арыш оны бәрабәренә. Поты – алтмыш тиен.

Янә шул ук Елыш авылының Кирила Вачили [угылы] алты пот он.

Ошбуларның раслыкына үз кулым берлә тамгам салдым ⊢

Вә һәм мин – Аргы Яңа Авылның Бикәй Әлмөхәммәд угылы ошбу эшнең раслыкына гүаһ булып тамгам салдым ⨯

53

// *(3б кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елда [алдым] Мамадыш укру[гы]ның Казан өязенең Озын Сач авылының Илҗә Пәчили угылы Хәмзә Максуд угылыннан дүрт сум акча имана тугрысына. Шул акчаны түләй алмасам, бер крибәмне саттым.

Раслыкына тамгам салдым ¬

54

Мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче [елда] Мамадыш укругының Йөри юлының Сиритни Мишә авылының Мөхәммәди(?) Мөрсәлим угылы алдым шул ук Яңа [Авылның] Хәмзә Максуд угылыннан имана тугрысына ике сум, сигез пот он бирмәкче булып, егерме бишәр тиенгә. Киләсе яңа арыш урагы өстендә бирмәкче булып.

Раслыкына тамгам салдым +

55

Тарих мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елда Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Иске Авылның Һибәтулла Корбангали угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан биш тәнкәгә имана тугрысына. Унбиш сумга бер пот бал бирмәкче булып алдым. Калган бер тәнкәгә һәм дәхи бал бирмәкче булып[18] алдым, яңа балга,

---

[18] Кулъязмада бу сүз ялгыш ике тапкыр кабатланган. Бу язмада бурычка алынган акча күләме буталчык рәвештә теркәлгән.

Элҗен[19] вакытында карап бирмәкче булып, гүаһлар алдында. Алдым егерме сум акча. Бер пот бал бирмәкче булып унбиш сумга, дәхи калганның, бал бирмәкче булып.

Раслыкына тамгам салдым гүаһлар алдында >III

56

// *(4а кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә 24 нче елда Мамадыш укру[гы]ның Казан губернасының Йөри юлының Иске Авылның Габдеш(?) Габдеррахман угылы алдым алты сум



*Хәмзә Максуд улы дәфтәренең 4а кәгазе*

---

[19] Кулъязмада бу сүз «Энҗел» дип язылган һәм ул ялгыш булса кирәк. Дөресе – «Элҗен» (Илҗин), ягъни православиедәге «Ильин день» бәйрәме көздә тотылган дип фаразладык. Бу бәйрәм 2 август көненә туры килә.

акча имана тугрысына Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан. Өч имана печәнлек басу эче, хакы – ике сум ярым. Калган акчаның тәкабеленә егерме ике пот он бирмәкче булып тамгам салдым Бәһасе утызар тиен.

Янә алдым шул ук Хәмзә агайдан ике сум акча ике ярты йир бирмәкче булып, арыш йире, сачәргә.

Раслыкына тамгам салдым

57

Мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елда Яңа Авылда Губай Сагындык [угылы] алдым Яңа Авылда Хәмзә Максуд [угылын]нан пот ярым он бер ярты [йир] урмакчы булып алдым.

Раслыкына тамгам салдым

58

Мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елда Яңа Авылның Габделхәлил Габдрахман угылы алдым[20] Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан илле грүнкә иске он, бер ярты йир урмакчы булып, арыш йире – киләсе йәйгә.

Раслыкына тамгам салдым гүаһлар алдында

59

Мең дә сигез йөз дә 24 дүртенче елда Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Озын Сач авылының Пәчкә Пәчили угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан дүрт сум акча язгы имана тугрысына. Рамазан аеның унбишенче көнендә шул дүрт сум акчага кайры дөшереп бирмәкче булып, потын егерме бишәр тиенгә.

Әгәр түләй алмасам, җигеп килгән атымны заклат салдым, кара байтал атымны.

Раслыкына тамгам салдым

[20] Кулъязмада бу сүз ялгыш 2 мәртәбә кабатланган.

60

// *(4б кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елда Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Яңа Авылның Миңне... вә Габдеррәхим агай – икесе бер-беремезгә йөкче булып, алдык Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан егерме [бер сум] язгы имана тугрысына.

Шул ук акчаның түрт сумына бер имана йиреме саттым киләсе яңа арыш [йире], ашлык сачәсе. Янә калган уналты сум акчаның вәгъдәсе – сабанга төшкәч түләмәкче булып. Вә һәм бер сум тәкабеленә бер бөтен арыш йире урмакчы булып, һәр икемез тамгамызны салдык үз кулымыз берлән 

Янә пурамызны (ишек алдындагы) саттык, тамгамызны салдык.

61

// *(5а кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә [24 нче елда] мин – Мамадыш укругының Казан губернасының Ыстарый Җүмиески вулусның Двапүл Арташ авылының Галиәкбәр Юлдаш угылы алдым ун сум акча, ике кап бирмәкче булып, Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан.

Ошбу эшемнең раслыкына тамгам салдым 

Мин – Габделмәҗид, Киҗек Тарлауның Галиәкбәрнең каенагасы, ул түләй алмаса, үзем түләмәкче булып тамгам салдым  Кап түләй алмасам, җирән атымны бирмәкче булдым.

Мин Яна Авылның Шәфи Сатый угылы гүаһ булып тамгам салдым 

62

// *(5б кәгазь)* 24 дүртенче елда Җәнәй авылының Питыр Пурис угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан егерме сум акча имана тугрысына. Шул егерме сум акчага саттым җирән байтал атымны.

Раслыкына тамгам салдым гүаһлар алдында 

63

Вә кинә Төбәкнең мин – Мөхәммәдәмин Яңа Авылның Хәмзәдән алдым утыз пот онга акча, яңа арыш онына. Поты егерме бишәр тиен.

Ошбуның раслыкына гүаһ булып мин – Мөхәммәдәмин гүаһ булып, вәгъдәмдә тормакчы булып тамгам салдым.

Вә кинә ошбуның түләмәкче булуына йөкче булып вә һәм гүаһ булып мин – Хәмид Сәгыйд угылы тамгам салдым.

64

Тарих мең дә сигез йөз дә егерме түртенче Мамадыш укругының Киличшинески вулысның Саурыш авылының Җәпим Бәчели угылы алдым сигез сум акча, егерме пот арыш оны бирмәкче булып Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан[21].

Вә янә алты пот бирәсем бар.

Ошбуның раслыкына үз кулым берлә тамгам салдым

Вә янә мин – Түбән Өчнаратның Микипар Ычтапан угылы гүаһ булып тамгам салдым

65

// *(6а кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме түртенче елда мин – Өчнарат авылының Микипар Ычтапан угылы дүрт сум акча алдым, ун по арыш оны бирмәкче [булып] көз көне. Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан.

Вә янә ун грүнкә тоз, алтмыш [тиен].

Ошбуның раслыкына үз кулым берлә тамгам салдым

66

Тарих мең дә сигез йөз дә егерме түртенче елда мин – Мамадыш укругының Киличшинески вулысның Бүлшуй Мишә авылының Садыйк Сагындык угылы алдым унике сум акча, йөз баш мунчалага, иңе – ярты аршын. Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан.

---

[21] «Угылыннан» сүзенең ахыры кулъязмада «ан» тәнвине белән язылган.

Ошбуның раслыкына үз кулым берлә тамгам салдым.

Вә һәм мин Габделкәрим Әпәләй угылы ошбу эшнең раслыкына гүаһ булып тамгам салдым +

67

// *(6б кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче [елда] Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Иске Яңа Авылның Бикмәмәт Әлмәмәт угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан йите сум акчага бер йөз кап сугып бирмәкче булып алдым.

Зөлхиҗҗә аеның унйитенче көнендә.

Раслыкына тамгам салдым +

Һәм дәхи бер йөз кап сугып бирмәкче булып йите сумга тамгам салдым.

Яңа Авылның Рәхим Корбангали угылы гүаһ булдым.

68

Тарих мең дә сигез йөз дә егерме дүртенче елында Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Янәй авылының Ылука угылы Ибан алдым ике тәнкә Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан, ярты умарта бирмәкче булып.

Алды шомырт чәчәгенә төшкән вакытта бирмәкче булып.

Тамгам салдым Ылука угылы Ибан ∧ *[Гарәп язулы имза:]* Ибан.

69

// *(7а кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә егерме бишенче елда Мамадыш укругының Казан өязенең Йөри юлының Керәшен Саурышының Димид Абанас угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан имана тугрысына унбиш сум акча. Көзге иманага җөмәдиәлахыр аеның бишенче көнендә шул унбиш сум акча тугрысына бер умарта бирмәкче булып.

Унбиш сум акчага йите умарта арасыннан сайлап бирмәкче булып, үз кулым берлән тамгам салдым Димид Абанас угылы ⩓

Шул ук Саурышның Димид Абанас угылыннан калды аласы унсигез сум илле тиен.

70

// *(11б кәгазь)* Тарих мең дә сигез йөз дә 25 нче [елда] Мамадыш укругының Казан губернасының Янәй авылының Фәтхулла Минәй угылы алдым Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан алтмыш ике грүнкә бал, агачы берлән.

Түләр вәгъдәсе – урысның Ыспас дигән вакытында түләмәкче булып алдым. Әгәр вагъдәд түләй алмасам, күк алашамны шул вәгъдәденнән соң саттым шул бал тәкабеленә.

Ошбу эшнең раслыкына тамгам салдым гүаһлар алдында

71

Тарих мең дә сигез йөз дә 25 нче [елда] Мамадыш укругының Казан губернасының Иске Авылның Габделҗәлил, Сәйфулла Габдрахман угыл[лар]ы алдык сигез сум акча Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылыннан[22]. Ул акчаның биш сумына бер имана печәнлек, бер имана сабан ашлык йире, бер имана арыш йире егерме алтынчы елны бирмәкче булдык. Вә һәм өч сумына алты пот арыш оны бирмәкче булдык.

Ошбу эшләрнең раслыкына үз кулымыз берлә тамгаларны салдык

***

Бу текстлар Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1047т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Аның гомуми мәгълүматы 41–43 нче саннар белән билгеләнгән язмаларның искәрмәсендә бирелде.

46 нчы санлы язмадагы шәгъбан аеның 15 көне – 15 апрельгә туры килгән. Шул ук язмада һәм аннан соңгы берничә урында теркәлгән Керәшен Саурышы – хәзерге Татарстан Республикасының Теләче районындагы Олы Саурыш авылы.

[22] «Угылыннан» сүзенең ахыры кулъязмада «ан» тәнвине белән язылган.

47 нче язмадагы 3 нче шәүвәл көне 1 июньгә туры килгән.

48 нче язмадагы 14 нче шәүвәл 12 июньгә туры килгән. Шул ук һәм башка язмаларда теркәлгән Төбәк – хәзерге Татарстан Республикасының Саба районындагы авыл.

49 нчы язмадагы 25 нче зөлкагъдә көне 22 июльгә туры килгән.

52 нче язмадагы «крибә» сүзе рус телендәге «крепь» сүзеннән, имана җире мәгънәсендә кулланылган. Шул ук язмадагы Аргы Яңа Авыл – хәзерге Теләче районындагы Олы Мишә авылы.

55 нче санлы язмадагы Иске Авыл – хәзерге Теләче районы территориясендә элек булган, хәзерге вакытка беткән авыл.

57, 58 һәм башка язмаларда «бер ярты җир урмакчы булып» дигәндә имана җиренең иген үскән ярты өлешен уру күздә тотылган.

61 нче санлы язмадагы «Ыстарый Җүмиески вулус» – «Иске Юмья волосте». Иске Юмья – хәзерге Кукмара районындагы удмурт авылы.

Двапүл Арташ – Ике басу Арташ авылы хәзерге Саба районында. Тарлау – шул ук районындагы Язлы Арташ авылы. Кульязмада Тарлау атамасы алдында язылган Киҗек сүзе бәлки Кечек (ягъни, Кече – Кече Тарлау) булгандыр – бу мәсьәлә ачыкланмады.

62, 68 һәм 70 нче язмалардагы «Янәй» – хәзерге Теләче районындагы Җәнәй авылы.

64 нче язмадагы Түбән Өчнарат авылы хәзерге Саба районында.

67 нче язмадагы Иске Яңа Авыл – хәзерге Теләче районындагы Урта Мишә авылы.

69 нчы язмадагы 5 нче җөмәдиәлахыр көне – 1826 елның 22 июленә туры килгән.

70 нче язмадагы «урысның Ыспас дигән вакыты» гыйбарәсендә православие динен тотучыларның август аенда үткәрә торган Спас бәйрәмнәре (барлыгы өч Спас) күздә тотылган.

72 нче язмада күрсәтелгән Кече Шыңар авылы – хәзерге Саба районындагы авыл.

## 72. Өй салу турындагы килешү. 1825 ел.

// *(12а кәгазь)* 1825 елда мартның 21 нче көнендә Кече Шыңарның мин – Мәхмүд Бикбау угылы алдым Яңа Авылның Хәмзәдән йөз сум акча, бер өй ясамак булып: ике кат түшәм, вә кинә унөч рәд буласы ниргәсе, вә кинә тәрәзә вә һәм ишек урыннарын берәр бүрәнә кисәсе, вә кинә югары чормада ишек куясы, вә кинә түбәсен явып, түшәсе такта берлән.

Ошбу өйне ясамакта һәркайсымыз бер иттифакта булып, әүвәл мин – Мәхмүд Бикбау угылы бу бинаны тәмам кыйлмакга тамгам салдым

Янә мин Ишмөхәммәд тамгам салдым

Вә янә мин Төхфәтулла тамгам салдым

Вә кинә бу мәҗлестә хазир булып, мин – Сәлимҗәүһәр мулла Сәмигол угылы язып кулым куйдым.

Озын Сачның мин – Әләкси гүаһ булып тамгам салдым

Вә кинә ошбуның раслыкына гүаһ булып мин – ил имамы мулла Һибәтулла Гайса угылы язып кулым куйдым.

Өч пот ярым бал вә кинә егерме биш тиен акча

***

Текст Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1047т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Аның гомуми мәгълүматы 41–43 нче саннар белән билгеләнгән язмаларның искәрмәсендә бирелде.

## 73. Хезмәтче булып яллану килешүе. 1825 ел.

1825 нче елда дикәбернең 3 нче көнендә Бөгелмә өязе Сәпәй вулусы Әгерҗе авылының ясаклы кемсәнәләрдән Дәүләтшаһ Вәлишаһ угылы вирдем ошбу дугавар язуыны Әсәй авылының имамы мулла Габбас Рахма[н]колый угылына,



*Яллану килешүе*

ни кем шул хосуста – керештем гакъде иҗарә берлән һәр йорт хезмәтләрене вә һәм гайре хезмәтләрне, һич инкяр кыйлмаенча, итәргә. Хакы – йите сум (тәнкә хисабы берлә). Әгәр ошбу хезмәтләрне камил әда кыйла алмасам, артымда агам Әшир Габдеррәхим угылы йөкче булмакы сәбәпле, вәгъдәмез алдагы 26 нчы ел априлнең 20 нче көненчә артык акча алмамыз.

Әшир Габдеррәхим угылы йөкче булып тамгам салдым

Дәүләтшаһ Вәлишаһ угылы хезмәт итмәкче булып тамгам салдым

Хазир гүаһлардан Әгерҗе авылының имам, мулла Мәхмүд Исмәгыйль угылы һәм Фәйзеррахман мулла Мәхмүд угылы.

Гүаһ булып яздым – Әгерҗе авылының указнай имам, учитель Габдеррахман мулла Мәхмүд угылы, Дәүләтшаһ Вәлишаһ угылының үтенүе илән, кулым куйдым.

***

Бу текст 17х17 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер тарафына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Галим, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Закир Кадыйри (1878–1954) архивыннан булган әлеге кульъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «4693т» шифры белән саклана. Аны китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Марс Тукаев 2021 елның сентябрендә тапшырды.

## 74. Алыш-биреш килешүе. 1826 ел.

// *(7а кәгазь)* 1826 сәнә мин Иске Авылның Һибәтулла Габдеррәшид угылы Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылындин алдым сигез сум акча, егерме пот он торгызмакчы булып унбиш көнгә тигрү[23]. Мәзкүр унбиш көндә егерме пот онны бирә алмасам, мәзкүр сигез сумга көрән кашка алашамны бирдем.

Мәзкүр язуның раслыгына мин – Һибәтулла Габдеррәшид угылы тамгам салып вирдем ʌ

Ил имамы мулла Әмир мулла Мәсгуд угылы Һибәтулла Габдеррәшид угылының үтенүе буенча язып кулым куйдым.

***

Текст Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1047т» шифры белән саклана торган кульъязмадан алынды. Аның гомуми мәгълүматы 41–43 нче саннар белән билгеләнгән язмаларның искәрмәсендә бирелде.

## 75. Солыхнамә. 1829 ел.

Копия

1829 нчы сәнә, синтәбернең 30 көнендә Вятка губернасы Уржум округы Буйски вулуснуй праблининең Мазарбашы

[23] Бу сүз кульъязмада «тигрүә» рәвешендә язылган.



*Солыхнамә*

авылының мин – Тимершаһ Сәфәр угылы һәм Шәмседдин Сәгъдеддин угылы һәр икемез бу көнгәчә бөтен алыш-биреш хисапларымызны сөйләшеп тәмам кыйлып, бер-беремез илән бәхилләштек.

Түбәндә язылмыш шаһитлар хозурында көн элгәре бер-беремез илән дәгъва вә низаг кыйлышып, мәхкәмә урыннарына барышып йөрешмәкче булмадык.

Гакылымыз камил вә сихәт вакытымызда һичбер кешенең икраһ вә иҗбарыннан гайре, көлли хакларымны сакыйт кыйлдым мин – мәзкүр Шәмседдин мәзкүр Тимершаһга һәм мин

мәзкүр Тимершаһ мәзкүр Шәмседдингә көлли хакларыны сакыйт кыйлдым.

Ошбуның растлыкына инанмак өчен мин – Тимершаһ Сәфәр угылы кулым куйдым, Шәмседдин Сәгъдеддин угылы кулым куйдым.

Мин Мазарбашыда имамел-мөслимин Фәез мулла Халид угылы гүаһ булып кулым куйдым.

Бән – Халид Колшәриф угылы кулым куйдым.

Гүаһ булып мин – Сәйфулла Исхак угылы кулым куйдым.

Колшәриф Мәмшәриф угылы тамгам салдым.

Ошбу копиягә мәзкүр Тимершаһ һәм Шәмседдиннең илтимасы илән яздым Мөхәммәтхаррас мулла Габдеррәшид угылы.

***

Бу текст 17,5х23 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазе таушалган һәм берничә өлешкә бөкләнгән урыннары тузып, өлешчә ертылган-тишелгән.

Кәгазьнең икенче ягының түбәнге өлешендә, сул як почмагында «Шәмседдин абзый берлә язышкан» дигән сүзләр теркәлгән.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2138т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Альмир Мифтахетдиновтан 2013 елның 1 сентябрендә алынган.

Текст ахырындагы Мәмшәриф исеме Мөхәммәтшәриф дигәннең кыскачасы. Хәзерге Кукмара районындагы Мәмәшир авылының исеме дә татар телендәге элекке архив документларында (мәсәлән, XIX гасыр метрика язмаларында) «Мәмшәриф» дип теркәлгән.

### 76. Хезмәтче булып яллану килешүе. 1833 ел.

// *(9б кәгазь)* Сәнә 1833 нче елда фибралның егерменче

көнендә Мамадыш укругының Җүмйә вулысының Каенсарның Вәлит Моратай угылы (авыл карты) вә һәм Гөлкә Җәким хатыны (анасы)[24] бирде җалга ун сум бәһа берлә үз авылымызның Җәкәү Җәким угылыны мәзкүр числадин түбән априлнең ун көнегәчә хезмәт итмәкче булып.

Мәзкүр вәгъдәмнең раслыгына мин Җәкәү Җәким угылы тамгам салдым

Вә янә Моратай Вәлит угылы тамгам салдым.

Мәхәллә имамы мулла Әмир мулла Мәсгуд угылы гүаһ булдым, язып кулым куйдым.

***

Текст Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1047т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Аның гомуми мәгълүматы 41–43 нче саннар белән билгеләнгән язмаларның искәрмәсендә бирелде.

Язмадагы «җалга» (ялга) сүзе «ялланырга» мәгънәсендә.

## 77–80. Алыш-биреш килешүләре. 1833 ел.

77

// *(7б кәгазь)* 1833 нче елда фибралның 26 нчы көнендә имана тугрысына алдым Габдулла Байки угылы Хәмзә агайдан сигез сум акча. Шул сигез сум акчага сукага ялга кердем.

Әгәр шул сигез сум акчага сука сукалый алмасам, бер атымны саттым шул сигез сумга. Акчаның алты сумына сукага сукаламакчы булдым.

Ошбуның раслыкына тамгам салдым Габдулла Байки угылы гүаһлар алдында

Гайса Сагындык угылы гүаһ булып тамгам салдым

Янә Габдулла Байки угылы ярты имана йиремне сабан ашлыкга бирдем илле тиен акча, гүаһлар алдында тамгам салдым

[24] *анасы* – ягъни, хезмәткә ялланган Җәкәүнең әнисе.

78

// *(7б кәгазь)* 1833 нче елда Сиритни Мишә авылының Габдулла Байки угылы алдым 4 пот он шул ук Яңа Авылның Хәмзә Максуд угылындин. Йөз кырык тиен поты, бары булды биш сум алтмыш тиен. Шул биш [сум] алтмыш тиен тәкабеленә бер сыгыр танасы саттым. Сабан урагы өстендә түләр вәгъдәсе.

Бән – гүаһлар алдында тамгам [салдым] Габдулла Байки угылы 

79

// *(2б кәгазь)* 1833 нче елда хәмәлнең 1 нче көнендә ике пот он алдым Габдулла Байки угылы Хәмзә Максуд угылыннан.

Бәһасе – ике сум кырык тиен. Кырык тиен акчага өч көн утын кисмәкче булдым.

Раслыкына тамгам салдым: Габдулла Байки угылы 

80

// *(8а кәгазь)* 1833 нче елда майның 10 нчы көнендә Сиритни Мишә авылының Камали Сәмигол мулла угылы ун пот он сатып алдым, хакы ун пот – унбиш сум акча. Ике ай вәгъдә илән авылымызның Хәмзә Максуд угылыннан[25].

Биш сум акча бирдем, калды йите пот он тәкабеленә ун пот арыш, вәгъдәсе – ике айдан соң бирмәкче булдым.

Әгәр вәгъдә үтәмәсәм[26], кызыл сыгырымны саттым ун [пот] арыш тугрысына.

Раслыкына гүаһлар алдында тамгам салдым 

Янә бер сум тугрысына бер бөтен ...

Бәхтияр Сәйфулла угылы тамгам салдым 

***

Текстлар Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1047т» шифры белән саклана торган кульъязмадан

---

[25] «Максуд угылыннан» сүзләре кульъязмада «Максудан угылыннан» рәвешендә теркәлгән.

[26] Бу сүз кульъязмада ялгыш «бирсәм» дип теркәлгән.

алынды. Аның гомуми мәгълүматы 41–43 нче саннар белән билгеләнгән язмаларның искәрмәсендә бирелде.

77 нче тексттагы «хәмәл» – март аен, «ялга кердем» гыйбарәсе «ялландым» мәгънәсен белдерә.

## 81. Китап сатып алу турындагы язма. XIX гасыр башы

Ошбу китапны алдым Ачулы авылының мишәр Габделкаюм Габбас угылыннан. Хакы илле алтын.

Ошбуны алмаклыгның раслыкына гүаһ булдым бән – Хисан Сыртлан угылы кулым куйдым.

Ошбуның алмаклыгның ыраслыгына бәгъдә Кәлимулла Кинҗәгол угылы гүаһ булып кулым куйдым. Сараш илүенең юртавай ыстаршина Габдеррәшид угылы камандасының Хәлил авылының.

***

Бу язма 14х10 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына зәңгәр төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазь читләре тетелгән. Бу кәгазь кулъязма китапның тышлыгы өчен кулланылган булган.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «3719т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Татарстанның Кукмара районындагы Манзарас авылында яшәүче Фаяз Сафиннан 1995 елның июнь аенда бу юлларның авторы тарафыннан алынган иде.

Сараш – хәзерге Пермь өлкәсенең Барда районындагы авыл.

Хәлил – хәзерге Башкортстанның берничә районында мондый исемдәге авыллар (Хәлил, Иске Хәлил) бар.

## 82. Вәкаләтнамә. 1835 ел

Сәнәи 1835 нче елда мартның[27] көннәрендә Казан өязенең Суыксу булысының Таршна авылының мин – Хәбибә Гомәр кызы вәкил кылдым дәгъва вә хосумәт хакында үземнең нәфсемә зарарымнан гайрегә – шул ук өязнең Пимәр булысының Өнсә авылының зәүҗем Шәмседдин мулла Максуд угылына, хаким мәндин нә җавап сораса, урынымызга җавап бирмәк өчен.

Мин Хәбибә Гомәр кызы раслыгына кәнди әлем илә галәмәтемне салдым: «кулым».

Шаһитлар: әүвәл – тугма кардәшем Вәлишаһ Гомәр угылы тамгам салдым.

Янә Вәлид Гомәр угылы тамгам салдым.

***

Бу вәкаләтнамә тексты – документның караламасы. Аның берничә урынындагы сүзләре сызылган булуы һәм тамга рәсемнәре төшерелмәгәнлеге шуны белдерә.

Текст 11х13 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазьнең өске өлеше кисеп алынган һәм бер чите янган.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2520т» шифры белән саклана. Ул Казан шәһәрендә яшәүче Айдар Урманчедан (Бакый Урманче коллекциясе) 2017 елның 29 мартында алынган.

## 83. «Минуш бине Мостай васыяте». 1831–1841 еллар арасы

*(7 бит)* Бил-Хаккый вә тәвасу бис-сабри.

Әл-аять: «Әй, кәнү фи әмрид-дөнья тәвасу бил-Хаккъ».

---

[27] Кульязманың бу урынында беренче юлның югары өлешендә өстәп язылган сүзләр булган. Әмма, кәгазе кисеп алынганлыктан, алар билгесез кала.

Вә калә Аллаһу Тәгалә: «Вә лә тәмүтүннә иллә вә әнтум мөслимүн».

Әл-аять: «Вә Һуа әхбарүн мин васыятә Ягъкуб галәйһиссәлам вә инни вусый ли-вәрәсәти би-зәликә әй мөслимән, хәтта әсәәлә мин Аллаһи Тәгалә әмвүтү мөслимән шәһидән вә әсәәлү Аллаһә Тәгалә шәһадәти әүляди вә әзважи вә әхиббаи кә-ма әмәрә галәйһиссәлами фи лүбси әс-сәйабил-җәдиди илбәс җәдидән вә гыйш хәмидән вә мүт шәһидән ли-әннә әд-дәлаләтә әл-хәйри иләл-гайри әгъля дәрәҗатин-нәсыйхәти».

Сүммә үктүб васыяти би-лөгатит-төркийәти йәсһәлү ли-көлли әхәдин әт-тәфәһһүмү би-нәфсиһи лә йәхтаҗү иля тәфсири гайриһи.

Фасыл.

Әй, бәнем нигъмәт җисемем, хисын вә кальгаи динем – хәләл җефетем Маһитаб! Сезгә васыятемдер.

Әгәр бәнгә йийәр нәфәка, эчәр су вә сулур нәфәс бетеп, тәкъдире Сөбхани мөкаддәре әҗәл йитеп бу даре фәнадән вә даре бәкайә сәндин элек нәкыль идәрсәм, бу балаларыбыза вә сезгә – җанымыза мөсавиләрдер. Анларны мәхрүм идеп ташлап китеп, ирә вармагай ирдең.

Әгәр ирә варырсаң, күб вәҗеһләр илән кәнд үзеңдә ноксан вә кимчелек вә үкенечләр вә хәсрәтләр табарсән.

Әүвәл бән сезе тәмам мәхәббәт вә ихласым илән хуш күреп, кичә вә көндезләрдә хезмәтеңә разый улып, хәер-догаларым берлән булдым. Бу эшләр икенче йирдин табыламы йә юкмы? Аллаһу әгъләм, табылмас. (Ирдән калып ирә варанның бәяны Хөснеддин фасылында җийындыр).

Гәрчә байга барсаң, сезгә аның канәгате уламы-юкмы? Әгәрчә мулла кемсәгә барсаң, ул һәмишә ушандак улыр.

Әгәр сән барган кешейә охшарсәң, ул барылмыш кемсә сәнгә охшар исә, артта сәндин аерылып калган балалар сәне көндә биш кәррә егълатырлар. Анлар өчен егъларсән.

Хәер, анларны сән хәтер вә йадеңә алма, әмма ул угланлар сәне күрә барырлар. Анлар сәне күреп егъларлар, сән анлар егъ-

лаган заманда, // *(8 бит)* әгәр башында фәһемең вә кальбеңдә фикер вә гакылың улса – сән егъларсән. Йөзең саргаеп, тәнең сызып, бик агыр сырхау берлән хәстә яткан кешедәй булып калырсән.

Вә икенче вәҗеһ будыр – бер хатын, аның әре вафат улса, ул хатын балалар берлән ул балаларны ул хатын тәрбия кыйлырга шәфкатендин ятимләрнең башыннан гына кул берлән сыйпаеп мәсех итәрсә, рәсүл салләллаһу галәйһи вәссәлләмнән мәрвидер: «Мән мәсәхә раәсә йәтимин кәтәбә Аллаһу ләһү би-көлли шәгърәтин мәррәт галәйһа йадүһү хәсәнәтән вә мәхагатһү би-көлли шәгърәтин сәйэиәтән вә рафәга ләһү би-көлли шәгърәтин дәрәҗәтән фил-җәннәти».

Вә дәхи пәйгамбәр галәйһиссәламнән мәрвидер: «Мән дәммә йәтимән иля тәгамиһи вә шәрабиһи әүҗәбә Аллаһу әл-җәннәтә».

Вә дәхи пәйгамбәр галәйһиссәламнән мәрвидер: «Мән кянә ләһү әүлядүн фә-әддәбәһүм вә әнфәка галәйһим әүҗәбә Аллаһу ләһү әл-җәннәтә».

Нә хушдыр – кәнде үзеңнән тугмыш балаларны әдәп үгрәтеп, анлар үзеңдин соңра йимеш егачларың калыб, фаразан, сезгә һәр көнне бүләк идеп йибәрә торырларса. Әгәр анларны мәхрүм идеп китеп, әдәп-әркян белмәйен калып, анларның сәдакаи җария улмакларыннан мәхрүм улып мәэюс улырсаң, үзең күзеңә ком коеп, күрмәз итмәк кеби улырсән.

Өченче вәҗеһ будыр – бәнем сәнгә һәрдаим догам бу иде: «Аллаһу зөл-фазыл, бу бәнем хәләл җефетемгә нәфсене мөзәкки вә кальбене мосаффа вә рухыны мөнәүвәр әйләп, дөньяви вә охрави морадларны мөяссәр әйләгел» дәю.

Һәрдаим әгъкаб хәмсә әүкат бәгъдендә, кичә вә көндезләрдә, бәлки галәд-дәвам, әмма гайре урыннан бу кадәр ихлас илән хәер-дога буламы? (Валлаһу әгъләм). Бәлки, булмайа. Мәгәр ата вә анадан улса кирәк. Гайредән тизлек үзрә булмая, бәлки, булмас. Мәгәр хәер вә ихсанә кодрәте улан кемсә риясыз ихлас илән, халис Аллаһ өчен сарыф идәрсә, улыр.

Ахирел-әмер, сәнгә васыять шулдыр – угланнар сәне

тәрбияләреннән чыкармасалар, балаларның илән анларның тәрбиясе бер байның тәрбиясеннән әфзаль улыр нәфсә.

Әмма угланнарыма бер васыятемдер ки, бу яшь энкәңезне тәрбияңездән китәреп, аны балаларыннан мәхрүм идәрсәңез, вә әүвәл кәнд үзе ихтыяр идеп тормаса, барчаңыздан разый имәсмән, (*9 бит*) ризалыгым юкдыр.

Фасыл.

Нурдидә Фәхреддингә васыять будыр.

Бәнем бәгъдемдә хәле хәятеңдә, мөмкин кадәре, яшь энкәеңне балалары берлән тәрбия кыйласән! Әгәр ул яшь энкәйнең үзе ул яшь балалары ташлап китмәс ирсә, аны китәрергә, хәйлә илән китсен дәю сәбәп итмә! Кара икмәк вә кара суйа мохтаҗ улмасаң, тәрбияңнән мәхрүм әйләмә! Ул яшь балалар хезмәт иясе улгынча. Әгәр хезмәт иясе улгандин соңра сүзең тыңлап, хезмәтеңдә улсалар, һәмишә шәфкатеңнән мәхрүм әйләмә, белмәгәннәрене үгрәт!

Әгәр һич тә сүзең кабул әйләмәсәләр, анларның эшләрене Аллаһа тапшырырсән. Үзләре белгәнен кыйлалар.

Сәнең анларны кечек заманнарында тәрбияләвең хакыны белмәсәләр, Аллаһ белер – сән худ әҗердән мәхрүм улмазсән.

Вә ләкин анлар[ны] кечек заманда дин белерлек, иман вә ислам вә намаз вә рузә гыйлемнәрене белерлек тәгълим идәсән! Вә дөньяви хезмәтләр дә мәгыйшәт өчен үгрәт. Әгәр мөмкин улурса, сату вә сәүдә белдерергә иҗтиһад идеп, кәнд үзеңезләр яман вә фәсад эшләрдән мәныг идеп, әдәб вә әркян үгрәтеңезләр! Үгрәткәнеңез өчен әҗер вә саваплар алырсызлар. Аллаһу зөл-Мәннан сезләрә дөньяви вә охрави дәрәҗәләр илән миннәт идәр. Вә ул сезләрдән вә сезләрнең сәбәбеңез илән үгрәнән балаларның тәмәезләре улурса, шайәд ки, хәер-догалары берлән вафатларыңыздан соңра Аллаһ кабул идәрсә, Аллаһы Тәгалә каберләреңезе пөрнур идеп, мөнис улып, мәсрүр улырсызлар. Ни хуш шадлык улыр. Әгәр терекләрдән үлекләрә әдна ихсанның савабы ирешдекдә Өхед тагы кеби улып күрелер, имеш.

Вә дәхи бер парә сүзләрдер – ул яшь балаларның өсләренә

киемнән башларына бүрек өсләренә кияр чипкән йә тун эсселеккә пешәрлек вә суыкга өшерлек улмаеп йөрсәләр, кифаядер. Әмма Аллаһы Тәгалә дәүләт виреп, хәлеңез улырса, үзеңез белерсезләр.

Вә дәхи бәнем балаларымнан бер балам бу хәзердә падишаһ хезмәтегә Мифтахеддин кардәшеңез солдатка китеп, дөньяви вә охрави фазыйләтләрдән мәхрүм улып, һәмишә (*10 бит*) кичә вә көндезләрдә хәсрәт эчендә.

Кани гыйлем укымак вә намаз вә рузә вә гайре гыйбадәтләре әда кылмак? Кани аның йигән тәгаме вә киян киеме вә торыр өюе вә аның бергә йөрер юлдашлары?! Аллаһы Тәгалә ул фәкыйрьгә сабры җәмил виреп, ахирел-әмер озын гомер рузи булып, ул шартлардан ихлас улса, яңадан дине ислам юлында гыйлем укып вә гыйбадәтне Аллаһу зөл-фазыл миннәт идеп, тәүбә вә тәүфыйк биргәй.

Һәрничек, кодрәтеңез йиткән кадәре, ул мескенне малыңыздан вә хәер-догаңыздан мәхрүм әйләмәясезләр!

Сән Маһи вә Фәхреддингә васыятемдер – ул Мифтахеддин өчен һәрдаим хәер-догаңыз вә ихсаныңыз илән улып, аның хәлясыне теләясезләр!

Вә дәхи бер парә Әхмәд бала хакында.

Әүвәл Әхмәд, сән Фәхреддингә мөлаемчылык идеп, хуш вә яхшы күрелсәм ирде дәю [тырыш]!

Ул рәсем вә дәстүр вә канунны ригая кыйлыр кеше дәгелдүр. Әмма, андак улса да, бәндин соңра кәнд үзең илән берничә әйям хезмәтеңдә тәҗрибә идеп карарсән. Әгәр сүзеңе кабул итмәйеп, кәнд үзеңә файдасы улмаз улырса, карарсән! Әгәр хәлең киңлек вә иркен улырсаң, бераз нәрсә биреп, башка – тереклек итәр[гә] чыкарырсән. Әмма ул ялгыз чыкып, яшь балалар берлән калсаң, кәнд үзеңне мескен итәрлек итмә! Ул бер кеше – балигъ вә камил, рәшид улган аз берлән дә юнәлтер. Чакка-чук бераз ашарлык, кияр киеме берлән берәр ат бирерсән!

Гайре ни әйтәем? Үзең яшь балалар илән бик мохтаҗлыкка ирешердәй улып калмаясән. Чөнки бәнем, гәрчә малым аз улса

да, һәркаюңызның хакы бар. Гәрчә ул яшь балалар безгә хезмәт итмәделәр, бәндин соңра бәнем малымда анларның хаклары сезнең илән мөсавилардыр.

Вә дәхи ул Мифтахеддин гәрчә бу хәзердә сезләрнең хозурыңызда хазир улмаса да, аның һәм хакы сезләрә мөсавидыр. Бу балаларның хакларыны вә һәм Мифтахеддин хакыны кәнд үзеңнең кулыңда вә тәсаррыфыңда улсын.

Әгәр сән, Фәхреддин, ул малларны, анларның хакларыны батыйль вә фәсад йирә тәсаррыф итмәсәң, дөнья-тереклек өчен бер йирдә улсаңыз, арта вә кисә бән разыем. Сән анларның аталары кеби тәрбиядә мөрәббиләре улдыкың өчен. Ләкин үзләренең яшьлектән егълап йөргәндә, «Әй, балакаем! Ни өчен бихозур улып йөрерсән? Егълама!» – дәю, йомшак сүз илән хушхаль идәрсәң! Бу фәкыйрьнең мәгъмүм вә мәхзүн йөрердекдә мотталигъ улсам, ни (*11 бит*) хуш, шад вә мәсрүр идәрсән. Фәкыйреңдән сезгә пәчәдин мәрахиле фазыйләт хасил улыб, хәер-догалар алырсән.

Бу хосуста язар улсам, сүзем бетәрлек дәгелдер, касыйр иттем.

Фасыл

Әй, сөрүре синә Әхмәд! Сиңа васыять сүзләр аңлагыл – бик раст сүзләремдер[28]...

***

Бу васыятьнамәнең иясе Минуш Мостай улы (1769–1853) – халкыбыз тарихында билгеле муллаларның берсе. Аның турында галим Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә дә язылган[29].

[28] Кульязмада васыятьнамәнең дәвамы юк.

[29] Фәхреддин Р. Асар: мәмләкәтемездә улан ислам галимнәренең вә мәшһүр кемсәләренең тәрҗемә вә табакаләре, тарихе виладәт вә вафатлары вә башка әхвальләре хакында язылмыш китаптыр. 2 җилд, 11 җөзъә. – Оренбург: М.-Фатих Кәримев матбагасы, 1905. – Б. 235–236; Фәхреддин Р. Асар. 2 том / төз. И.Гыймадиев, Р.Миңнуллин, С.Баһавиева. – Казан: «Рухият» нәшр., 2009. – Б. 59–60.

Васыятьнамәнең тексты һәм Минуш мулла нәселенең тарихына бәйле, фәнни яктан бик мөһим язмалар археограф Зәйнәп Максудованың күчермәләрендә сакланган. Алар хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (васыятьнамә – «НМРТ КП 18369/699», 5–7 кәгазьләр; нәсәп язуы – «НМРТ КП 18369/554», 13–17 кәгазьләр).

Васыятьнамә тексты 1960 нчы елларда гомуми дәфтәрнең 7–11 битләрендә шәмәхә төстәге язу карасы белән теркәлгән. Дәфтәрнең тышлыгында «Татар тел тарихын өйрәнүдә 1) Төрле гасырлардагы татар олугларының үләр алдында гаиләсенә язып калдырган васыятьнамәләренең үрнәкләре; 2) төрле ханнарның ярлыглар үрнәге. Җыючы – Зәйнәп Максудова» дип язылган.

Нәсел дәвамчыларының хатирәләренә күрә, Минуш Мостай улының үз кульязма китабын 1930–1940 нчы елларда туганнарыннан берсе алып киткән һәм кайтармаган.

Зәйнәп Максудова 1913–1916 елларда Тәтеш өязенең Түбән Тархан авылында (хәзерге Тәтеш районында) мөгаллимә булып, кызлар укыткан. Шул вакытта Минуш Мостай улының кульязма китапларыннан аның «Нәсәп язуы» дип аталган шәҗәрәләрен һәм нәсел тарихына бәйле мәгълүматларны, шулай ук васыятьнамә текстын күчереп алган. Аннан соңгы чорда Минуш мулланың үз кульязмалары сакланмаса да, аның тарихи текстлары өлешчә З.Максудова күчермәләрендә хәзергәчә килеп ирешкән. Максудова үзендәге элекке мәгълүматларын 1960 нчы елларда яңа дәфтәргә күчереп куйган.

Минуш Мостай улының Зәйнәп Максудова күчергән «Нәсәп язуы»ннан аңлашылганча, васыятьнамәнең автор тексты 1831–1841 еллар арасында язылган булган. Мондый еллар арасын билгеләү өчен васыятьнамәдә улы Мифтахетдиннең солдат хезмәтендә булуы турында язылганы, «Нәсәп язуы»нда аның 1831 елда солдат хезмәтенә китүе әйтелгәне һәм 1841 елда вафат булганлыгы турындагы мәгълүмат игътибарга алынды.

Васыятьнамәнең ахыры юк. Бу, беренчедән, аның «фасыл»-бүлекләргә аерып язылган булуыннан аңлашыла. Чөнки берен-

че фасылында – хатынына багышланган өлешендә «Хөснетдин фасылы» да булганлыгы әйтелгән. Ләкин бу текстта ул юк. Икенчедән, ахырындагы, традицион васыятьнамәләргә хас формаль үзенчәлекләре юк.

Васыятьнамәнең З.Максудова күчереп алган төп текстында кулъязманың соңгы битләре, ихтимал, сакланмаган булгандыр. Югыйсә, калган өлеше дә, һичшиксез, күчерелгән булыр иде.

Тексттагы «арта вә кисә» гыйбарәсен «тулаем, артыгы белән» мәгънәләрендә дип аңладык.

Минуш мулла язмаларында үз нәселләренең Минуштан алып иң борынгы бабаларына кадәрге 37 буынлы шәҗәрә мәгълүматы аеруча кызыклы. (Аңа З.Максудова Минуштан соңгы өч буынны да өстәп, шәҗәрә 40 буынга җиткән). «Нәсәп язуы»нда бу нәселнең әүвәлге бабалары Болгарда яшәгәнлеге, ислам динен кабул итүләре, Болгар җимерелгәч Тау ягына килеп төпләнүләре, Шәмәк, Чирмешән, Олы Тархан авылларында, Оренбург, Казан һәм Буа шәһәрләрендә гомер итүләре, Минуш Мостай улының Яңа Шимбер авылында (хәзерге Татарстанның Әтнә районында) 1793–1812 елларда имам булып торуы, аннан соң Үтәмеш авылында мулла булуы һ.б. язылган. Бу нәселдә борынгыдан алып «мирза» һәм «тархан» титулларына ия бабайлар, гильдияле сәүдәгәрләр, тәрҗемәче, муллалар булган. Рус дәүләте чорында кол (крепостной) крестьяннарга, Идел буенда зур җир биләмәләренә дә ия булганнар.

Тарихи әһәмиятле мәгълүматлары булган «Нәсәп язуы» текстының төп өлеше түбәндәгечә.

// (*14а кәгазь*) «Нәсәп язуы

Минуш бине Мостай бине Исмәгыйль бине Әхмәд (вә ахиһи Рахманкол) ибне Уразлы бине Уразай бине Уразкилде бине Әлмәмәт бине Әлмөхәммәд бине Ишмөхәммәд бине Габделлатыйф бине Габдулла бине Габдерраззак бине Гобәйдулла бине Габделфәез бине Габдеррәхим бине Габбас бине Габдулла бине Гобәйдулла бине Мөхәммәдшәриф мирза бине Габделкәрим бине Әхмәд бине Мөхәммәд бине Әбүбәкер бине Габдеррахман бине Насреддин бине Фәхреддин бине Шәмседдин бине Хәмзә

бине Гали бине Зәйнеддин бине Габдессаттар бине Нәдер бине Бәкри бине Бикәй бине Биктәш Болгари (бине Тукый).

Биктәш карт Болгарда сәхабәләр алдында дине ислама килмеш кемсәдер. Әмма атасы җаһилияттә вафат улмыштыр, Тукый исемле. Бу нәселдән Болгардан Мир Тимер заманында нәселе берлән күчеп киткән Габбас Габдулла угылыдыр, Шәмәк дигән йиргә.

Югарыда мәзкүр Исмәгыйль угылы Исхак (Исхак олуглары икән, солдатка киткән), Мәүлед, Мансур вә Мостай. Бу Мансур бик күп хәлләрне белгән зәки вә агяһ кемсә ирде. Юкарыда мәзкүр нәсәп язуы мәзкүр Әхмәд берлән бертугма Рахманкол Уразлы угылы Рынбурыхта пираватчук булып торган. Ул Рахманколның Рынбурыхта торганда Мәүлед вә Мансур исемле балалар икесе хезмәткә йөргәндә язып биргән. Ул Мәүлед вә Мансур вә Мостай // *(14б кәгазь)* бертугма кардәшләрдер.

Мин – Минуш Мостай угылы Мансур бабаның кулында күреп, андин язып алганмын.

Ул Рахманкол кардәш әйтер икән – безнең ул нәселнең урыс крәстияннәремез күп икән. Татар урысны биләмәсен диян указ[30] булгач киткәннәр. Мәзкүр Рахманкол әйтер икән: Ындыр (Ундыр), Бидәнге, Вәчилефкә, Гәварәвкәләр әүвәл, Идел буе Кәравин, Вишкә[31] безнең йир икән дип әйтер икән. Аның

[30] Бу очракта христиан динендәге коллар тотучы мөселманнар, үзләре чукынмасалар, биләмәләрен һәм крепостнойларын патша карамагына алырга дигән, император Пётр Беренче һәм хөкүмәтнең 1713 һәм 1715 еллардагы карарлары күздә тотылгандыр. Шундый ук карарлар 1729 һәм 1743 елларда да кабатланган. Шул ук Зөя өязенең Макыл (хәзерге Югары Ослан районындагы Татар Макылы) авылы кешесенә 1685 елда биләмәләр һәм коллар бирелгән булып, чукынмаган өчен үзеннән христиан крепостнойлары тартып алыну мисалы (Миннуллин З. Татарские частные акты XVII – первой половины XIX в.: источниковедческая характеристика. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. – С. 124) Минуш мулла язган вакыйгага аваздаш.

[31] *Ундыр, Вишкә* – Идел елгасы буендагы, хәзерге Ульяновск өлкәсенең Ульянов районындагы Ундоры һәм Вышка авыллары. *Бидәнге* – мондый исемдәге авыллар хәерге Ульяновск өлкәсенең Ульянов районында (Бидәнге) һәм Татарстан Республикасының Тәтеш районында (Татар Бидәнгесе) бар.

кадимнән бабалардан калган нәсәп язылган рисаләсе бар икән.

Ул Әхмәд баба шул сәбәпле Тарханга киткән – бу нәселдән Габделкәрим угылы Мөхәммәдшәриф Болгарда бик фазыйль кем ирсә икән вә һәм «мирза» аталмыш кем ирсә икән. Шуның өчен Әхмәд Уразлы угылыны Олуг Тарханда «мирза Әхмәд» диярләр икән. Ул Әхмәдне заманында Олуг Тархандин Пурул[32] дигән урыс авылыгача урман тикшерергә ысмутрител икән. Ахирел-әмер, Пурулдан артларыннан чыкып, анлар ике кемсә икән, икесен дә үлтергәннәр.

Әткәмез Мостай карт баба Исмәгыйльнең вафатында бер яшьтә калган. Әбкәмез карчык Гайшәбикә иргә бармаенча, балаларын тәрбия кылып, вафаты Тарханда улган. Бабамыз Исмәгыйльдән бай калган. Ләкин ул заманда яңы керәшеннәр фетнәсендә замана агыр улып, керәшеннәр иманаларының җизиәләре мөселманнардан әда кылдырганнар[33]. Ул заманда Мәүлед вә Мансур баба икесе кәсеп өчен Рынбурыхта вә Каргалыда йөргәннәр. Күбрәк шул мәзкүр кардәш Рахманкол // (*15а кәгазь)* пираватчүктә торганнар.

Ул әткәйләрнең анасы – әби карчык Гайшәбикә Тарханда Дусай мулланың атасы берлән бертугма кемсәнең кызы икән. Бикчура исемле картның атасы һәм бертугма кардәш икән әбигә. Бу хәбәр ишетә калдым Бикчура угылы Нәдердән вә Мансур бабадан вә һәм Габделваһһаб Габдеррәфыйг угылыдан. Ул Габдеррәфыйг – Дусай мулла нәселедер. Мәкамнәре Тарханда – Даныш мәхәлләсендә кыйбла тарафы башында ирде.

Ул юкарыда мәзкүр Рахманкол илән Әхмәднең аталары Уразлы исемле баба Вулгы Иделенең мәгъриб тарафында Чирмешән суы буенда Чирмешән илендә тереклек иткәннәр. Ул Чирмешән иленә Шәмәк дигән йирдән килгәннәр. Ул Шәмәккә Мир Тимер заманында нәселе берлән күчеп килгәннәр (Габ-

[32] *Пурул* – хәзерге Татарстан Республикасының Буа районындагы Большое Фролово авылы күздә тотылгандыр.

[33] Монда Сенатның чукынган татарлар һәм башка халык вәкилләре өчен чукынмаганнарын салымнар түләргә һәм рекрут бирергә мәҗбүр иткән 1747 елгы карары күздә тотылган.

бас Габдулла угылы). Ул Шәмәк дигән йир Вулгы Иделенең мәгъриб тарафындагы Шәмәк булса кирәк, гайре тарафта Шәмәк йире дәю беленмәйдер, тәварихларда күрелмәйдер.

Ул мәзкүр Уразлы баба Тархан болынына Зүә каласына барып крип ясаткан (Тархан исеменә. Ошбу сүзне нәкыль кылды Олуг Тарханның Минкә Хәбибулла угылыннан, ул ишеткән остазы Сәлимҗан хәзрәттән. Мәзкүр хәзрәт бик мәгълүматлы булган)[34].

Ул мәзкүр Уразлы бабаның ир угланнары Рахманкол, янә Әхмәд, янә Сәед, янә Сиддыкай, янә Мортаза, янә Ильяс. Әмма ул Рахманкол Рынбурых кальгәсендә пираватчүклеккә киткән. Ул Рахманкол төрки вә таҗик вә гарәп вә фарсы вә урыс вә тальян вә гайре лөгатьләрә мәһарәтле ир икән. Шуның сәбәпле кыргыз вә башкорт вә каракалпый лөгатьләренә тәрҗемә өчен соралып алынган, бер лөгатьтән икенче лөгатькә нәкыль ясар өчен.

// (*15б кәгазь*) Әткәй – Мостай карт 1791 нче елда купис булды. Буа кальгасенә күчте купис булып. Казанга күчте 1796 елда. Янә Казандин Буа кальгасенә кайттык купис булып 1810 нчы елда. Янә атай карт – Мостай Исмәгыйль угылы вафат булды 1815 елда, дикабер көннәрендә.

Әткәй Мостай карт вафат булса да, аның купис исеме берлән угланнары Минуш, Муса, Әхтәм, Габдеррәкыйп, единайверный указ куәтенчә, капитал бирдек «купис угланнары» дәю 1822 елгача. Әмма 1823 нче елда капитал агыр улып, бирергә куәт йитмәде, мишәнгә калдык. Душ берлән мешаныскуй падушнай бирдек. 1840 елда чимия аерырга кәгазь бирдек. 41-дә тәмам булды (башка чимия булдык дүрт душ берлән: Әхмәд, Фәхретдин, Хөснетдин берлән үзем (Минуш).

1784(9-?)[35] елда июньнең 12 көнендә гайде фытырның 2 нче көнедә хәләл җефет Гөлзәминәгә никах ителгән икән, иске

[34] Вак хәрефләр белән бирелгән бу өстәмә бүтән каләм белән язылган – З.М.

[35] 1788 нче елда Минуш 20 яшендә булса, 1853 елда үлгән, туган була 1769 елда. 95–96 ел гомер иткән була. – (*З.М. иск.*). 1784(9-?) рәвешендәге дата З.Максудова кулъязмасында шулай теркәлгән.

горрәлектә мәзкүрдер. 1829 сәнәдә рамазан аенда 27-сендә, кадер кичә, вафат улмыштыр. Кәнд үзем Гөлзәминә 20 яшьтә икән никах ителгән яки 19 микән. Бергә гомер итепмез 41 ел микъдары.

1829 сәнәдә июньнең ахыр көннәрендә Маһига[36] никах ителде маһе мөхәррәмнең 4 нче көнедә 3 йөз сум мәһәр илән. Ике йөз хәзер, ләкин бу ике йөзнең бер йөзе кунаклар алдында, сумгадыр. Йола өчен, йөзе мөәҗҗәл. Сабит мулла никах укыды.

// (*16а кәгазь*) Маһи вафат улды 1843 сәнәдә априлнең 24-ндә, шинбә көн, рабигыль-ахирнең 4 көнедә 38 яшендә. Хәләлемез Маһи берлән бергә тереклек итепмез 14 ел фәкать. Дүрт баласы калды: Хөснетдин – 11 яшендә, янә Исмәгыйль – 8 яшендә, янә Хисаметдин – 5 яшендә, Хөсәен – бер яшь ярымда. Маһиның вафаты утыз сигез яшь микъдарыннан хисап итеп фидия бирдек.

Мин – Минуш Мостай угылы Казан губернасы Сары Кукшай өязе Бурис Утар – Яңы Шинбер иленә имам булдым 1793 елда априлнең 10 көнендә. 1812 нче елгача. Ул мәзкүр Шинбердән муллалык тәрек итеп киттем 1812 елда март 25 көнедә.

Сенбер өязе Үтәмеш иленә имам булдым 1812 елда мартның 30 көнедә. Мәзкүр Үтәмештән Өфегә барып, фәтваханәдә имтихан ителеп, указнай мулла булдым. Сенбер өязедә барча мөселман илләрендин выбор алып, имаме җамигъ вә мөхтәсиб мәртәбәсе берлән 1830 ел июньнең 22 көнедә. Өфедә әркиптә[37] 1064 нумерда мәзкүр улса кирәк.

Мифтахеддин (угылы була – *З.М.*) вүлидә 1809 елда. Салдатка бирелде 1831 нче ел март 6 көнедә, җомга көн, 96 набурда. Уралыскидан килеп Сенбердән Житомирга узды 1835 елда,

---

[36]Авторның үз текстында Маһи дип кенә язылган исемнең тулысын З.Максудова Маһисәрвәр булмады микән дип фаразлап, берничә урында «Маһи» исеме янына «(сәрвәр-?)» рәвешендәге өстәмәсе артык. Чөнки васыятьнамәнең башында әлеге исем Маһитаб дип язылган.

[37]*әркип* – архив (*З.М. иск.*).

«Ызбурный» ярминкәсе заман ирде. Вафат булды 1841 нче ел үктәбернең 22 көнедә.

1844 елда мартның 14-сендә, җомга көн, хәләл җефет Гайшәгә никах ителде. ... йөз илле сум мәһәр илән. Вә әмма гарәбия камәр рабигыль-әүвәлнең 12 кичә улган».

Монда әйтелгәннәрнең кыскача бер өлеше «Асар» хезмәтендә Минуш Мостай улы турында язганда кулланылган. Аның турында «Асар»да шулай ук мондый юллар да бар: «... төрле мәсьәләләрдә осталыгы булып, үз кулы белән күп китап вә Кәлям Шәриф язган, күчергән, ләкин язган әсәрләре барысы янгыннарда янып югалып беткән, диләр. Үзе вафат булгач, урынында Хөснеддин исемле улы имам булып калды, аның улы – бүген Самара шәһәрендә имам вә ахун Шиһабеддин әфәнде»[38].

## 84. Хәлегънамә. 1840 ел.

... Бакай авылының мин – хатын кеше Җәмилә ясашнай Атнагол кызы үтенәмен үземнең [ирем булгучы] Таиб Сабит угылыннан утыз сумнык бәдәл тәкабеленә мине хәлегъ кыйл дип. Бәдәле хәлегъне түбәндә зикер ителәчәк гүаһлар хозурында үземнең ихтыярым илән гыйддәт нәфәкамне, кисвәне, ...немне һәм гайре мәкъбуз мәһәремне һәр җәһәттән дагый булгучы дәгъвамны сакыйт кыйлыб, хазире мәҗлесдә гүаһла[р] хозурында үз телем илән үтенеп, бәдәлне биреп мәзкүр шартлар илән мин – мәзкүрә Җәмилә Атнагол кызы хәлегъне үтенүемнең раслыкына, үз кагыйдәмезчә, хатыннар тамгам ⲩ салдым.

Мин – типтәр, Ярмәкнең ыстаршина Габделлатыйф Исмәгыйль угылы камандасы Таиб Сабит угылы мәзкүрә

[38] Фәхреддин Р. Асар. 2 том ..., 2009. – Б. 60. Минуш Мостай улы һәм аның нәселе турында соңгы вакытта мәкаләләр чыкты: Исхаков Н., Исхакова Р. Үтәмеш: беренче мәхәллә тарихы // Безнең мирас. – 2021. – №5. – Б. 44–49; Исхаков Н., Исхакова Р. Үтәмеш: дини хәрәкәт // Безнең мирас. – 2021. – №6. – Б. 55–59.

хатыным Җәмилә Атнагол кызыны мәзкүр шартлар илән хәлегъне үтенүене кабул кыйлдым һәм бәдәле хәлегъне [бу] мәҗлестә кабз кыйлдым һәм ләфзы хәлегъне телемдә ижра кыйлдым. Бәдәлнең затлары – бер кәзәки илән янә [ки]җеле тышлы түшәк, бу шартлар илән хатыным Җәмиләне хәлегъ кыйлуымның раслыкына гүаһ[лар хо]зурында үз кулым илән тамгам ∧ салдым.




*Хәлегънамә*

Гүаһе әүвәл мин – Зәйнулла Зәйнегабдин угылы тамгам + салдым.

Янә Ибраһим Салих угылы тамгам салдым.

Янә Гыйсмәтулла Габделмәҗит угылы тамгам ∨ салдым.

Янә Гыйбадулла Атна[гол у]гылы тамгам ∧ салдым.

Йад ителгән зәүҗиннең үтенүе илән мин – шул ук авылның сабурнай имам вә учитель Мөсәгыйд Габдеррәшид угылы яздым.

[Мәз]күрә Җәмилә кыз баламны берничә хак алып тәрбиягә үземә алдым мәзкүр гүаһлар хозурында.

1840 нчы ел, мартның 4 көнендә.

***

Бу хәлегънамә тексты 17x22 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазьнең бер чите аеруча таушалган һәм дымланып пычранган.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1208т» шифры белән саклана. Китапханәгә Оренбург өлкәсенең Северный районындагы Бакай авылы мәчетеннән 1996 елның 11 апрелендә бу юлларның авторы тарафыннан алынган иде.

Ярмәк – хәзерге Самара өлкәсенең Камышлы районындагы Иске Ярмәк авылы.

## 85. Тәгаллекъ язуы. 1840 ел

1840 нчы елда июльнең 2 нче көнендә Чистай өязенең Мөслимски вулысның Наратлы Елга авылының мин – Мөхәммәдеррәхим Габделгазый угылы телемнән бирдем бу тәгаллекъ язуыны.

Тәнем сәламәт, гакылым сахих заманымда, һичкемнән иҗбар вә икраһ күрмәенчә, үз ихтыярым берлән үземнең тәхте никахымда булгучы Габделмәннан кызы Мөфлихәне бәнем тәхте никахымда булган заманда түрт шарт илән никахландым.

Ул шартларның әүвәлгесе – ата-анасына җәй фасылын-

да бер мәртәбә вә һәм кыш фасылында бер мәртәбә зиярәтенә килтермәк булдым.

Икенче шарты – ул хатыным Мөфлихәне тән каралгыдай сукмак вә иза кыйлмак булмадым. Вә һәм ата-ана ләфзы берлән хәкарәт кыйлып сүкмәк булмадым.

Өченче шарты – ул хатыным Мөфлихәнең каю милкен булса да, үз ихтыярыннан башка, сатмак вә йә рәһен кыйлмак булмадым.

Түртенче шарты – өч көнлек йиргә нәфәкасез куеп китмәгә булмадым.

Әгәр дә бу түрт шартларның каюсына булса да садыйк була алмасам, хатыным Мөфлихә Габделмәннан кызы мәһәре илән бер талакы баин илән талак кыйлдым.

Раслыкына мин Мөхәммәдеррәхим Габделгазый угылы гүаһлар хозурында кәнди әлем илән тамгам салдым.

Фәлән Фәлән угылы гүаһ булып[39]

Мин – Мөфлихә Габделмәннан кызы мәзкүр шартларны хөкеме шәрыгъ үзәрендә ижра кыйлмаклыкга үземнең әткәм Габделмәннан Биктимер угылыны вәкил иттем вә һәм мәзкүр шартлар хосусында хакимнәр хозурында ихтыярымны әткәмгә тапшырдым.

Раслыкына мин – Мөфлихә тамгам урынына галәмәтемне[40] салдым.

***

Бу тәгаллекъ язуының тексты 16,5х21 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача диярлек: кәгазь читләре таушалган.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «4414т» шифры белән саклана. Аны китапханәгә Казан

[39] Кулъязмада бу җөмләнең «тамгам салдым» рәвешендәге дәвамы язылмаган.

[40] Төп чыганакта шулай. Дөресе – «имзам урынына...» тиеш булгандыр. Чөнки «галәмәт» сүзе – «тамга, билге» мәгънәсен белдергән.

шәһәрендә яшәүче тарихчы галим Нурулла Гариф 1999 елда тапшырды.

Наратлы Елга – хәзерге Татарстан Республикасының Чистай районындагы Нарат-Елга авылы.

## 86–88. Китап сату һәм вәкыф итү турындагы язмалар. 1841, 1861, 1862 еллар

86

// *(417а кәгазь)* Бу «Җамигыр-рөмуз» китабы мөтәвәффа мәрхүм мулла Фәйзулла Йосыф угылының ике угылы – Низамеддин илән Фәхреддиннең вә ике кызы – Мәүсуфә илән Зөбәйдәнең милекләредер. Эчендә сиксән алты шикъкасе булыр.

Мин – Низамеддин мәрхүм мулла Фәйзулла угылы ошбу «Җамигыр-рөмуз» китабыны бирдем сатып нәкыд сиксән сум акчаның тәкабеленә агам мулла Мөхәммәдсадыйк мулла Сабкол казый мәрхүм угылына. Әмма шул шарт илән разый булып – бәлки, үземнең бер заманда форсатым булып, мәзкүр 80 сум акчамны биреп алырга, мәгәр минем форсатым булмай, ягъни акчасыны бирергә куәтем йитмәсә, алганыма разый булдым.

1841-дә гыйнварның 6 нчы йаумендә.

87

Мин Мөхәммәдшакир мулла Мөхәммәдсадыйк әл-мәрхүм угылы ошбу «Җамигыр-рөмуз» китабыны кардәшем Низамеддин мулла Фәез угылына кайтарып бирдем 22 сум көмеш тәкабеленә, 1861 нче елда, майның 12-ндә.

Сатып акчасыны алдым 80 сум. Мулла Низамеддин мулла Фәйзулла угылы 1861 нче, май 12-ндә Хәсән мулла Фәйзулла угылына.

Сәнә 1861 нче елда июнь әүвәл көнендә шикъкасе туксан бишдүр.

## 88

// *(28а кәгазь)* Сәнә 1862 нче елда майның егерме икенче көнендә Кар Илендә имам мулла Хәсән мулла Фәйзулла мәрхүм [угылы] үз милкем – ошбу «Җамигыр-рөмуз» китабыны угъланнар Габдулла илән Габдеррахманга вәкыф кыйлдым, сүммә ли-әүлядиһи әз-зөкүри вә ин сәфәлү.

Сихәт вакытымда вәкыф кыйлганлыкымның раслыкына мин – мулла Хәсән мулла Фәйзулла мәрхүм угылы кулым куйдым.

Мулла Хәсән мулла Фәйзулла угылының вәкыф кылганына шаһит булып, мулла Әхмәдишаһ мулла Шәфи угылы кулым куйдым.

«Җамигыр-рөмуз» китабын имам мулла Хәсән мулла Фәйзулла әл-мәрхүмнән Габдулла илә Габдеррахманга вәкыф кыйлып, сүммә ли-әүләдиһи әз-зөкүр вә иннә сәфәлү сихәт вакытымда вәкыф кыйлдым.

***

Бу китапның язмышына бәйле югарыда язылганнарга өстәмә рәвешендә мондый юллары да бар: «Сәнә 1867 нче елда авыстның 31 нче көнендә эткәмез мулла Хәсән мулла Фәйзулла мәрхүм угылы гүр иясе булды. Хода Тәгалә иманыны юлдаш әйләп, оҗмах әһеленнән кыйлгай иде, амин, би-хөрмәти сәйидил-мөрсәлин» *(417а кәгазь)*.

Ияләренең язмалары теркәлгән бу китап Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «58г(50)» шифры белән саклана. Аның төп тексты 1791 елда Фәйзулла Йосыф улы тарафыннан күчерелгән.

Кулъязма истәлекнең кыскача мәгълүматы бу китапта 36 нчы сан белән урын алган текст искәрмәсендә язылды. Китапны сату-алу турындагы югарыда китерелгән өзекләре көрән һәм кара төсләрдәге язу каралары белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

Кар Иле – хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районындагы Кариле авылы.

Кулъязма китапны күчергән Фәйзулла Йосыф улы Кариле

авылында XIX гасыр башында ук имамлык иткән, аннан соң 1832 елдан аның улы Хәсән, 1866 елдан Хәсәннең улы Габдулла, ул вафат булгач аның улы Габдерәүф 1905 елдан 1920 еллар ахырына кадәр имамлык вазифасын башкарган[41].

Сабкол казый – татар тарихында мәгълүм шәхес Сафкол Котый улы (1755–1833). Аның Килмәк исемле бабасы Кырым татары булган, патша Пётр I алып барган сугышта әсирлеккә төшкән һәм Казан артында гомер иткән. Сафкол – Олы Мәңгәр авылында (хәзерге Әтнә районында) мулла булган һәм 1796 елда Уфадагы Диния Нәзарәтенә казый итеп сайланган. Бу шәхес турында татар галимнәренең хезмәтләрендә мәгълүматлар бар[42].

## 89. Ат сату турындагы язма. 1849 ел.

// *(68б кәгазь)* 1849 нчы елында Казан губернасының Мамадыш өязе Олыязыски булусның Ыстарый Мәкчемески уп[шы]стваның Нувай Гурелый Йелник авылының Сибгатулла мулла Таһир угылы саттым ... туган бер җирән ат – ялы уңда, уң колагы ярган, борын өсте ак, башка примитлары юк.

Саттым шул ук Казан губернасы Мамадыш өязенең Казанчы авылының ... Хәмид угылына.

---

[41] Мөхәммәтшин Г. Балтач мәчетләре: үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2018. – Б. 115–116. Бу китаптагы Хәсән Фәйзулла улының вафат булган вакыты 1867 елның 18 октябрендә диелгән (115 бит) дата югарыда язылганга туры килми.

[42] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Кыскартып төзелде / төз. Ә.Хәйруллин. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б. 306; Фәхреддин Р. Асар: мәмләкәтемездә улан ислам галимнәренең вә мәшһүр кемсәләренең тәрҗемә вә табакаләре, тарихе виладәт вә вафатлары вә башка әхвальләре хакында язылмыш китаптыр. Беренче җилд, алтынчы җөзъэ. – Оренбург: М.-Ф.Г.Кәримев матбагасы, 1904. – Б. 297–299; Фәхреддин Р. Асар. 1 том / төз. Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: «Рухият» нәшр., 2006. – Б. 139; Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз.: Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 165. Шуны искәртү мөһим: Р.Фәхретдин хезмәтенең ике басмасында да (1904, 2006) Сафколның бабасы Кырымнан XVI гасыр ахырында килгән дип ялгыш басылган, дөресе – Пётр патша чорында икәнлеге – Г.Рәхим китабында язылган.

// *(69а кәгазь)* Ырастлыкына әүвәл мин гуаһ ... Йөзәй Мансур угылы тамгам салдым 

Кинә Әхмәди Бикчәнтәй угылы тамгам.

Йосыф Йөзәй угылы тамгам 

Сатканлыкымның ырастлыкына мин Нувай Гурелый Йелник авылының Сибгатулла мулла Таһир угылы язып кулым куйдым.

***

Бу сату-алу язмасы гарәп һәм фарсы телләрендәге берничә әсәр бергә төпләнгән кульязма җыентык эчендә сыек көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазьләренең читләре таушалган, язуы уңган, Әхмәди Бикчәнтәй улының тамга рәсеме күренми.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «382г(319)» шифры белән саклана. Аның төп тексты XIX гасыр башында күчереп язылган, кәгазенең филигранендә: «1816» ел билгеләнгән. Зурлыгы 10х16,5 см, күләме 72 кәгазьдән гыйбарәт.

Бу китап Милли китапханәгә Татарстан Республикасының Саба районы Иске Икшермә авылында яшәүче Рәшидә Хатыйповадан 1994 елның август аенда бу юлларның авторы, китапханә хезмәткәрләре Ирек Һадиев һәм Айрат Заһидуллин тарафыннан алынган иде.

Документта телгә алынган Олыяз, Иске Мәкчем, Новый Горелый Ельник (Яңа Мәкчем) авыллары хәзерге Татарстан Республикасының Мамадыш районы территориясенә нисбәтле. Иске Мәкчем – хәзер Ямаш исеме белән, Новый Горелый Ельник – Вахит исеме белән йөртелә. Казанчы – хәзерге Саба районындагы Казанчы-Бигәнәй авылы булса кирәк.

## 90. Китап сатып алу турындагы язма. 1863 ел.

1863 нче елда июльнең 16 нчы көнендә Шәрәфеддин бине Мөхәммәдсадыйк әл-Бакырчый ошбу ярты «Шәрхе мулла» ки-

табыны гакъде сахих илә Камаледдин бине мулла Габделҗаббар әл-Чынлывидан сатып алдым. Бәһасе – 4 сум 50 тиен.

Сихәт гакъдемездә шөһуд: Мөхәммәдзакир Әхсән угылы, мулла Фазлый Хәбибулла угылы, мулла Н... мулла Фәхреддин угылы.

Аллаһ хәерле кыйлып, истифадә вә ифадә насыйп иткәй иде.

***

«Шәрхе мулла» исемле, гарәп телендәге кулъязма китапның төп тексты 1859 елда Буа авылында Габделвахид бине Габдеррахман бине Колый мәдрәсәсендә Шаһи бине Садыйк бине Бохарай тарафыннан 1859 елда күчерелгән.

Бу китап Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «152г(124)» шифры белән саклана. Зурлыгы – 16,5х20 см, күләме – 39 кәгазьдән гыйбарәт. Ул китапханәгә Казан шәһәрендәге «Мәрҗани» мәчетеннән 1996 елның 26 мартында алынган иде.

Сату-алу турындагы текст 39б кәгазендә кара төстәге язу карасы белән, гарәп яузының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Саклнышы канәгатьләнерлек.

## 91. Тәхарежнамә. 1864 ел.

// *(4б кәгазь)* 1864 нче елда синтәбернең 3 нче көнендә Казан өязенең Олуг Әтнәнең Шәмседдин Гомәр угылының варислары Мөхәммәдкәрим Шәмседдин угылы, Нигъмәтҗан Шәмседдин угылы вә сәлбия кызлары Хөснихамал вә Бибифатыйма Шәмседдин мәрхүм кызлары әткәмез Шәмседдин мәрхүмнән мәтрүкә булып калган Казанның Яңа Бистәсендә Иске Олуг таш мәсҗид мәхәлләсендә икенче Олуг урамның забутка киткән тыкрык башында улгучы йорт вә йиремездән агамыз Нәҗмеддин Шәмседдин угылыннан түбәндә кул куйгучы шаһитлар хозурында, муафыйкы шәргы шәриф, тәхареж кыйлыштык бу рәвешчә кем.


تخارج نامه

ЦѢНА 20 КОП. СЕР.

Тәхарeҗнамә

Мин – Мөхәммәдкәрим Шәмседдин угылы солых кыйлып, мин бәгъдәсенә дәгъва вә хосумәт булмаслык шарты илән тәхареҗ булдым мәзкүр эткәмезнең йиредән хисса алып бу рәвешчә кем – эткәмездән калган йорт урыныдан түбән 2-шаржин ярым калгандин соң, литсә тарафыдан ун шаржин итеп алып, түр тарафы 12 шаржин – Казан мишәне Йосыф Хөсәен угылының чигенә тоташкан, хәзердә (ягъни, бу тәхареҗ язуыны язган вакытта) ошбу мин – Мөхәммәдкәримга булган йирдә Казан өязенең Әлдермеш авылының Нигъмәтҗан Нурмөхәммәд угылының йорты бар. Ул Нигъмәтҗан минем йиремдә буладыр. Мин бәгъдәсенә мин хуҗа булдым, калган өҗрәсене аларга булды.

Имди ошбу тәхареҗне язган мәҗлестә гакъде тәхареҗ кыйлышып, иҗабе кабул кыйлыштык. Вә кинә мин бәгъдәсенә дәгъва булмасын өчен мәхәллә имамы Хөсәен мулла Әмирхан угылыдан ярбавай кәгазь илән язышып, кулларымызны куйдык.

Бу тәхареҗга разый булып бән – Нәҗмеддин Шәмседдин угылы кулым куйдым.

Бу тәхареҗга разый булып бән – Мөхәммәдкәрим Шәмседдин угылы кулым куйдым.

Кәримгә өч буй коймасы илән литсәдәгы булды.

// *(3а кәгазь)* Вә кинә Мөхәммәдкәрим Шәмседдин угылыдан түбән каладыр 13 шаржин. Ошбу 13 шаржиннан литсә тарафы 6 ярым, түр тарафы 12 шаржин итеп алып, мин – Нигъмәтҗан Шәмседдин угылы тәхареҗ кыйлып, гакыд кыйлыштык.

Әмма мин – Хөсниҗамал Шәмседдин кызы мәзкүр Нигъмәтҗаннан түбән литсә тарафын 3 шаржин чарик итеп, түр тарафын 12 шаржин итеп алып, тәхареҗ булып гакыд кыйлдым.

Әмма мин – Бибифатыйма Шәмседдин кызы Хөсниҗамал Шәмседдин кызыдан түбән литсә тарафын 3 шаржин чәрек, түр тарафын 12 шаржин итеп алып, тәхареҗ булып гакыд кыйлдык.

Имди бу тәхареҗга һәркаюмыз разый улып, тәхареҗнамәга кулларымызны куйдык.

Бу тәхарежнамәга мин – Нәҗмеддин Шәмседдин угылы кулым куйдым[43].

Бу тәхарежнамәга мин – Нигъмәтҗан Шәмседдин мәрхүм угылы кулым куйдым.

Бу тәхарежнамәга Хөснижамал Шәмседдин кызы кулым куйд[ым].

Бу тәхарежнамәга Бибифатыйма Шәмседдин кызы язу белмәгәнлеге өчен мин – хәләле Җиһаншаһ Ягъкуб угылы Яушев кулым куйдым.

Мәҗлестә улгучы шаһитлар:

Казан мишәне Йосыф Ягъкуб угылы кулым куйдым.

Казан мишәне Шаһингәрәй Бикмәмәт(?) угылының язу белмәгәнлеге өчен Хөсәен мулла Әмирхан угылы кулым куйдым.

Бу тәхарежгә мин – гүаһ булып, Җиһаншаһ Ягъкуб угылы Яушев кулым куйдым.

Яңа Бистәдә үз йорты берлән торгучы Корбангали Баязит угылы кулым куйдым.

Бу тәхарежне мин – Яңа Бистәдә Иске Таш мәсҗид мәхәлләсендә указной имам мулла Хөсәен мулла Әмирхан угылы кулым куйдым.

***

Текст 22х36 см. зурлыгындагы бер кәгазьнең ике ягына кара һәм өлешчә көрән төстәге язу каралары белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

Кульязма Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә «818т» шифры белән (галим Каюм Насыйри кульязмалары арасында) саклана. Сакланышы уртача: кәгазьнең бер чите ертылган, берничә сүзгә язу карасы тамган.

---

[43] Кульязманың бу урынында коймалар турында ике юл текст вак хәрефләр белән язылып, сызылган.

Тексттагы «шаржин» – сажин сүзенең бозылган варианты, «литсә тарафы» – алгы ягы (рус телендәге «лицевая» сүзеннән).

Олуг Әтнә – хәзерге Татарстан Республикасының Әтнә районы үзәге – Олы Әтнә авылы.

Әлдермеш – Биектау районындагы авыл.

## 92. Мирас бүлү турындагы язма. 1870 ел.

// *(1б кәгазь)* 1870 нче елда синтәбернең 8 нче көнендә Уржум өязе Төрек вулысы Күкнур-Алашайка авылының Сәйфетдин Салих угылының угланнары – түрт угыл: Фазылҗан, янә Галим, янә Сәлим, янә Мостафа.

Түрт угылдан Фазылҗан берлә Сәлим солых берлә, гүаһлар алдында тәхареҗ кылдылар.

Ашлыктан унбер арба арыш алды. Янә бер богыл печән. Янә сабан ашлыктан өч арба солы. Янә бер чана. Янә бер тырма. Янә сука (кашыгы берлә). Янә урмандагы бүрәнә, янә йортта биш бүрәнә.

Тушы язган нәрсәләр Фазылҗан берлә Сәлимгә. Янә калганы Галим берлә Мостафага һәм әнкәсенә булды.

// *(2а кәгазь)* Мин – Сәфәргали Вәли угылы гүаһ булып кулым куйдым.

Мин – Муллахмәд Баязид угылы гүаһ булып тамгам салдым

Мин – Гыйззәтулла Рәхмәтулла угылы гүаһ булып тамгам салдым

Мин – Гыйльван Сиддыйк угылы гүаһ булып тамгам салдым

Мин – Вәли Госман угылы гүаһ булып тамгам салдым

Мин – Галим Госман угылы гүаһ булып кулым куйдым.

Мин – Мифтахеддин Бикчәнтәй угылы гүаһ булып [тамгам салдым][44]

Мин Хуҗахмәд Бикчәнтәй угылы гүаһ булып кулым куйдым.

[44] Кулъязмада тамга рәсеме күренми.

Мин – Дәмин Мөхәммәдшәриф угылы гүаһ булып тамгам салдым 

Мин – Гаделшаһ Нури угылы, сутнук, гүаһ булып тамгам салдым 

Мин – ыстараста Вәли Хөсәен угылы гүаһ булып тамгам салдым[45].

Мин – Фазылҗан Сәйфи угылы юка[ры]дагы[46] риза булып тамгам салдым 

Мин – Галим Сәйфи угылы растлыгына тамгам салдым 

Мин – Мостафа Сәйфи угылы гүаһ булып тамгам салдым 

***

Текст 17х22 см. зурлыгындагы ике кәгазьгә кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача: кәгазьләрнең читләре гөмбәчектән зарарланган һәм кайбер сүзләре танылып бетми.

Кулъязма Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «4355т» шифры белән саклана. Ул Казан дәүләт университетының 1984 елгы археографик экспедициясе вакытында Мари АССРның Бәрәңге районындагы Мазарбаш авылында Мәнфүсә Гайнетдиновадан алынган. Үзебездән өстәп, тагын шуны да искәртергә кирәк, әлеге археографик экспедициядә М.Гайнетдиновадан бик күп кулъязма истәлекләр алынган һәм алар арасында хосусый актлар шактый.

Күкнур-Алашайка – хәзерге Мари Республикасының Бәрәңге районындагы Мазарбаш исеме белән дә билгеле авыл.

---

[45] Кулъязмада тамга куелмаган.

[46] Төп чыганакның бу урынында бер сүз (мәсәлән, «язылганнарга») төшеп калган.

## 93. Солыхнамә. 1871 ел.

Сәнә 1871 нче миладия гакрәб 3 нче йаумендә кәнди ризасы вә хөсне ихтыяры берлә мөсаләхә кылды тол хатын Хәбибелҗамал бинте Әхмәд үзенең ибне әхи Габделвәли бине Мөхәммәд берлә шул хосуста кем, мәрхүм эткәсе Казан сәүдәгәре Әхмәд бине Габдеррәшидтән калган йорт вә гайре тәрикәседән тиячәк хиссаи ирсия дәгъвасыннан мәзкүр ибне әхи Габделвәли бине Мөхәммәдтән йөз сум тәнкә алды.




*Ш.Мәрҗани кулы белән язылган солыхнамә*

1860 сәнә Урынбургский духаунай сабранияга биргән гаризасы вә аннан башка һәркайсы мәхкәмәләргә биргән кәгазьләрендә мәзкүр дәгъва вә хокукыннан кичеп ибраэ кылды.

Вә мин бәгъдә тәрикә вә гайре тәрикә хосусында мәзкүр Габделвәли ибне Мөхәммәдтә вә Мөхәммәд бине Әхмәднең аннан гайре вәрәсәләрендә һичбер вәҗеһдән хак вә дәгъвам калмады дәю, вә мин бәгъдә миннән дәгъва вә хосумәт садир булмас. Вә, билфараз, садир булса, мәрдүд вә нәфир мәсмуг булсын дәю икърар кылып, гаһед вә тәэкид кылды.

Шөһуде годуль хозурында мәзкүрә Хәбибелҗамал бинте Әхмәд кулын куйды вә һәр сәнә бирә торган дәстүр авыл җиреннән хиссамны вәли бирер: Хәбибҗамал Әхмәд кызы кулым куйдым.

Шаһит булып кулым куйдым – мөәзин Сәгыйдь бине Халид.

Чар өязе Кече Битаман карьясенең Хәлил ибне Әхмәр кулым куйдым.

Казан мишчаны Габделвәли Мөхәммәд угылы.

***

Текст 18х22 см. зурлыгындагы куш битле кәгазьнең бер ягында караңгы көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Текстның үзендә кем тарафыннан язылганлыгы күрсәтелмәсә дә, аның Казан имамы һәм мәшһүр галим Шиһабетдин Мәрҗани тарафыннан теркәлгән булуы бәхәссез. Бу, беренчедән, кульъязма өслүбеннән аңлашылса, икенчедән, әлеге документ Ш.Мәрҗанинең башка кульъязмалары белән бергә галимнең үз варисларыннан алынган булуы белән раслана.

Кульъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «961т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Даниял Әмирхановтан 1998 елның 12 октябрендә бу юлларның авторы тарафыннан алынды.

Текстта язылган 3 нче гакрәб көне 25 октябрьгә туры килгән.

Урынбургский духаунай сабрания – Оренбургское духовное собрание.

Кече Битаман – хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районындагы авыл.

## 94. Китап сатып алу турындагы язма. 1874 ел.

1874 нче сәнәдә без ки, түбәндә язылачак Казан губернасы Тәтеш өязе Балтай вулысы Коллар авылының мулла Әдһәм угылы Габделвәли Гобәйдулла угылы Габдессәламдин унсигез тәнкәгә бер «Казыйхан», сигез тәнкәгә бер «Әхтәри кәбир», ике ярым тәнкәгә бер «Нәвадире Сөһәйли» китабы алганлыгымның раслыгына унбишенче майда кулым куйдым.

***

Текст 18х22,5 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Кулъязма Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә «240д» шифры белән саклана.

Коллар – хәзерге Татарстан Республикасының Апас районындагы Кызыл Тау авылы.

## 95. Китап сатып алу турындагы язма. 1876 ел.

1876 нчы елда ошбу «Шәмсия» китабыны алдым мин – Мөхәммәд хаҗи вәләде Габделфәттах Олугязывый, бер сум утыз биш тиен акча бәрабәренә, Сәрдә авылының Исмәгыйль мулла Габделвәли угылыннан.

Аллаһы Тәгалә гыйльме нафигъ мөяссәр әйләсен.

Ошбуны сатканлыкымның раслыгына мин Исмәгыйль мулла Габделвәли угылы кулым куйдым.

***

Текст 16,5х24,7 см. зурлыгындагы, гомуми күләме 196 кәгазьдән торган кулъязма китапның 196а кәгазендә кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Китапның төп тексты – Сәгъдетдин Тәфтазанинең «Китабе шәрхеш-шәмсия» исемле, гарәп телендәге әсәре XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән, кәгазендәге су билгесендә «1823» дигән датасы бар. Әлеге кулъязма Татарстан Республикасының Милли музеенда З.Максудова фондында саклана.

Сәрдә – мондый исемдәге авыллар хәзерге Татарстан Республикасының Арча, Әтнә һәм Саба районнарында берничә (Урта Сәрдә, Югары Сәрдә, Сәрдә һ.б.).

Бу китап хакында мәгълүмат һәм аны сату-алу турындагы язманың фоторәсеме, шулай ук аның гарәп хәрефләрендәге һәм хәзерге татар телендәге тексты басылган: Бустанов А. Библиотека Зайнап Максудовой = Зәйнәп Максудова китапханәсе. – Мәскәү, 2019. – С. 252–253. Тик әлеге китапта текст бирелешендә кайбер хаталар бар. Мәсәлән, «Олугязывый» сүзе «Олуг язды» һәм «олыг язуы», «Сәрдә» атамасы «Сарда», «мөяссәр әйләсен» сүзтезмәсе «бирсен», «сатканлыкымның» сүзе «сатлыгымның» дип басылган.

## 96. Милек васыяте. 1877 ел.

// *(2а кәгазь)* 1877 нче елда 6 нчы фибралда Уржум өязе Төрек вулысы Күкнур-Алашайка иленең мин – падишаһ хезмәтендә улгучы солдат Насыйрҗан Рәхмәтулла угылы үземнең тәхте милкемдә улгучы мал вә әмлякләремнән вә каралтыларымнан көллисене, еллар хәвефле улып, үземезнең тынычлык илән сәбат вә карарымыз улмаганлыгы сәбәпле, нагяһ үземез хезмәткә чакыртыла калсак, соңы көн мал вә әмлякләрем тәләф улмасын өчен угылым Сабирҗан илән вә кызым Бибисәидәгә һәрбер малларымны исемләп яздырдым.

Вә әгәр Ходай Гыйззе вә Җәлләдән вакыт йитеп, тәкъдире

Илаһи буенча вафат улсам, җәмәгатем Шәмсеҗамал Мөхәммәдәмин кызы мәзкүр угылым вә кызымны тәрбия кылып, үзе ихтыяры илән торса, каһрән вә җәбрән чыкармасыннар. Шул йортта бергә балалар илән тәрбияләнеп тор[ыр]. Әмма үзе ихтыяр кыйлып чыкып китсә, исемләнмеш мал вә әмлякләремнән шәрган тиешле сәмән хакыны биреп чыкарылсын.

Әмма ма бәкъи минәс-сәмән, мал вә әмлякләремнең көллисене мәзкүр угылым Сабирҗан, кызым Бибисәидәгә бирелеп, балигъ вә балига улганча, би-муафыйкан шәрыг вә канун, яхшы мәсҗид картлары бер яхшы вә имин булган кешене тәгаен итеп вә эпикүн итеп куелсын.

Вә дәхи мәгълүм улынадыр – Ходай Гыйззе вә Җәлл һәркаюмыз[га] хәерле шатлык вә тынычлык гомерләр насыйп итсен!

Мәсҗид картларына гозеремездер – вә әгәр тәкъдире Илаһи буенча вафат улсам, вафатым мәгълүм булган соңында балаларымны яхшы тәрбия кыйлып, ормай вә сукмай вә эрәнҗетмәй торган бер яхшы вә юаш вә рәхимле бәндә тугры килеп, йортка кермәк улса һәм җәмәгатем шуны кабул итсә, кертеңезләр дәю үтендем.

Мал вә әмлякләремнән булган әүвәл – ак өю, дәхи көртелгән(?) яңа өю, дәхи түбән кара өю, дәхи келәт – кара өю каршысында, дәхи тупсалы капка, коймалар илән, ике торык абзар, // (*1б кәгазь*) дәхи байтал ат, дәхи сыгыр, өч баш сарык, дәхи бер үгез, дәхи бер яңа кайры сипкән тун, дәхи бер көрән чикмән, дәхи бер кәзәки, дәхи бер карманнай сәгать, дәхи биш буйлы чылбыр, фарзумит якалы[47], дәхи сука (тимерләре вә кашыгы илән), дәхи бүрек. Янә арба, янә самавыр, янә түшәк. Дәхи бер имана җир уҗым – ике төштә. Дәхи алты пот керешле – Сәфәргали Мөсәгыйдь угылыннан алдым бер җир, янә ал-

[47] Төп чыганакның бу урынында «чикмән» яисә башка өс киемен белдергән сүз язылмыйча калган. *Фарзумит* – кием-салымны бизәү өчен кулланылган ука; рус телендәге «позумент» сүзе.

дым Гыйззәтулла Хәбибулла угылыннан 4 пот керешле җир, янә Насыйрҗан Хәбибулла угылыннан алдым ике җир (ун пот керде), янә «Кесәл» Шәмседдиннән алдым 4 пот керешле җир алдым. Бар да 76 нчы елда алынды. Бар уҗымым йиде төштә, янә унбер арба орлыклык солы, бер яхшы камыт (бавы илән).

Ошбу шаһитлар алдында мин – силыски ыстарыстага мәгълүм улынды.

Әүвәл Гайнеддин Сәйфеддин угылы гүаһ улып кулым куйдым.

Хуҗахмәт Бикчәнтәй угылы кулым, гүаһ булып кулым куйдым.

Сибгатулла Фәтхулла угылы гүаһ улып кулым куйдым.

Сәйфетдин Вәлит угылы тамгам салдым

Гаделшаһ Тимербулат угылы гүаһ улып[48]

Әхмәдҗан Габделхаликъ угылы гүаһ улып

Нарятчик Фәезхан Фазыл [угылы] гүаһ улып тамгам

Ибраһим Хөсәен угылы гүаһ улып тамгам

// (*1а кәгазь*) Гайнеддин Вәлит угылы гүаһ улып тамгам

Батырша Халит угылы гүаһ улып кулым куйдым.

Тимершаһ Хөсәен угылы гүаһ улып тамгам

Сәлимҗан Сәйфелмөлек угылы гүаһ улып тамгам

Мөхәммәди Мөхәммәдрәхим угылы гүаһ улып тамгам

Андин мин силски ыстарыста Таҗәхмәд Хәмит угылы ошбу язылган язуга гүаһ улып пичәтем бастым.

[*Түгәрәк мөһер:*] «Печать сельского старосты Алгайско-го(?) общества».

***

Текст 18х22 см. зурлыгындагы өч кәгазьгә көрән һәм кара төсләрдәге язу каралары белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Кульязма Казан (Идел буе) федераль университетының

[48] Бу һәм моннан соңгы юлның җөмлә ахырлары язылып бетмәгән һәм тамгалары куелмаган.

Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә «449д» шифры белән саклана.

Васыять язмасының авторы – запастагы солдат «еллар хәвефле» булуын искәрткәндә Россия һәм Госманлы-төрек империяләре арасында 1875 елдан башланган гаять киеренке мөнәсәбәтләр һәм зур сугыш чыгу куркынычы күздә тотылган. Сугыш 1877 елның апрель аенда башланып, 1878 елның февралендә тәгалләнгән.

Тексттагы «сипкән тун» дигәндә киелгән, таушалган мәгънәсе күздә тотылган. «Әпикун» сүзе – опекун. Шәмсетдин исеменә нисбәт ителгән «Кесәл» сүзен кушамат дип аңладык. «Нарятчик» – нинди дә булса эш өчен җаваплы кеше; рус телендәге «нарядчик» сүзе.

## 97. Җир сату турындагы язма.
## 1886 ел.

Мең дә сигез йөз дә сиксән алтынчы елда Мамадыш өязе Елыш булысы Тө[бәк] авылының мин Галикәй Мортаза угылы саттым өч төштә арыш йире: пирвай – Мулла аланы юл аркылы «аражуб»(?) аша, бер яны – Гайнулла яны, икенчесе – Зәйнетдин, Чүннек яны, Гыйззәт яны, өченчесе – Мөскәйдә Сибгать яны. Бәһасе – дүрт сум көмеш.

Раслыкына мин – Галикәй Мортаза угылы үз кулым берлә тамга салдым.

Ишмөхәммәт Бикмөхәммәт угылы тамга салдым.

Мәннаф Ваһһаб угылы тамгам салдым.

Гайнулла Хәбибулла угылы тамгам салдым.

Әпте булысы Кибәче авылының мин Шәрәфетдин Ваһһаб угылы алдым Галикәй Мортаза угылыннан.

Силски ыстараста Гыйлаҗетдин Мифтахетдин угылы пичәт бастым: «Печать Стар. Тюбякского общ. Елышевск. волости».

***

Бу документ тексты 18х22,5 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача. Текстта тамгалар куелмаган.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2055т» шифры белән саклана. Аны китапханәгә Казан дәүләт университеты доценты Фәнүзә Нуриева тапшырды.

Төбәк – хәзерге Татарстан Республикасының Саба районындагы авыл. Кибәче – шул ук районндагы Олы яки Кече Кибәче авылларының берсе.

Әпте – хәзерге Теләче районындагы Әбде авылы.

## 98. Мөхәммәтшакир Мусин васыятьнамәсе. 1886 ел.

// *(1б кәгазь)* Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.

Әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин вәссаләте вәссәлләм галә рәсүлиһи Мөхәммәдин вә алиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Әшһәдү әл-лә иләһә иллә Аллаһу әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү вә радыйәтү билләһи Раббән вә би-Мөхәммәди галәйһиссәлам нәбиййина вә бил-ислами динән вә бил-Коръәни имамән вә бил-Кәгъбәти кыйблатән вә бил-мөэминини ихванән.

Йә әййуһа әлләзинә амәнү әттаку Аллаһи хаккый тәкатиһи вә лә тәмәүвәтән иллә вә әнтум мөслимун.

Ошбу мең дә сигез йөз дә сиксән алтынчы елда 26 нчы июньдә мин – Казан куписы энесе Мөхәммәдшакир Мөхәммәдҗан угылы Мусин Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең вәхданиятенә вә рәсүле әкрәм Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәлләмнең рисаләтенә шәһадәт биреп, мәкарр вә мисдак булган хәлемдә, гакылым вә бәдәнем сагъ вә сәлим вә шәрган тәсаррәфәтем нафиз вә мөгътәбәр улган хәлемдә хөсне ихтыярым илән васыять кыйламын.

Бәнем мөкаддәр вафатым бәгъдендә үземнең мәтрүкәмнән бәнем сөягемне госел кыйлып, муафыйкы сөннәте сөннийәи



*Мөхәммәтшакир Мусин*

рәсүле әкрәм, тәкфин вә тәҗһиземне кыйлырсыз.

Дәфенем өчен биш йөз тәңкә сарыф кыйлырсыз вә вафатым сәнәсенә кадәрле зиммәмгә лязимел-әда улан фәраиз вә важибатемнең искаты өчен гали сәбилдер.

Салих вә мөтәдәйин адәмнәргә фидия бирерсез ике йөз илле тәңкә. Вә дәхи хале хәятемдә лязимел-әда улан хөҗҗәтел-ислам мөяссәр улмаса, бәнем өчен бер салих вә мөтәдәйин вә мөтәшәрригъ, мәнасике хаҗны галим булган бер адәмне җибәреп, бер мәртәбә хаҗ кыйлдырасыз. Хаҗ йибәрелгән адәмне ихтыярлы кыйлдым, ни рәвешле теләсә хаҗ кыйлырга– минем зиммәмнән төшкәндәй булса, ярар. Бәдәле хаҗ өчен тәгаен кыйлдым мең сум тәнкә. Билфараз, үзенә бер гозере шәргый вакыйг булса, әмер иттем: гайрегә шул мең сум тәнкәдән бәдәл биреп, минем өчен хаҗ кыйлдырырга. Әгәр насыйп булып, хаҗ сәфәре чыккач Исламбулда яки аннан ары



ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ

بسم الله الرحمن الرحیم

الحمد لله رب العالمین والصلوة والسلام علی رسوله محمد وآله واصحابه اجمعین اشهد ان لا اله الا الله واشهد
ان محمدا عبده ورسوله ورضیت بالله ربا وبمحمد علیه السلام نبیا وبالاسلام دینا وبالقرآن اماما وبالکعبة
قبلة وبالمؤمنین اخوانا یا ایها الذین آمنوا اتقوا الله حق تقاته ولا تموتن الا وانتم مسلمون اوشبو
منکده سکز یوز سکسان آلتنچی یلده ۲۶نچی ایوننده من قزان کوبه‌سی انسه محمدشاکر محمدجان
اوغلی موسین الله تبارک وتعالی ننک وحدانیتنه ورسول اکرم محمد مصطفی صلی الله علیه وسلم ننک
رسالتنه شهادة بیروب مقر ومصدق بولغان حالده عقلم وبدنم صاغ وسلیم وشرعا تصرفاتم نافذ
ومعتبر اولغان حالده حسن واختیاریم ایلان وصیت قیله من بنم مقدر وفاتم بعدنده اوزم
ننک متروکه‌مدن بنم سویکمنی غسل قیلوب موافق سنة سنیهٔ رسول اکرم تکفین وتجهیز منی
قیلورسز دفنم اوچون بش یوز تنکه صرف قیلورسز وو فاتم سنه سینه قدرلی ذمه‌مکا لازم
الادا اولان فرایض وواجباتم ننک اسقاطی اوچون علی سبیل دور صالح ومتدین آدملارکا
فدیه بیرورسز ایکی یوز ایللی تنکه ودخی حال حیاتمده لازم الادا اولان حجة الاسلام میسر اولماس
بنم اوچون بر صالح ومتدین ومتشرع مناسک حجنی عالم بولغان [illegible] حج
قیلدوره‌سز حج بیرلگان آدمنی اختیارلی قیلدوم [illegible] حج قیلورغه منم ذمه‌مدن توشکا
ندای بولسه یارار بدل حج اوچون تعیین قیلدوم منک صوم تنکه بالفرض اوزینه بر عذر شرعی
واقع بولسه امر ایتدیم غیریکا شول منک صوم تنکه‌دن بدل بیروب منم اوچون حج قیلدورغه اگر
نصیب بولوب حج سوزی [illegible] اسلامبولده یاکه آندان آری وفات بولسام [illegible] یوز تنکه بیروب
حج قیلدره‌سز بدل بیرگان کشیکه حج تمام بولغان بعدنده قزانغه قایتوینی شرط ایتارسز ودخی
طوطام [illegible] ننک قزی بیبی طائفه‌نی تربیه قیلوب نکاح [illegible] کیاوکا بیرگانده بش یوز صوم تنکه صرف قیلورسز
ودخی مسجد کرک یرلارکا ایکی مسجد بنا قیلورغه بیرورسز هر مسجدکا منکده بش یوز تنکه‌دن
ایکی مسجدکا اوچ منک تنکه اوشبو ایکی مسجدکا ایکی منک تنکه بانککا صالوب قویارسز شول
ایکی منک تنکه ننک [illegible] اوشبو ایکی مسجدننک حاجت یرلاری صرف قیلورسز ودخی آول‌لارده
مدرسه حاجت بولغان یرلارکا ایکی مدرسه بنا قیلورغه بیرورسز هر مدرسه‌که یوز ایللی تنکه‌دن

*Мөхәммәтшакир Мусин васыятьнамәсе*

вафат булсам, йите йөз тәнкә биреп хаҗ кыйлдырасыз. Бәдәл биргән кешегә хаҗ тәмам булган бәгъдендә Казанга кайтуны шарт итәрсез.

Вә дәхи тутамызның кызы Бибитаифәне тәрбия кыйлып, никахлап кияүгә биргәндә биш йөз сум тәнкә сарыф кыйлырсыз.

Вә дәхи мәсҗид кирәк йирләргә ике мәсҗид бина кыйлырга бирерсез. Һәр мәсҗидкә мең дә биш йөз тәнкәдән – ике мәсҗидкә өч мең тәнкә. Ошбу ике мәсҗидкә ике мең тәнкә банкыга салып куярсыз. Шул ике мең тәнкәнең рибехене ошбу ике мәсҗиднең хаҗәт йирләре[нә] сарыф кыйлырсыз.

Вә дәхи авылларда мәдрәсә хаҗәт булган йирләргә ике мәдрәсә бина кыйлырга бирерсез. Һәр мәдрәсәгә йөз илле тәнкәдән – // *(2а кәгазь)* ике мәдрәсәгә өч йөз тәңкә. Ошбу ике мәдрәсә өчен бер мең тәнкә банкыга салып куярсыз.

Рибехене ошбу ике мәдрәсәнең хаҗәт йирләрегә сарыф кыйлырсыз.

Вә дәхи коесыз авылларга ике кое казытырга бирерсез. Һәр коега 75 сум тәнкәдән – ике коега йөз илле тәнкә.

Вә һәм үземнең васыятьләрем буенча сарыф ителгәннән калган малларым нөкуд булсын яки әмтига булсын вә әсбаплар мәнкуль вә гайре мәнкульдән халис үз милкем булган мәтрүкәмне – көллисене үзем шәргый вәрәсәләремгә, муафыйкы шәргы шәриф, тәкъсим кыйлыныр.

Вә һәм ошбу васыятьләремне иҗра вә тәнфиз кыйлыр өчен һәм хакымны мин ләһе әл-Хакка ирештерерләр дип, кәмаль исабәт вә игътимад кыйлып, васыйи мөхтар кыйлдым шөһуде годуль хозурында: әүвәл – Казан куписы Мөхәммәдшәриф Мөхәммәдҗан угылы Мусинны, икенче – Казан куписы энесе Мөхәммәдсиддыйк Мөхәммәдҗан угылы Мусинны.

Вә һәм мәзкүр Мөхәммәдшәриф илән Мөхәммәдсиддыйк шөһүде годуль хозурында васыйлыкны кабул кыйлдылар.

Мин, мусый мәзкүр Мөхәммәдшакир Мөхәммәдҗан угылы Мусин ошбу шәһадәт вә икърарларымны вә васыятьләремнең көллисене камил ихтыярым вә хөсне ризалыгым илән

әйткәнемнең раслыгына шаһитлар хозурында [имза кылдым]: Мөхәммәдшакир Мөхәммәдҗан угылы Мусин.

Мөхәммәдшәриф Мөхәммәдҗан угылы Мусин васый кыйлганлыкны кабул кыйлдым: Мөхәммәдшәриф Мөхәммәдҗан угылы Мусин.

Мөхәммәдсиддыйк Мөхәммәдҗан угылы Мусин васый кыйлганлыкны кабул кыйлдым.

Мәзкүр Мөхәммәдшакир Мөхәммәдҗан угылы Мусинның мәзкүр васыятьләрене камил ризалыгы вә гакылы илән әйткәненә һәм көллисене үзеннән ишетеп шаһитлар:

Шаһит булып Казан өязенең Битаман авылының Садреддин Мифтахеддин угылы яздым.

Шаһит булып Казан өязе Түбән Курса авылының Шәмседдин Хөсәен угылы.

Ошбу васыятьнамәне мәзкүр Мөхәммәдшәриф Мөхәммәдҗан угылы Мусинның үтенүе буенча Казан шәһәрендә 5 нче Таш мәсҗиддә указный мулла Мөхәммәдйосыф Габдессаттар угылы Сәгыйдев яздым.

***

Текст 22x35 см. зурлыгындагы ике кәгазьгә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1866т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Нурания Галимовадан Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллин тарафыннан 2003 елның март аенда алынган. Сакланышы яхшы диярлек: бөкләнгән урыннары бераз таушалган.

Бу васыятьнамәнең авторы – Казан шәһәренең мәшһүр сәүдәгәре Мөхәмматшакир Мусин (1851–1912). Ул Казанда һәм төрле ярминкәләрдә көнчыгыш аяк киемнәре белән сәүдә иткән. Вафаты да Түбән Новгород ярминкәсендә ирешеп, 1912 елда йөрәк өянәгеннән үлгән. Аның турында XX гасыр башындагы татар матбугатында һәм соңгы чордагы журналларда һәм китапларда язылды, фоторәсемнәре басылды.

Китапның кереш мәкаләсендә әйтеп үтелгәнчә, ихтимал, бу васыятьнамә М.Мусинның иң соңгы текст варианты түгелдер. Чөнки ул бу васыяте язылганнан соң 26 ел үткәч вафат булган.

Битаман – хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районындагы авыл.

Түбән Курса – хәзерге Арча районындагы авыл.

Садретдин Мифтахетдин улы – танылган татар сәүдәгәре, химаяче Садретдин Нәзиров (1845–1925).

Шәмсетдин Хөсәен улы – XIX гасыр уртасыннан китап сәүдәсе белән, 1866 елдан нәшрият эшчәнлеге белән шөгыльләнгән шәхес. Аның игелекле эшен варислары һәм туганнары дәвам иткән.

Мулла Мөхәммәтйосыф Сәгыйдев (1830–1909) – 1868 елдан Казан шәһәренең Баруди мәчете имамы булган. Кадимчелек вәкиле буларак танылган. Язучы Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» исемле сатирик повестендагы баш герой прототибы дип фаразлана.

## 99. Игъланнамә. 1889 ел.

// *(3а кәгазь)* Исхак вә Ибраһим Гобәйдулла угланнары Юнысовларның мал-мәтрүкәләрене тәкъсимгә мәэмүр имамнарга Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысовтан игълан.

Шул хосуста кем, сез хәзрәтләр 15 нче үктәбергә мал-мәтрүкәне тәкъсим мәҗлесенә безне чакырган икәнсез, каю язуыңызы күрдем һәм шул мәҗлескә хазир булырга кулымнан имза вирмеш идем. Ләкин ул мәҗлескә бара алмаймын берничә манигълар сәбәпле һәм Казанда булмаймын, сәфәр кыйламын.

Әмма үз тарафымнан шәригать мәҗлесенә хазир булырга ошбу тәкъсим хосусында вәкаләтнамә вирәмен Сахибгәрәй Әхмәд угылына, кайсы кем минем өчен сөйләп вә һәм җавап виреп торыр һәм тиешле урынга кул куярга вәкил иттем.

Патумыствинный пачутный гражданин Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысов.

Инабәт өчен мөһеремне бастым.


3

اسحاق و ابراهیم عبید الله اوغلانلارى یونوسف لارنىڭ مال متروکه لرینى تقسیم که
مأمور امام لارغه

محمد رحیم اسحاق اوغلى یونوسفدان

اعلان

شول خصوصده که سن حضرتلر الانى اوکتابرگه مال متروکه نى تقسیم مجلسنه
بزنى چاقرغان ایکانسز قابو بارونکز کوردوم هم شول مجلسکه حاضر بولورغه قوللرامدان
امضا ویرمش ایدوم لکن اول مجلسکه بارا آلمایم بر نیچه مانع لر سببلى هم
قرارده بولا آلمیم سز قیلامن امّا اوز طرفمدن شریعت مجلسنه حاضر بولورغه
او شبو تقسیم خصوصنده وکالة تامّة ویرامن صاحبگرى احمد اوغلینه کایسى که
مینم اوچون سوراو وهم جواب ویروب توردور هم تیوشلى اورونغه قول
قویارغه وکیل ایتدوم [illegible] محمد رحیم اسحاق
اوغلى یونوسف [illegible] اثبات اوچون [illegible] مهر باصدم

Потомств. почетн. гражд. МУХАМЕДРАХИМЪ ИСКАКОВИЧЪ ЮНУСОВЪ ВЪ КАЗАНИ.

*Мөхәммәтрәхим Юнысов игъланы*

[Овал рәвешендәге мөһер:] «Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысов әл-Казани. Потомств. почетн. гражд. Мухамедрахим Искакович Юнусов, в Казани».

## 100. Вәкаләтнамә. 1889 ел.

// *(1а кәгазь)* Мин – Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысов вәкиллек вирәмен Сахибгәрәй Әхмәт угылыга шул хосуста кем – Сахибгәрәй Әхмәт угылы минем өчен тәкъсиме тәрикә



*Мөхәммәтрәхим Юнысов*

мәҗлесенә хазир булып һәм минем өчен сөйләп вә җавап вireп һәм тиешле урыннарга кул куеп торыр.

Әлхасыйль, бу мәҗлескә мөдахәлә кыйлырга вәкаләтнамә вирдем – патумствинный пачутный гражданин Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысов.

Инабәт өчен мөһеремне бастым.

*[Овал рәвешендәге мөһер:]* «Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысов әл-Казани. Потомств. почетн. гражд. Мухамедрахим Искакович Юнусов, в Казани».

***

Казан шәһәренең мәшһүр сәүдәгәрләре Юнысовларның мирас бүлү мәсьәләсенә бәйле әлеге документлары Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә «361д» шифры белән саклана.

Югарыда текстлары бирелгән игъланнамәдә һәм вәкаләтнамәдә даталары күрсәтелмәгән. Әмма шул ук язмаларга бәйле гариза мәсьәләнең торышын тулырак күзалларга ярдәм итүе белән бергә, анда төгәл датасы да куелган. Шул ук саклану берәмлегендә 2а кәгазендә теркәлгән гаризаның тексты түбәндәгечә: «Гыйзззәтлеләремез Казанда Ибраһим вә Исхак Гобәйдулла угланнары мәрхүм Юнысовларның малмәтрүкәләрене тәкъсимгә мәэмүр имамнарга

Патумствинный пачутный гражданин, Казан сәүдәгәре, олуг варис Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысовдин

гариза.

Шул хосуста кем, безләрнең әткәмез Исхак вә агамыз Ибраһим Гобәйдулла угланнары Юнысовларның малларыны тәкъсимгә ошбу 15 нче үктәбердә, якшәнбә көн, мәҗлесе шәрыг тәгаен кыйлынган икән һәм безләр дәгъвәт кыйлынганмыз. Гәрчә бу мәҗлескә хазир булмасак та, шул Духовнай Сабраниянең фәрманының гонваны мөҗибенчә, би-муафыйкы шәрыг, кыйсмәт кыйлуга без үз тарафымыздан разый. Безнең хазир булмаганлыкымыздин мәҗлес тәэахир кыйлынмаса иде.

Хазир булмаганлыкымызның сәбәбе – бик зарур хезмәт чыкып, Казандин бүген сәфәр кыйлдык. Мәҗлескә бәлки кайтып йитешә алмамыз. Үземез хазир булмасак та, юкарыда мәзкүр фәрманның мәфһүменчә, шәргы шәриф буенча кыйсмәткә шөруг кыйлсаңыз иде.

Шәһре Казан. 1889 нчы ел, 13-ндә үктәбер.

Мөхәммәдрәхим Исхак угылы Юнысов».

Бу өч документ та 22,5х35,5 зурлыгындагы кәгазьгә язылганнар. Шулардан «игълан» һәм «вәкаләтнамә» көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә, ә «гариза» көрән төстәге язу карасы белән, тәгъликъ төрендә теркәлгәннәр.

## 101. Җир сату турындагы килешү. 1893 ел.

1893 нче елда гыйнварның 7 нче көнендә Буа өязе вә Шыгырдан вулысы вә Шыгырдан иленең мин – Хәйреддин Сиддыйк угылы үз душыма тигән бер йиремне саттым шул ук Буа өязе вә Шыгырдан иленең Фәхретдин Вәлиулла угылына.

Йирем Согыт җиренә башы берлән урманга табан ягында – Галиулла Басыйр угылы, үгә табан ягында – Хәсән Хөсәен угылы.

Йиремнең бәһасе булды биш сум.

Мин Хәйретдин Сиддыйк угылы йиремне сатып, биш сум акча алганлыкымның раслыкы өчен тамкам салдым.

Мин – силски ыстарыста Бәһаветдин Хөснетдин угылы пичәт бастым.

***

Текст 17,7x11,2 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына сыек көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «7510т» шифры белән саклана. Аны Чувашстанның Батыр районы Шыгырдан авылыннан Рәфис Җәмдиханов 2002 елның 19 февралендә китереп тапшырган.

Шыгырдан, Согыт (Татар Согыты) – хәзерге Чувашстан Республикасының Батыр районындагы авыллар.

## 102. Ибраһим Әмин улы васыятьнамәсе. 1895 ел.

// *(1а кәгазь)* Васыятьнамә

Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим.

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.

Әүвәл бинам Аллаһ дөюм, пәйгамбәремез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи сөюм, чәһарияр ба-сафа. Бән васыять идәм ки – Ибраһим Әмин угылы үземнең угылым Йосыфга, Аллаһы Тәгаләдән вакыт ирешеп дөньядан күчсәм, әүвәл тәкфин-тәҗһиземне бән әйткәнчә кыйласән, фидиямә ике баш

умарта бирәсән, гүр садәкасына ике сарык, гайреләрне ушандак тиешенчә.

Вә янә моның бәгъдендә балаларым бер-берсилә низаглашып йөрмәсеннәр өчен үзләренә биргән нәрсәләремне белдерәмен.

Әүвәл – угылым Йосыфга ындырга табагы өемне вә һәм анбарымны, һәм баз-келәтемне, вә һәм абзарларымны – бар-


وصیت نامه
اعوذ بالله من الشیطان الرجیم بسم الله الرحمن الرحیم

ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ
503 т.

*Ибраһим Әмин улы васыятьнамәсе*

часы бер ат, дүрд баш сарык, арба, чана, бер тарантас арба, камыт, ыңгырчак, сука, тырма барча әсбаплары илән вә гайре йорт эчендә булган нәрсәләрне көллесен тәмлик кылдым.

Вә янә угылым Гайсәгә бер өю, бер келәт, өю алды (сайгаклары илә) һәм бер абзар вә гайре каралты ясарга хәзерләгә[н] бүрәнәләре илән һәм бер ат, камыт-эшлиясе вә гайре әсбаплары илән, бер ыстан арба һәм чана һәм сука, тырма бар әсбаплары [белән] вә һәм йорт эчендә булгучы әсбапларны тәмам биреп чыгардым. Бер бакыр комка[н], бер такта яра торган пычкы, бер агач сандык, бер киез биреп чыгардым, бер сыгыр, дүрд сарык биреп чыгардым.

Вә янә кызларыма бишесенә берәр бозау, икешәр сарык, берәр ястык, икешәр мамык мендәр һәм сөлге, ашъяулык, нидер хәляикъ арасында була гадәттә булгучы нәрсәләрне тәмам хәзерләтеп йибәрдем.

// *(1б кәгазь)* Вә янә угылым Йосыфга васыятем ошбу – угылым Мусаның угланнарынын янә берсен өйләндереп, ягъни хатын алып биреп, өчесен берчә башка чыгарасән, өю салып һәм келәт ясап, бер ат, ике сарык биреп һәм сука, тырма илән вә гайре әсбаплары илән, камыт, ыңгырчагы илән. Үз балаларың күк итеп вә һәм үземнең җомга намазына киеп бара торган тунымны вә һәм басма тышлы түгәрәк мендәремне һәм бер бакыр комган биреп чыгарасән.

Вә янә Хәлилулла белән уртак унике баш кортларымны угылым Йосыфга бер өлеш, Гайсәгә бер өлештән вә һәм Мусамның угланнарына бер өлештән файдаланырсыз. Вә һәм карчыгымга бер өлештән файдаланырлар.

Вә янә үземә генә махсус биш баш умартаның икесен фидиямә, аннан калганыны ха[ты]нымга тәмлик кылдым. Вә һәм хатынымның гүр сәдакасына ике сарык бирәсән.

Вә янә угылым Йосыфга ахыр васыятем ошбу – нидер кем юкарыда зикер иделенгән нәрсәләрдән калган әмвалемне сиңа тәмлик кылдым. Нидер кем бурычларым бар – барчасын шул малларым берлән әда кылмак шарты илән сине вәкил кылдым.

Үз кулым берлән язып кулым куйдым.

1895 нче елда, апрельнең 28-ндә.

Вә янә бурычларымның бер йөз дә илле дүрт тәнкәсе үз кулым берлән алган һәм Йосыфның үз кулы берлән алган бурычлар барчасы минем бурычларым.

Гайса Ибраһим угылы әтинең әйткән васыятенә разый булып кулым куйдым.

Бибикамилә һәм разый булып галәмәтемне кулым куйдым.

Янә Йосыф әткәмнең васыятенә разый булып кулым куйдым.

***

Бу васыятьнамә тексты Ибраһим Әмин улы тарафыннан 22х35 см. зурлыгындагы 1 кәгазьгә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача диярлек: бөкләнгән урыннары өзелеп чыгу дәрәҗәсендә.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «503т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Татарстанның Балтач районындагы Шода авылында яшәүче Миңсылу Җамалиевадан 1995 елның август аенда алынган иде.

«Ыстан арба» – станлы ат арбасы.

## 103. Инабәт язулары. 1896–1897 еллар.

«а»

1896 нчы елда фибралның фәләненче көнендә Самар губернасы Бөгелмә өязе Александр вулысы Ырыссуы авылының Габделвәли Гали угылы алдым бер йир урак. Ягъни, шул хосуста авылымызның силски ыстарастасындин вирелде ошбу инабәт язуыны.

Кушкан вакытта һич инкярсез хезмәт итмәкче булдым.

«б»

1897 нче елда фибралның фәләненче көнендә Самар губернасы Бөгелмә өязе Александр вулысы Ырыссуы авылының Габделвәли Гали угылыдан ал[дым] бер йир урак. Ягъни, шул

хосуста авылымызның силски ыстарастасындин вирелде ошбу инабәт язуыны.

Кушкан вакытта һич инкярсез хезмәт итмәкче булдым.

***

Бу язмалар 17х22 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына ачык көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача диярлек.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1215т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Татарстанның Ютазы районындагы Бәйрәкә авылында яшәүче Әнвәр Яхиннан бу юлларның авторы тарафыннан 1991 елның июнь аенда алынган иде.

Ырыссуы – хәзерге Татарстан Республикасының Ютазы районындагы Иске Урыссу авылы.

## 104. Җир сату турындагы карар. 1898 ел.

Приговор

1898 нче елда 5 нче дикәбердә.

Казан өязе Суыксу булысы Ташсу авылының мөселман җәмәгатьләре пулавный ысхудта силски ыстарыста хозурында, һәркаюмыз бер иттифакта булып, ашлык чәчәргә җарый торган, җәмәгатькә калган җир итеп җир бүлгән чакта хисапка кертми һәм жирәбә салмыйчы калдырамыз ошбу әйтелмеш җиремезнең кай урында һәм зурлыгы ошбу эрәвешчә: шул ук авылымызның урман кырыенда Кизләүле Кыяк өстендә Мулла ышнасы һәм Сәйфулла ышнасы һәм түбән башында «Җәмәгать йөрәге» ошбу өч йирне бер итеп, юкары җак чиге Мулла ышнасының юкары эзеннән башлап, уң як урман ягы, Түбән Кыяк болыны итәгеннән тугры түбән төшеп, янә болын буенча килеп, авылга таба карап «Җәмәгать йөрәге»нең түбән ягыннан әйләнеп, Халид сызасының итәгеннән янә юкары таба тәмам Мулла ышнасының юкары башына барып туктасы.

Ошбу юкарыдагы әйтелмеш җиремезне сат[т]ык шул ук



*Җир сату карары*

авылымызның Мөхәммәджан мулла Гайнеддин угылы илә Сәлахеддин мулла Низамеддин угылына. Хакы – егерме биш сум тәнкә, вәгъдәсе – унбиш елга. Әүвәл чәчә башлаган елның башы 1901 нче елның башыннан хисап кылып, 1916 нчы елда вәгъдәмез туласы.

Акчасын зимләмир ырасхутына тоттык.

Ыраслыгына һәркаюмыз түбәндә исемнәремезне яздык һәм кулларымызны куйдык.

Ошбу җиремезне сатканлыкымызга әүвәл – Хөснеддин Шәмседдин угылы, Сәмид Мәҗид угылы, Хәмид Латыйф угылы, Хәйрулла Җамия угылы, Мөхәммәдҗан Баттал угылы, Шаһи Сәйфулла угылы, Сәгъдеддин Сабит угылы, Мифтахеддин Хисамеддин угылы, Вәлиулла Мөхәммәдеррәхим угылы, Мортаза Мостай угылы, Төхфәтулла Габдеррәфыйк угылы, Хәйрулла Гыйззәтулла угылы, Вәлиулла Заһидулла угылы, Закир Мөхәммәдеррәхим угылы, Халид Вахид угылы, Низамеддин Хисамеддин угылы, Зариф Мәҗид угылы, Әхмәдишаһ Вахид угылы, Гариф Хәмид угылы, Вәлиулла Муса угылы, Шакир Мөхәммәдеррәхим угылы, Мәннаф Латыйф угылы, Исмәгыйль Госман угылы, Сәйфулла Сәгыйдь угылы, Сиддыйк Хәким угылы, Миңлебай Сахиб у[гылы], Сафиулла Сахиб угылы, Бәһави Хисамеддин угылы, Мифтахеддин Фәхреддин угылы, Зариф Мөхәммәдҗан угылы, Сабит Габид угылы, Хөснеддин Сәйфеддин угылы, Шаһи Бикчәнтәй угылы, Мәҗид Мөсәгыйд угылы, Сәмид Мөсәгыйд угылы, Гайнеддин Таҗеддин угылы, Мөхәммәдшаһ Әхмәдьяр угылы, Шиһаб Хисамеддин [угылы], Шәриф Мәҗид угылы, Хөснеддин Сираҗеддин угылы, Шәрәфеддин Фәхреддин угылы, Гайнеддин Хисамеддин угылы, Әхмәдулла Нигъмәтулла у[гылы], Хәбибулла Гыйззәтулла угылы, Хәмидулла Габид угылы, Вафа Әхмәдҗан угылы, Вәлиулла Гомәр угылы, Сәгъдеддин Фәхреддин угылы, Галәведдин Фәхреддин угылы, Сәмид Сабит угылы, Галиулла Гомәр угылы, Нәҗмеддин Сабит угылы, Сахиб Сабит угылы.

Ошбу юкарыдагы картларның үтенүе буенча мин – Садыйк Сабит угылы үзем өчен һәм картлар өчен кулым куйдым.

Камаледдин Хәмид угылы кулым куйдым.

Хәсән Рәхмәтулла угылы – кулым куйдым.

Ошбу пригаварның ыраслыгына һәркаю җәмәгатьләрнең ырыксате белә мин – силски ыстарыста Заһидулла Бикчәнтәй угылы кәҗүнни пичәтне бастым: «Печ[ать] сельс[кого] стар[осты] Айбашинско-дорожног[о] общ[ества] Студено-Ключищен[ской] вол[ости]».

***

Бу документ тексты 22х35,5 см. зурлыгындагы куш кәгазьнең бер битенә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «5656т» шифры белән саклана. Галим, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәтһади Максуди архивына нисбәтле бу язма истәлек китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Ләйлә Гаффаровадан 2021 елның октябрендә алынды.

Кәгазьнең бер тарафында карандаш белән «Ташсуның Мөхәммәдҗан берлән Сәлахеддин җәмгыятьтән җир алган пригава[р]» дип язылган. Болардан Сәлахетдин Низаметдин улы (1869–1949) – Әхмәтһади Максудиның бертуган энесе. Ул авылда яшәгәндә үк аяк киемнәре тегү эшен оештырган, 1900 елда Казанга күченеп, аяк киемнәре фабрикасы ачкан һәм I гильдияле сәүдәгәр буларак танылган. Совет хакимияте урнашкач, мөлкәтләре һәм йорт-җирләре тартып алынып, гаиләсе белән яңадан Ташсу авылына кайткан. Берничә елдан тагын Казанга киткәннәр. Аларның тормышлары һәм нәселләре турында китапта язылган: Зәбиров Г. Максуд баба һәм Максудилар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 32–39.

Документтагы икенче кеше – Мөхәммәтҗан Гайнетдин мулла улы (1856–1919) Сәлахетдин Максудовның агасы (әтисенең бертуган энесе). Аның нәсел тармаклары турында югарыда әйтелгән Г.Зәбиров китабының 149–157 битләрендә язылган.

Ташсу – хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районындагы авыл.

## 105. Хәлегънамә формуляры. 1898 ел.

Әрәм хат бу рәвешчә языгыз

1898 нче елда фәлән губернаның фәлән өязнең фәлән авылның фәлән угылы фәлән үземезнең тәхте никахымда улган хатынымны – фәлән кызы фәләнне хөлуг кыйлдым гүаһлар алынысында.

Моның соңында һичбер дәгъва-хосумәт кыйлмаска, калган мәһәремне үземезнең никахлы булган иремездин вә һәм гыйддәт нәфәкасене, әгәр д[ә] баласы булса, сөт имә торган балага ни килгән хакыны вә һәм киндер, сукна хакыны барчасыны кичтем.

Ирендин һәм хатыныңдин кул куйдыргайсызлар. Әгәр дә белмәсәләр, алар өчен башка кешедән куйдыргайсызлар. Ул әрәм хатыны үзеңездә калдырасызлар, икенче кешегә никах язганда үзеңездә хәзер була.

Ире үлгән хатынга – ике ай ун көн, ирендин аерылганга – дүрт ай ун көн.

***

Бу хәлегънамә формуляры 11х17,5 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача: кәгазьнең читләре бераз таушалган, дымлану кичергән.

Кульъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «3814т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Самара өлкәсенең Иске Ярмәк авылы мәчетеннән 1996 елның декабрь аенда бу юлларның авторы тарафыннан алынды.

Тексттагы «алынысында» сүзе «алдында» дигән мәгънәне белдерә.

## 106. Хәбибҗамал Госман кызы васыятьнамәсе. XIX гасырның икенче яртысы.

Васыятьнамә

Мин – фәкыйрә Хәбибҗамал Госман кызы.

Вафат улсам, башым өч кат ябасыз: ике катына ике яңа яулык, өченче катына яңа өрпәк маңлай иләән.

Һәм кәфенемне хәзрәт хатыны килми кисмәгәйләр. Ул килгәч кисәрләр.

Ике кызыллы ашъяулык: берсе – хәзрәт хатынына, берсе – Нәҗми мөәзин хатынына.

Гүргә индергән соң ике мөәзингә ике кызыл башлы



*Хәбибҗамал Госман кызы васыятьнамәсе*

сөлгеләр һәм Мөхәммәдьяр абзыйгә бер кызыл башлы яңа сөлге. Янә бер кызыл ашъяулык яңа хәзрәткә. Зияраттән кайткач бер кызыллы ашъяулык мәхзүмгә сөлге, кимәмә киндер илән ситса, хәзрәткә ситса, Вәлиулла мәхзүмгә киндер вирерсез.

Гүр сәдакасына бер сарык алып биргәйсез. Һәм мәкъбәргә барып Коръән укырга кырык көнчә кемгә кушыйк дәю, хәзрәткә мөшавәрәт кыйлгайсыз.

Коръән үз өстемдә хәтем иттергәйсез һәм фидиягә үзеңез белеп биргәйсез.

Һәм Нәҗми мөәзин хатынына бер яңа күлмәкне биргәйсез.

Һәм су керткән кешегә ике дәстмал.

Комганга су тулдырып биргән кешегә кызыл башлы дәстмал.

Дәстар башын дүрт якын кешеләр тоткайлар – берәр дәстмал.

Ташкичүнең олы киленгә бер ситса ыштан илән бер нәрсә кушып биргәйсез.

Өстемә явып алган киндерне су салган кеше илән юган кешегә уртак булыр.

Котаймасның Шакир кызына бер-ике нәрсә биргәйсез.

Һәм ике мөәзин хатынына ике алъяпкычлык басма.

Керләрем юган кешегә ак башлы сөлге.

Кызым Сахибкамалгә көмеш каптырма, түшәк-ястык, самавар, комган, ахак кашлы йөзек сала... үзеңә булыр.

Башка калган нәрсәләрне үзеңез белеп сарыф итәрсез.

Шушы сүзләр буенча хәзрәткә киңәш итеп эш кыйлгайсыз, башка кешегә киңәш итмәясезләр.

Һәм гозеремездер – юган вакытта сөягемне бик йомшаклык илән тота күргәйләр.

Пакьләгән вакытта пакь кыйла торган кешеләр булгай иде, гайре кешеләр булмагай иде.

Мөһере шәрифемне кәфенгә салгайсыз, онытмайсыз.

Кәнфара суын йөземә, кәфенемә бөркәйсезләр[49].

Без фәкыйрә әнкәңезгә кайткан вакытта зиярәт кыйлгайсыз. Ризалыгымыз шушы фигылеңездәдер.

Һәркаюмызга бәка иман рузи кыйлгай иде, амин.

Угылымыз Ибраһимгә бу сүзләр...[50]

---

[49] Хуш исләр бөркү борынгы дини китаплардан ук килгән. Мәсәлән, «Гайнел-гыйлем» китабының үлемгә һәм мәеткә бәйле урынында болай диелгән: «дәхи рәсүлуллага иярүнең хакы ... хуш исләндермәклектер үлекнең тирәләрене – аның өчен: үлек булган өю фәрештәләр хазир була торган урындыр» (Гайнел-гыйлем тәрҗемәсе / мөтәрҗим – Шәйхелислам бине Әсәдулла Хәмидуллый әт-Төкеви. – Казан: матбагаи Кәримия, 1902. – Б. 125).

[50] Кәгазь битенең соңгы юлындагы шушы сүзләрдән соң текстның дәвамы юк.

***

Бу текст 17,5х21,5 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына сыек көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуның тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазь читләре таушалган һәм кайбер урыннары ертылган.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «3345т» шифры белән саклана. Ул китапханәнең 2016 елда (август аенда) Арча районына оештырылган археографик экспедициясе вакытында Колачы авылында яшәүче Илсөя Мөхәммәтгалиевадан алынган.

Ташкичү – хәзерге Татарстан Республикасының Арча районындагы авыл.

Котаймас – хәзерге Әтнә районындагы Кышлау авылының элекке атамасы.

Тексттагы «кимәмә» сүзе хатын-кыз мәетен зиратка күтәреп илткәндә аның өстенә чатырсыман корылган тукыманы («кимәлек»не) белдергәндер.

## 107. Габделгали Бәйрәкәви васыятьнамәсе. XIX гасырның икенче яртысы.

// *(3б кәгазь)* Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.

Бу әүвәл васыятьнамәдер кем, бителде түбәндә зикер иделәчәк шаһитлар хозурында, мөштәмил бу мәгънә үзәренә кем, бән – фәкыйрь, пөртәкъсыйр Габделгали бине мулла Гобәйдулла бине Ибраһим әл-Бәйрәкәви васыять идәрәм, шәһадәт виргәнем хәлдә, бөйлә – лә иләһә иллә Аллаһу вәхдәһү лә шәрикә ләһү, ләм йәлид вә лә йүләд; вә ләм йәттәхиз сахибәтән вә лә вәләдән вә әннә сәйидина Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү вә әминүһү галә вәхиһи салләллаһу галәйһи вәсәлләм вә әннәл-җәннәтә – хаккун вән-нарә – хаккун вәс-сәгатү атиятүн лә рәйбә фиһа вә әннә Аллаһә йәбгасү мән фил-кобури Аллаһүммә инни ушһидүкә вә ушһиду хәмәләтә гаршикә вә мәляикәтикә вә җәмигыйль-


بسم الله الرحمن الرحيم
اول
بو وصیت نامه دورکم بتلدی توبانده ذکر ایدلاجك شاهد
لار حضورنده مشتمل بو معنی اوزرینه کم بن فقیر بر
تقصیر عبد العلی بن ملا عبید الله بن ابراهیم البیرکوی وصیت
ایدرم شهادة ویرکانم حالده بو ایله لا اله الا الله وحده لا شریك
له لم یلد ولم یولد ولم یتخذ صاحبة ولا ولدا وان سیدنا محمدا
عبده ورسوله وامینه علی وحیه صلی الله علیه وسلم وان الجنة
حق والنار حق والساعة آتیة لا ریب فیها وان الله یبعث من
فی القبور اللهم انی اشهدك واشهد حملة عرشك وملائكتك
وجمیع خلقك بانك انت الله لا اله الا انت وحدك لا شریك لك
وان سیدنا محمدا عبدك ورسولك وانی رضیت بالله ربا وبالاسلام دینا
وبمحمد صلی الله علیه وسلم رسولا ونبیا مبتهل الیه ان یتم علی
فی ذلك الاعتقاد فهمته وان لا یسلب منی ما وهب لی
فیه وما امتن به علی حتی یتوفانی علی ذلك انه الملك

*Габделгали Бәйрәкәви васыятьнамәсе*

халькыйкә би-әннәкә әнтә Аллаһу лә иләһә иллә әнтә вәхдәкә лә шәрикә ләкә вә әннә сәйидина Мөхәммәдән габдүкә вә

рәсүлүкә вә әнни разыйтү билләһи вә бил-ислами динән вә би-Мөхәммәдин салләллаһу галәйһи вәсәлләмә рәсүлән вә нәбийән мөбтәһилүн иләйһи эн йүтиммә галәййә фи заликәл-игътикади фәһимтүһү вә эн лә йәслүбә минни ма вәһәбә ли фиһи вә ма имтәннә биһи галәййә хәтта йәтәвә фә-әнни галә заликә фә-иннә ләһүл-мөлкү // (*4а кәгазь*) вә би-йәдиһил-хәйрү вә Һуа галә көлли шәйин Кадыйрун.

Васыять идәрәм балаларым Зәкия, вә Мөхсин, вә Мәсгудь вә Габдуллагә вә әһле бәйтем Хәдичәгә вә хафитларым Мөҗаһид вә Мәхмүд вә Габделхакга вә ихване дин, әһле тарикатьләрә вә мәдрәсәмездә карарзадә улан талибел-гыйлемләрә вә һәм һәр минем әмеремне тотанлара шул васыять илә кем, аны Ибраһим вә Ягъкуб галәйһума әссәлам балаларына васыять кылдылар, тәхкыйкы Аллаһы Тәгалә сезләрә хак улан дине исламы рузи кылды, бәс камил иҗтиһад идеңез шул ук дине исламда үлмәккә.

Янә васыять идәрәм – һәркаюңыз Аллаһы Тәгаләнең әмеренә сиррән әү гыйлләнән ниятә буйсынасызлар, тагатендә лязим улыб, мәгъсыятьтән тыеласыз. Галәлхосус намазны мәсҗиддә җәмәгать илә укымакга сәгый вә иһтимам идәсез, мохалифе шәрыгъ улан юл вә кануннара иттибаг итмәясезләр, сабантуй // (*4б кәгазь)* вә тәкә җыены вә гайре мәҗамигы ләһ вә ләгыбә вармаясыз. Анларда аслан гыйбрәт алыр нәрсә юктыр, вә касвәте кальбе мөҗиб әшья чуктыр. Бахосус, сезләрә моталлигъ булган бер мәнһи шәй – кабер казымак вакытында тупрак коелмасын өчен зиярәт ихатасындин яки хас-хас кабер ихатасыннан агач, ягъни киртә вә койма алып, изенсез истигъмаль кылып ташлап, тәләф кылмак мөлке гайре рөхсәтсез вә истигъмаль кылмак кеби эшләрдин, зинһар, сакланасыз.

Дәхи васыйларыма[51] васыять идәрәм – вафатым бәгъдендә җәмигъ диваным үтәясез вә әманәтләре, ягъни вәдигать вә гарият улан нәрсәләре әрбабенә тәслим идәсәз. Бәһре вәҗһ талибе Хакны ирзага сәгый идәсез, вә вәкыф улан «Шәрхе Гайнел-гыйлем» әл-Гали әл-Карины китабәте вәкъфындә язылганча калды-

[51] Бу сүз кулъязмада «васыятьләремә» дип ялгыш язылган.

расыз, тәмлик вә тәмәллек итмәясез. Ул газиеш-шан, баһирел-борһан, җәллиһи шаниһи вә газыйме солтаниһиның нә олуг вә гыйнаятедер кем, мәгъруре бил-әмәл вә мокассир фил-гамәл улан гасый, җафи колларына...[52]

***

Бу васыятьнамә тексты 11х17,8 см. зурлыгындагы дәфтәрнең 3б–4б кәгазьләрендә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгълик төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача.

Барлыгы 4 кәгазь күләмендәге өлеше сакланган (башы һәм ахыры юк) әлеге дәфтәрнең 1а–2а кәгазьләрендә «Бәйрәкә авылының ишан хәзрәтнең мәрсиясе» язылган.

2а кәгазендә текстларны күчергән кешенең исеме күрсәтелгән: «ошбуны язгучы Сөләй авылының Хатбулла Шәһидулла угылы».

Дәфтәрнең 2б кәгазендә (бер бит күләмендә) васыятьнамә текстының кереш өлеше язылa башлап тукталган һәм 3б кәгазеннән яңадан, тулырак рәвештә теркәлгән.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «7182т» шифры белән саклана. Аны китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Галия Хадмиева 2003 елның 17 мартында тапшырды.

Васыятьнамәнең авторы Габделгали Гобәйдулла улы Бәйрәкәви (1822–1902) мәшһүр имамнар (Гобәйдуллиннар) нәселенең вәкиле, ишан. Ул Бәйрәкәдә мөдәррис булган һәм имамлык вазифаларын үтәгән, 82 яшендә вафат булган. Әлеге шәхес һәм аның нәселе турында Р.Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә язылган[53].

---

[52] Кульязмада текстның дәвамы юк.

[53] Фәхреддин Р. Асар. 2 том / төз. И.Гыймадиев, Р.Миңнуллин, С.Баһавиева. – Казан: «Рухият» нәшр., 2009. – Б. 22–23; Фәхреддин Р. Асар / төз. Л.Байбулатова, Р.Йөзмөхәммәтов, А.Салахов, Р.Миңнуллин, И.Гыймадиев, С.Хафизова. 3 һәм 4 томнар. – Казан: «Рухият» нәшр., 2010. – Б. 265–267.

Габделгали хәзрәт васыятьнамәсендә исеме язылган улы Мөхсингә (1870–1930) бәйле рәвештә «Татар археографиясе» сериясенең 27 нче китабында кыскача мәгълүмат биреп, аның фоторәсемен дә урнаштырган идек[54]. Шунда ук энесе Мәсгуть турында да әйтелде.

### 108. Хәлегънамә. XIX гасырның икенче яртысы.

Казан өязе Кили авылының бән – Нигъмәтҗан Сәйфелмөлек угылының хатыны Гыйззенниса Сираҗетдин кызы илән арамызда хөсне могашәрә улмаган сәбәптән бән – Нигъмәтҗан Сәйф[елмөлек] угылы хәлегъ кыйлдым. Мәһәр вә гыйддәт нәфәкасене кичмәк шарты үзрә һәм хатынның үз нәрсәләрен үзенә виреп, дәгъва-низаг кылмады.

Растлыг[ын]а бән – Нигъмәтҗан Сәйфелмөлек угылы тамгам

Бән – мәзкүрә Гыйззенниса Сираҗетдин кызы зәүҗем Нигъмәтҗанның ошбу рәвештә хәлегъ кылмакын кабул итеп, растлыгына инабәт өчен тамгам+

Шаһитлар: Мөхәммәтгали Сәйфелмөлек угылы тамгам

Янә Галимҗан Миңлекәй угылы тамгам[55].

Янә Гыйззеннисаның атасы бән – Сираҗетдин [атасы язылмаган] угылы тамгам

***

Бу хәлегънамә тексты 21,5х21 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача: кәгазь элек шактый бөгәрләнгән булган һәм дымлану кичергән.

Казан шәһәрендә яшәүче Әнвәр Хәйридән 1998 елда сатып алынган әлеге кульязма Татарстан Республикасының Милли

[54] Шигъри ядкярләр: XII–XIX гасырлар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап», 2021. – Б. 210–211.
[55] Кульязмада тамгасы куелмаган.

китапханәсендә «1003т» шифры белән саклана.

Кили – хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районындагы авыл.

## 109. Ат сату турындагы язма. 1900 ел.

1900 нче год.

Казаныски губирна Мамадышыски өяз Питырпавылыски вулысның Төркәш авылының бән Габделкяфи Низаметдин угылы саттым бер ташкыр ат – бәһасе кырык өч сум илән. Ошбуның җалы кара, бүтән билгесе юк.

Ошбуны сатканлыкыма әүвәл шаһит – Хәйретдин Исхак угылы кулым куйдым.

Дәхи шаһит – Фәлән Фәләнев тамгам салдым.

Ошбу мәзкүр сатуның раст[лыгына] Сахабетдиннәр ...лыкына разый улып кулым куйдым, тамгам салдым – крестьян д. Туркаш Габ. Низ.

Силски ыстараста Дауд Гайсә угылы пичәтем бастым.

Тәмам.

***

Бу язма – төп документның күчермәсе. Текст 11х18 см. зурлыгындагы, 8 кәгазьдән торган шигырьләр дәфтәренең 8а кәгазендә ачык шәмәхә төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «848т» шифры белән саклана. Ул Татарстанның Кукмара районындагы Төркәш авылында, бу юлларның авторы тарафыннан 1995 елның июнь аенда табылып, китапханәгә алынган иде.

## 110. Вәкаләтнамә күчермәсе. 1902 ел.

Тәүкилнамәдән копия

1320 нче елда һиҗрия илә вә 1902 нче елда румия илә

үктәбер 17-ндә Гали Ягъкуб угылы Акчурин Габдеррахман ибне даменла Зыяддинне вәли вә вәкил кыйлдым Мәчкәрә Гали Үтәмешев кәримәсе Камәрбануны кәнде үземә гакъде шәргый кыйлмага зәүҗәлеккә вә кәнде ихтыярым илә бу мәзкүр Габдеррахман ибне даменла Зыяэддинне вәкил кыйлганымның сәдакатенә әл имза кыйлдым: Гали ибне Ягъкуб Акчурин.

Мәҗлесе вәкаләттә улган шаһиде әүвәл – имаме җамигъ вә мөдәррис, мулла Зыяэддин Мөстәкыймев.

Мәҗлесе вәкаләттә улган шаһитлар:

Мөхәммәдхәсән Сәед Шакулов,

Касыймхан бине Габдеррәшид Акчурин.

Мәчкәрә беренче мәхәлләдә сакланмыш 1902 нче елгы 1744 нумерлы дәфтәрдә саклангучы тәүкилнамәдән дөрест күчердем – мәзкүр мәхәлләдә имам-хатыйб вә мөдәррис Әхмәдшәриф ибне мулла Мәхмүд әл-мәрхүм.

***

Бу тәүкилнамә тексты 13х21 см. зурлыгындагы куш кәгазьнең 1а битендә ачык көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуның тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1822т» шифры белән саклана. Аны китапханәнең директор урынбасары Ирек Һадиев 2002 елның 6 сентябрендә тапшырган.

Мәчкәрә – сәүдәгәр һәм химаяче Үтәмешевләр нәселе чыккан авыл, хәзерге Татарстан Республикасының Кукмара районында. Данлыклы Үтәмешевләр нәселе һәм аларның эшчәнлекләре турында матбугатта һәм фәнни хезмәтләрдә мәгълүматлар шактый басылды.

Монда исемнәре язылган Акчуриннар һәм Тимербулат Акчуринның кияве Мөхәммәтхәсән Шакулов турында мәшһүр сәүдәгәрләр һәм фабрикантлар нәселенә багышланган китаптан укып белергә мөмкин: Таиров Н. Акчурины. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 160 с.

## 111. Вәкаләтнамә. 1907 ел.

1907 нче елда 31 нче үктәбердә мин – Байсар вулысы Иске Кормаш упшыства[сы]нда Иске Кормаш авылының Галимәрдан Габделгалим угылы вирдем ушал вәкаләтнамәне үземнең җизнәм Хәбибулла Хәлилулла угылына шул хосус-да – сез хәзрәтләрнең прихутыңыздан тәзәввеҗ әмерендә тәгаллекъле эшләрне әда кылыр өчен.

Бәкъиә мәһәр ула калса, үз зиммәмә калмак шарты илән вәкил кылмакымның сикасенә мин Галимәрдан Габделгалим угылы тамга салдым.

Яшем 29-да булса кирәк.




*Вәкаләтнамә*

Вәкил кылмакка шаһитлар: Садреддин Габделхәким угылы, 2 нче – Әхмәдгали Сәйфулла угылы.

***

Бу вәкаләтнамә тексты 18х22 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1154т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Ижевск шәһәрендә яшәүче Ниязи Насретдиновтан 1994 елның 10 декабрендә бу юлларның авторы тарафыннан алынган иде.

Иске Кормаш – хәзерге Татарстан Республикасының Актаныш районындагы авыл.

## 112. Шартнамә. 1909 ел.

1909 нчы елда 18 нче майда без кем, Иске Шауты авылының Хәйретдин Хөснетдин и Госсаметдин Хөснетдин угыллары, икемез бер иттифакта булып, вирәмез ошбу условия язуыны шул ук авылымызның Миңнекаһир Кашшафетдин угылына үземезнең аяк очында булган ишек алдының[56] югары башы Зарифтан турылап, түбән башы түбәнге капкага чаклыны – ни булган ихатасы белән. Капкадан түбән утырткан бакча үзебезгә калачак, ташы һәм калачак.

Хакы – ун сум. Тукыз сум хәзер бирә, бер сум үз[е] чыккан чакта бирергә. Үз[е] чыккынча үземез файда күрәргә. Әгәр дә «үзем әрбир чәчәм» дип әйтсә, мәныг кыйлмаска. Үз гомеренә биләр өчен.

Хазир шаһит[лар]: Габделгазиз Малик угылы, Мөхәммәтшәриф Гыйнәятулла угылы.

Бән – Госсаметдин Хөснетдин угылы язып, кулым куйдым.

Дәхи Хәйретдин Хөснетдин угылы язып кулым куйдым.

Иске Шауты упшыствасы силскуй ыстарыста Шәмсетдин

[56] Бу сүз кульязмада «аландуң» дип хаталы язылган.

Мөхәммәтҗан [угылы] Мөләкев кәзәннуй пичәтем бастым: [*түгәрәк мөһер*][57].

***

Бу шартнамә тексты 18х22 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына, гарәп язуының тәгъликъ төрендә теркәлгән.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «801т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында 1998 елда Оренбург өлкәсенең Абдуллин районындагы Шалты авылында Гатия Шәмсетдиновадан алынган. Сакланышы уртача, бөкләнгән урыннарыннан кәгазе кисәкләргә аерылган. Хәзер реставрацияләнгән.

Иске Шауты – Иске Шалты авылы.

### 113. Җир сату турындагы язма. 1910 ел.

// *(24а кәгазь)* 1910 нчы елда 28 нче фибралда бән – Самар губернасы Богырыслан өязе Иске Сасна вулысы Камышлы авылының Миргалим Хәсәншаһ угылы саттым үземнең душыма тигән бер дисәтинә җиремне. Урыны – «Иген кулы»нда, Миңнәхмәд агайлар илән ызандаш. Унике сум бәһа илән // (*24б кәгазь*) Габделкадыйр Габделгани угылына, бер мәртәбә сачәр өчен.

Бән – юкарыда мәзкүр бәһа илән сатуымның растлыгына Миргалим Хәсәншаһ угылы разый булып тамгам салдым.

Вә һәм бән – Камышлы авылының силскуй ыстарыста Габдешшөкүр Габделкадыйр угылы юкарыда мәзкүр шартларның растлыгына инабәт өчен кәҗүннәй пичәтем бастым.

[57] Мөһернең рус телендәге язуы танылмый.

***

Җир сату турындагы бу документ күчермәсе берничә китап һәм башка язмалар тупланган җыентык эчендә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Җыентыкның гомуми күләме 17,5x22 см. зурлыгындагы 96 кәгазьдән гыйбарәт.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «773т» шифры белән исәптә тора. Сакланышы уртача. Ул китапханәгә Самара өлкәсенең Камышлы авылы (район үзәге) мәчетеннән 1996 елның 11 апрелендә бу юлларның авторы тарафыннан алынган иде.

## 114. Вәкыфнамә. 1910 ел.

1910 нчы ел.

Кече Кавал авылының Сәгъдеддин Сахиб угылы ошбу Коръән Кәримне вәкыф итеп куйдым Кече Кавал мәсҗиде җамигъга.

Мәсҗиддә һәркем укыса – рөхсәт. Вәләкин алып кайтырга вә алып китәргә рөхсәт юк.

Вәкыф иттем – Сәгъди Сахиб угылы.

***

Бу вакыфнамә тексты 17x25 см. зурлыгындагы кәгазьнең бер ягына ачык көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуның тәгъликъ төрендә язылган. Сакланышы уртача.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «4125т» шифры белән саклана. Ул китапханәгә Казан шәһәренең Каравай бистәсендәге «Нур-Ислам» мәчетеннән 2006 елның 29 мартында алынган.

Кече Кавал – хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районындагы авыл.

## 115. Җир сату турындагы язма. 1915 ел.

1915 нче елда гыйнварның 13 нче көнендә без ки, Самар губернасы Бөгелмә өязе Мәсгудь булысы Сөләй авылының Мөхәммәдкәбир Мөхәммәдшәриф угылы сатып бирдем авылдашым Исмәгыйль Миңнәхмәт угылына ярты дисәтинә җиремне, Камы як басуда, сабан ашлык сачәр өчен. Җиремнең урыны киртәгә башлашда.

Бәһасе булды 14 сум көмеш. Мәзкүр җиремнең бәһасен алып бетердем һәм раслыгына бән – Мөхәммәдкәбир Мөхәммәдшәриф угылы үз кулым илән тамгам  салдым.

Дәхи дә инабәт өчен без ки, Сөләй авылының силски ыстарыста Хафиз Ишнияз угылы, кәҗүнни пичәтем бастым[58].

Һәм ошбуның раслыгына Исмәгыйль Миңнәхмәд угылы язып кулым куйдым.

***

Документның күчермәсе булган бу язма 11х18 см. зурлыгындагы, бәет һәм башка текстлардан гыйбарәт дәфтәрнең 13а кәгазендә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «7462т» шифры белән саклана.

Сөләй, Камы (Камы Исмәгыйль) – хәзерге Татарстан Республикасының Әлмәт районындагы авыллар.

## 116. Даут Гобәйди васыяте. 1919 ел.

// *(1а кәгазь)* Иске Кызылъяр авылы гражданнарына

Туганнар, иптәшләр! Революциянең көчле дулкыннары үз агымы белән мине дә алып китте. Мин инде бүген үземнең 40 ел торган илемне, 13 елдан бирле һавасын иснәп,

---

[58] Мөһер урынына шартлы рәсем ясалган.

суын эчеп яшәдегем Иске Кызылъярны, андагы бөтен дусишләрем белән бергә үземнең армый-талмый эшләп аякка бастыра алдыгым мөкатдәс мәктәбен, башларын күккә чыгарып, мөселманлыкның бердәнбер галәмәте булган мәһабәт мәсҗидне калдырып чыгып китәм. Мине революциянең көчле дулкыннары үз агымына таба агызып, бик авырлык белән булса да, сездән вә балаларымнан аерылып торырга мәҗбүр итте. Хәзергә хуш, сау булыңыз!

Иптәшләр! Сез минем юлның нинди икәнен, дөньядагы партияләрнең берсенә булсын катнашмаганымны да яхшы беләсез. Минем бар тоткан юлым – халыкны укыту һәм агарту булып, мөнбәр башында сезгә чын белән ялган арасын аерып сөйләдем. Мөселманлыкның һәм Коръәнебезнең нәрсә икәнен аңлату, балаларыбызны да, вә гомумән, яшь буынны әдәп-тәрбиягә өйрәтү иде. Мин боларны булдырдым да инде, ахыры. Чөнки Иске Кызылъяр, тәрбия ягыннан караганда, башка һәрбер авылдан өстен тора.



*Даут Гобәйди*

Сез минем китүемнең сәбәбен дә нәрсә икәнен сорарсыз инде. Мин аңар кыскача гына шулай җавап бирәм: мин һичбер партиягә каршы бер эш тә эшләмәдем. Вөҗдан дигән нәрсә мине укыту эшенә кысылып, ахырында мәктәпләрне һәм алардагы уку-укыту эшләрен тикшерүче итеп куйды. Янәшә-тирәнең надан кешеләре укытучыларга дошман күзе белән карыйлар. Аларны – укытучыларны коммунист дип беләләр. Шуннан аңлашыла, алар икенче бер партиянең килеп керүе белән үк укытучыларга ябышып, кулларыннан килгән бөтен пычракларны эшләячәкләр. Аннары мин, сайланган көнемнән башлап, совет эшчесе булып танылганга, мин көчләнеп китәм. Китмәсәм мылтык, китсәм, әллә нинди мәшәкатьләр куркыта. Менә шуның өчен дә мин көчләнәм һәм көчләнеп китәм. Ходай миңа шулай язгандыр инде. Сездән вә балаларымнан аерылып китү бик кыен булса да, Ходайдан тиз кайтуны өмет итеп, моңлы Кызылъярга сәламемне куеп чыгып китәм. Хуш, сау булыңыз, иптәшләр!

Сез миннән файдадан башканы күрмәгәнсездер, инша Алла. Кайберләреңезне рәнҗеткән булсам, гафу итеңез мине. Гаилә вә балаларымны Аллага тапшырып вә сезгә ышанып калдырам. Сез үзеңезнең тәмле тел, йомшак сүзләреңез белән аларның көенечле күңелләрен җуатыңыз. Ходай сезгә вә сезнең балаларыгызга да рәхмәт күзе белән карасын.

// *(2а кәгазь)* Аһ, авыр миңа шушы ике юлны язуы!

Ышанам иптәшләр, сез аларны кеше капкасына тилмереп бардырмассыз. Аларның усаллар тарафыннан сүгелеп, кадерсезләнүләренә сезнең инсафлык вөҗданыңыз разый булмас. Сүземнең шул төшләренә җиткәч, бик авыр миңа. Кулларым язарга бармый!

Хуш, иптәшләр, сау булыңыз!

Мин сезгә нинди яхшы юл өйрәткән булсам, шуның буенча барып мәктәпләр алдында тезләнеңез! Коръәнне тугры аңлап, аның эзеннән кыл кадәр дә аерылмаңыз! Коръәнгә хилаф, дин исеменнән ялган сөйләүче, мөкатдәс динебезне карага буяучыларның сүзләренә ышанып, дөнья-ахирәттә бәхетсез булмаңыз!

Элекке кебек тату, бер сүздә яшәп, берегез өстеннән берегез донос ясамагыз, әләкләшмәгез. Күп мәртәбәләр әйткәнемчә, кулларыгызга агач кылыч алып, инкыйлапны тыныч кына уздырырга тырышыгыз!

Ходай тиз көннән күрешеп, шатланып яшәүне насыйп итсен. Амин.

Кулларыгыздан кысып, маңлайларыгыздан үбеп калам.

8 нче април 1919 нчы ел.

Гобәйди.

***

Бу васыятьнамә-мөрәҗәгатьнең тексты 20x29 см. зурлыгындагы ике кәгазьгә машинкада бастырылган.

Кульязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «1824т» шифры белән саклана. Сакланышы яхшы.

Истәлек китапханәгә Татарстанның Әгерҗе районындагы Тирсә авылында яшәүче Хуҗамөхәммәт Хәлиуллиндагы[59] кульязмадан 1990 елның декабрендә бу юлларның авторы тарафыннан күчереп алынган иде. Х.Хәлиуллиндагы нөсхәсе Факия исемле карчык тарафыннан 1975 елда күчерелгән булган.

Күренекле шагыйрь, мулла һәм педагог, китаплар һәм дәреслекләр авторы, тәрҗемәче Даут Гобәйдинең (1873–1919) әсәрләре, педагогик эшчәнлеге һәм колчакчылар кулыннан ерткычларча җәзаланып үтерелүе турында республика матбугатында аз язылмады. Милләтпәрвәр шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанның Даут Гобәйдигә багышланган шигыре дә бар.

Даут Гобәйдулла улы Гобәйди элекке Алабуга өязенең (хәзерге Әгерҗе районының) Кыдырлы авылында туган, Иж-Бубый мәдрәсәсендә укыган. Туган авылында балалар укыткан, кызлар мәктәбе ачкан. 1902 елда муллалыкка имтихан тотып, имам-хатыйплык шәһадәтнамәсен (указын) алган, 1905 елда күршедәге Иске Кызылъяр авылына мулла итеп сайлап куелган.

[59] Хуҗамөхәммәт Хәлиуллин – Иске Кызылъяр кешесе, танылган татар дипломаты Йолдыз Хәлиуллинның агасы (әтисенең бертуган энесе).

Шул елларда Даут Гобәйди рус классик әдәбияты үрнәкләреннән Гогольнең «Ревизор» һәм «Өйләнү» әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. Аның тәрҗемәсендәге бу әсәрләр 1905 елда Казанда нәшер ителгән. Төрек телендә басылган китаплардан файдаланып Кыдырлы мәктәбендә укыткан чорда язылган «Хифзыс-сыйххәт» исемле хезмәте 1907 елда Казанда басылып чыккан. Аның «Мөгаллимел-хөруф» исемле әлифба һәм уку китабы беренче мәртәбә Казанда 1909 елда дөнья күргән. Бу хезмәт кабат-кабат нәшер ителгән һәм 1918 елда аның бишенче басмасы дөнья күргәнлеге мәгълүм. Татар әлифбалары тарихын өйрәнгән галим Фатих Ибраһимов Д.Гобәйдинең бу әлифбасын югары бәяләде[60].

Мәгълүм булганча, 1911 елның гыйнварында мәшһүр Иж-Бубый мәдрәсәсе патша хөкүмәте тарафыннан туздырылып, мөгаллимнәре кулга алынган. Иж-Бубый мәдрәсәсе һәм аның җитәкчеләре белән тыгыз элемтәдә торган башка авыл муллалары һәм укытучылары, шул исәптән Даут Гобәйди дә, сак астына алынып, Сарапул төрмәсенә ябылган. Гаепләре исбат ителмәгәч, дүрт айдан соң Д.Гобәйди азат ителгән. Әмма конфискацияләнгән кульъязмалары һәм китаплары кире кайтарылмаган. Төрмәдән соң ул янәдән Иске Кызылъяр авылында мөгаллимлекне һәм муллалык вазифаларын дәвам иткән.

Марк Твеннан Даут Гобәйди татарчага тәрҗемә иткән «Принц вә теләнче» әсәре 1912 елда басылып чыккан. Бу китап 1919 елга хәтле өч мәртәбә нәшер ителгән. Даут Гобәйди 1913 елда Казанда «Шүрәле каргаган авыл» исеме белән шигырьләр җыентыгын бастырган. Җыентыкта аның халык әкиятләренә нигезләнгән мавыктыргыч сюжетлы, «Шүрәле» турындагы шигъри риваяте һәм шигырьләре урын алган.

Илдә совет хакимлеге урнашкач Д.Гобәйди Иске Кызылъяр авылының ул вакытта «Беренче баскыч халык совет мәктәбе» дип үзгәртелгән мәктәбендә укытучылык эшен дәвам иткән.

---

[60] Ибраһимов Ф. Белем Әлифбадан башлана. Тулыл., яңартылган басма. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 1994. – Б. 70–74.

Шул ук вакытта Сарсак-Омга волостенең Халык мәгарифе бүлеге мөдире һәм волость башкарма комитеты рәисенең урынбасары итеп билгеләнгән.

1919 елның апрель аенда Алабуга өязе авылларына көнчыгыштан Колчак гаскәренең Акмолинск полкы бәреп кергән. Чигенүче Кызыл гаскәрләр белән берлектә совет хакимияте әһелләре дә Вятские Поляны шәһәренә вакытлыча эвакуацияләнергә тиеш булган. Шунда китәр алдыннан, булачак афәттән хәвефләнгән Даут Гобәйди Иске Кызылъяр авылында ашыгыч рәвештә рухи васыятен язып калдырган.

Вятские Поляныга эвакуацияләнергә тиешле совет хезмәткәрләре белән киткән Даут Гобәйди, ни сәбәпледер (ихтимал, авылда калган җиде балалы ишле гаиләсе өчен борчылып), Алабугадан кире әйләнеп кайтырга карар иткән. Гади авыл укытучысы дигән документ белән, күп тикшерүләрне узып, Сокман авылына җиткән ул. Аңа ары бармаска киңәш иткәннәр, чөнки Тәбәрледә Латыйп бай Вахитовның ике катлы йортында колчакчыларның штабы урнашкан һәм алар бу авылда үзләрен аеруча кырыс тотканнар. Ләкин Гобәйди юлын дәвам иткән. Тәбәрле авылына кергәндә документларын тикшергәннәр – бар да тәртиптә кебек. Тәбәрленең элеккеге таныш мулласы Мулланәҗип Җәлалетдиневләрдә[61] табын артында хәл-әхвәл сөйләшкәч, Мулланәҗип хәзрәт тә Д.Гобәйдине үз өеннән чыкмаска үгетләгән. Ләкин Гобәйди, үгетләүләр һәм кисәтүләргә карамастан, Иске Кызылъярга кайтам дип кузгалган. Тәбәрле урамына чыгу белән аны тотып штабка китергәннәр. Документларын тикшергәч, җибәрергә торганда, совет хакимлеге тарафыннан эзәрлекләнүгә дучар булган бер бай кеше Даутның кем икәнлеген ак офицерларга әйтеп салган. Совет хезмәткәре икәне ачыкланганнан соң, колчакчылар аны рәхимсез рәвештә кыйнап, җәзалап, яланөс һәм

---

[61] Бу мулла турында кыскача мәгълүмат биреп, совет чорында эзәрлекләнүен «Татар археографиясе» сериясенең 29 нчы китабында язган идек («Утызынчы елларда...»: халык тормышының фаҗигале сәхифәләре / төз. Р.Мәрданов. – Казан, 2022. – Б. 126–129.

яланаяк хәлендә атка тагып, язгы карлы-бозлы урамнар буйлап йөрткәч, каравыл йортына бикләп куйганнар. Икенче көнне, 1919 елның 19 апрелендә вәхшиләрчә җәзалап (күзләрен чокып, колак-борыннарын, кул-аякларын кылыч белән чабып-турап һәм ахыр чиктә атып) авыл зираты каршындагы юл буенда үтерәләр. Аклар аның үле гәүдәсен күмәргә дә рөхсәт итмәгән. Фәкать төнге караңгылыкта Тәбәрле авылының берничә кешесе Д.Гобәйдине зират кырыена җирләп куйганнар.

Бөтен гомерен халыкны аңлы-белемле итәргә тырышкан, белем-мәгърифәт тараткан хөр һәм ирекле тормышта яшәүләрен ихлас күңелдән теләгән, шигырьләрендә дә гаделлеккә, аң-белемгә, хөр яшәүгә дан җырлаган мәгърифәтче, мулла һәм шагыйрь Даут Гобәйдинең тормышы шулай фаҗигале өзелгән.

Унтугызынчы елның дәһшәтле-канлы 19 апрель көнендә якын-тирә төбәктән Тәбәрле авылына китерелеп Сарсак-Омга волостенең башкарма комитеты рәисе Иван Молчанов, Яңа Аккуҗаның совет яклы агитаторлары Фәхретдин Баһавиев белән Азин дивизиясендә политрук булган Һидиятулла Габдуллин, Олы Кибья авыл Советы хезмәткәре Александр Кропочев һәм Боголюбово авылының совет яклы Иван исемле кешесе дә нәкъ шулай ук коточкыч җәзалап үтерелгәннәр. Бер көн эчендә алты кешене корбан итү вәхшәтен авыл халкын урамга куып чыгарып, халык күз алдында башкарганнар.

Колчакчылар бу яклардан куылганнан соң авылдашлары Даут Гобәйдине Кыдырлы авылы зиратына алып кайтып җирләгәннәр.

Даут Гобәйдинең мөрәҗәгать-васыяте Әгерҗе ягы авылларында кулдан-кулга гарәп язуында күчерелеп таралган. Фатих Ибраһимов Даут Гобәйдигә багышланган мәкаләсендә бу васыятьнең текстын бастырган иде[62].

Фатих Ибраһимов мәкаләсендә васыять текстының кайдан алынган булуы әйтелмәгән. Ләкин журналда чыккан текст

---

[62] Ибраһимов Ф. Иж-Буби шәкерте // Казан утлары. – 1991. – №9. – Б. 180–181.

белән Милли китапханәдә саклана торган күчермә бер-берсен тулыландыралар. Китапханәдәге күчермәдә дингә бәйле урыннары бераз төшереп калдырылган. Аның протографы 1975 елга – совет атеизмы чорына караганлыгын искә алганда, дингә бәйле кайбер сүзләрнең һәм җөмләләрнең кыскартылу сәбәбе аңлашыла.

Бу китапта тәкъдим ителгән текст – журналда басылган вариант белән чагыштырып тулыландырылды.

«Казан утлары»нда басылган васыятьнең төп чыганагында датасы 1919 ел диясе урынга ялгыш 1920 ел дип теркәлүе, Ф.Ибраһимов язганча, Даут Гобәйдинең рухи халәтенә күрә, сизмәстән җибәргән хатасы[63]. Ләкин безнең тарафтан күчереп алынган нөсхәдә елы дөрес – «1919 ел» иде.

## 117. Гатаулла Габбаси васыятьнамәсе. 1920 ел.

//*(1а кәгазь)* Васыяте габдеззәгыйфь Гатаулла ибне Нәҗмеддин әл-Габбаси әл-мохтаҗ иля рәхмәти Раббиһи әл-Гафурур-Рәүф

Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим.

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.

Әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин вәл-гакыйбәтү лил-мөттәкыйн вәс-саләтү вәс-сәлләмү галә сәйидина Мөхәммәдин вә али сәйидина Мөхәммәдин вә алиһи вә әсхабиһи әл-кирам.

Вә бәгъдә, шәһадәт идәмән вә икърар вә тасдыйк кыйламән – әшһәдү әл-лә иләһә иллә Аллаһу вәхдәһү лә шәрикә ләһү

[63] Әлеге мәкаләдә башка төгәлсезлекләр дә бар. Мәсәлән, мәкалә авторы Д.Гобәйдине 1873 елда дөньяга килгән дип язса да, аңа 1919 елда 36 яшь булган дип өч урында (180–181 битләр) ялгыш күрсәткән. (Дөресе – 46 яшь). Иж-Бубый мәдрәсәсенең туздырылган вакыты чынлыкта 1911 елда булган хәлдә, мәкаләдә 1912 ел дигән дата әйтелгән (179 бит). Гобәйди кебек үк, колчакчылар тарафыннан җәзалап үтерелгән Молчановның милләте мәкаләдә «мордвалы» дип ялгыш язылган. Хакыйкатьтә, ул күршедәге рус авылының рус кешесе булган һәм, гомумән, бу төбәктә мордва халкы элек тә яшәмәгән, хәзер дә юк.



3415т
ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ КУЛЪЯЗМАЛАР ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ

وصية عبد الضعيف عطاء الله ابن نجم الدين العباسي
المحتاج الى رحمة ربه الغفور الرؤف
اعوذ بالله من الشيطان الرجيم بسم الله الرحمن الرحيم الحمد لله رب العالمين والعاقبة
للمتقين والصلوة والسلام على سيدنا محمد وعلى آل سيدنا محمد وآله واصحابه
الكرام وبعد شهادة ايده من واقرار وتصديقا قيلامن اشهد ان لا اله
الا الله وحده لا شريك له له الملك وله الحمد يحيي ويميت وهو حي لا يموت
بيده الخير وهو على كل شيء قدير واشهد ان محمدا عبده ورسوله الله احد
الله الصمد لم يلد ولم يولد ولم يكن له كفوا احد ليس كمثله شيء وهو السميع
العليم يا رب ايمانمده شكم يوقدور حقا وتحقيقا مؤمن من اگر بندن
بلب يا بلمي كفر وگناه صادر اولديسه توبه ايتديم ورجوع قيلدوم قايتدم
وپيغمبرمز محمد مصطفى صلى الله تعالى عليه وسلم الله تبارك وتعالى ننك حضور معنويه سندن
هر نه كلتر ديسه ايناندوم وقبول ايتديم حق دور الله تعالى دن كلن هر نرسه كه
الله تعالى ننك مرادى اوزره ايناندوم وقبول ايتديم پيغمبرلره وپيغمبرلردن كلن
هر نرسه كه على نبينا وعليهم الصلوة والسلام وپيغمبرلرننك مرادلارى اوزره ايناندوم
وقبول ايتديم پيغمبرلرننك اوّلى آتامز آدم عليه السلام وآخرى محمد مصطفى صلى الله
عليه وسلم بو ايكيسى ننك آراسنده نه قدر پيغمبرلر ورسوللر وكتابلار وار ايسه [illegible]
سينه ايناندوم وقبول ايتديم . ودروندن دلدن ديه رمكه لا اله الا الله محمد
رسول الله اشهد ان لا اله الا الله واشهد ان محمدا عبده ورسوله
ما امرني الله تعالى قبلته وما نهاني الله تعالى عنه انتهيت عنه

*Гатаулла Габбаси васыятьнамәсе*

вәл-мәлик вә ләһү әлхәмдү йухи вә йәмит вә Һуа Хәййү лә йәмүт би-йәдиһил-хәйру вә Һуа галә көлли шәйин Кадир. Вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү. Аллаһу Әхәд, Аллаһус-Самәд; Ләм йәлид вә ләм йүләд; вә ләм йәкүлләһү күфүән Әхәд. Ләйсә кә-мислиһи шәйүн вә Һуа әс-самигуль-Галим.

Йа, Рабби, иманымда шигем юкдыр. Хаккан вә тәхкыйкан мөэминмән. Әгәр бәннән белеп йә белми көфер вә гөнаһ садир улдисә, тәүбә иттем вә рөҗуг кыйлдым – кайттым. Вә пәйгамбәремез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу Тәгалә

галәйһи вәссәлләм Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең хозуре мәгънәвиясеннән һәр нә килтердисә, инандым вә кабул иттем. Хактыр, Аллаһы Тәгаләдән килән һәр нәрсәгә, Аллаһы Тәгаләнең морады үзрә инандым вә кабул иттем. Пәйгамбәрләрә вә пәйгамбәрләрдән килән һәр нәрсәгә галә нәбийина вә галәйһим әссаләте вәссәллам вә пәйгамбәрләрнең морадлары үзрә инандым вә кабул иттем. Пәйгамбәрләрнең әүвәле – атабыз Адәм галәйһиссәлам вә ахыры Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәлләм. Бу икесенең арасында нәкадәр пәйгамбәрләр вә рәсүлләр вә китаплар вардыр – барчасына инандым вә кабул иттем.

Вә дәрун дилдән диярәм ки, лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәдән рәсүлуллаһ, әшһәдү әл лә иләһә вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү. Ма әмараниһи Аллаһу Тәгалә кабилтүһү вә ма нәһанийәһи Аллаһу Тәгалә ганһү интәһәйтү ганһү.

// *(1б кәгазь)* Әмәнтү билләһи вә мәляикәтиһи вә күтүбиһи вә рәсүлиһи вәл-йаумил-ахири вәл-кадәри, хәйриһи вә ширриһи мин Аллаһу Тәгалә вәл-бәгъси бәгъдәл-мәүт.

Әшһәдү әл лә иләһә иллә Аллаһу вәхдәһү, лә шәрикә ләһү вә әннә Мөхәммәдән рәсүлуллаһ, вә әннәл-җәннәтә вән-нарә вәс-сиратә вәл-мизанә вә сөаләә Мөнкир вә Нәкир вә газабел-кабри лил-кяфирин вә ли-бәгъзи госсатил-мөэмининә вә тәнгыйми әһлит-тагати фил-кабри би-ма әрадә Аллаһу Тәгалә көлләһә хаккун. Вә әннә әс-сагатә атийәтүн лә рәйбә фиһа вә әннә Аллаһә Тәгалә йәбгасү мән фил-кобури.

Радыйәтү билләһи Раббән вә бил-ислами динән вә би-Мөхәммәди салләллаһу галәйһи вәссәлләм нәбийән вә бил-Коръәни имамән вә бис-саләти фәраизән вә бил-Кәгъбәти кыйблатән вә бил-мөэминини ихванән. Рабби Аллаһу, лә иләһә иллә Һуа вә Һуа Раббил-гаршил-газыйм.

Игътикадда мәзһәбем әһлес-сөннәт вәл-җәмәгать, имам Әбел-Мансур Матуриди, гамәлдә мәзһәбем имам әгъзам Әбү Хәнифә Ногман бине Сабит мәзһәбе, кыйраәттә шәйхем Гасыйм Руәйси. Адәм галәйһиссәлам зөрриятеннәнмен. Хаккан

вә тәхкыйкан мөэминмен. Әлхәмде Лилләһи галә нигъмәтил-ислам вәш-шөкрү Лилләһи сәгадәтил-иман.

Хак Тәгалә җөмләмезне иман үзрә сабит әйләп, ахыр нәфәстә хөсне хатимә илә хәтем итә, йа Рабби истикамәт, гафу, гафиять вә тәүфыйк вә хөсне хатимә мөяссәр кыйл вә сүи хатимәдән сакла, йа Рабби, йа Рабби, йа Рабби! Амин, би-хөрмәти нәбийүкә хәйрүл-мөрсәлин салләллаһу галәйһи вә галә алиһи вә әсхабиһи вә әүлядиһи вә әзваҗиһи вә итбагыйһи әҗмәгыйн вәсәлләм.

Мохтаҗ би-рәхмәти пәрвәрдигяре ләтыйф будыр кем, хәзрәти пәрвәрдигярем Җәллә Җәляләһүдә илтимасын вә дәрхаст кыйламән кем, үзенең нигъмәтләрен үзәремә тәмам әйләп, иманымны сабит кыйлды. Бу гата әйләгән нигъмәтләрен бакый әйләп, зиядә әйләгәй иде.

Бу дөньяи гаддар вә мәккяр фә рәйбә диһәндә вә мәгъруре кәнәндәи би-вафадан бәндә вә фәрман бәрдарлеге тәксыйратемнән пошиман улып, җәнабе мәгъфирәт пәнаһигә тәүбә илән рөҗуг идеп, гафу вә мәгъфирәт вә рәхмәтеннән өмиддарәм. Зирәки бонлары нәүмизлектән мәныг кыйлып // (*2а кәгазь*) әйтәдер: «Лә тәкънәтү мин рәхмәти Аллаһи» дәю, бәс өмидләремезне заигъ кыйлмас. Вә тәүбәләремезне кабул идәр ки, вәгъдә кыйлды: «Вә Һуа әлләзи йукаббилүт-тәүбә гань гыйбадиһи» дәю. «Вә йәгъфу ган әс-сәйәәт» дәю гафу-ыннан хәбәр бирде. Вә нәби рәхмәтене салләллаһу галәйһи вәссәлләм безләрә ирсаль әйләде, чөнанча хәбәр вирәдер: «Вә ма әрсәлнәкә илләә рәхмәтән лил-галәминә» дәю.

Вә бәгъдә, сез – әһле гыялым, вә хөвиш әкърибам вә дуст-ларым!

Ходаем Тәгалә һәммәләремезгә үзе ризасы улан шәйләрә тәүфыйк рәфыйк кыйлгай, вә наморзыйсы улан әшья дүр әйләп, гасыймәт пәнаһында саклагай иде. Белеңез һәммәнең гакыйбәте – үлмәктер. Бәни Адәмнән һичкемгә аннан чара юктыр, вә һәм белеңезләр – изге гамәлләрә савап вә Хак Тәгаләнең ризалыгыдыр. Вә явыз гамәлләрә газап вә са-хыйтыдыр. Бәс кирәктер кем, үзләреңезә тәкъваны шигарь

әйләп, салихлар сохбәтен ихтыяр идеп, фасикъ вә бәдкярләр сохбәтеннән иҗтинаб идәсәз. Ул нигъмәтләре ки Хак Тәгалә сезләрә гата кыйлгандыр. Бәндәләрегә иттифак вә ихсан идеп, сәхавәтне вә заде ахирәтне үзләреңезә пишә кыйласыз вә нәсыйхәт вә никхаһлыгы бер-береңездән, бәлки гаммәи мөслиминнән дәригъ боермай, әмре мәгъруф вә нәһи мөнкәрне заигъ куймаясыз. Бер-береңез ма бәенендә хак вә хокукта тәсамих идеп, сыйләи рәхмен пәйвәстә саклап, өмуре динидә мөхтәлиф вә мөнхәриф улмай, өмуре исламиядә бәҗәд уласыз. Галәл-махсус әркяне пәнҗгянәи исламы бәҗа кыйласыз, ягъни шәраиты иман вә исламы яхшы белеп вә биш вакыт намазны вакытларында җәмәгать илән әда кыйлып, биля гозер вә шәргый җәмәгатьтән тәхәллефе рәва күрмәясез.

Әмвале наимә вә әнгаме саимәдән зәкяте мәфрузәтне, бер дә калдырмаенча, вирәсәз. Маһе шәрифтә әнвагы гыйбадәт вә хәер-ихсан илән мәшгуль улып, мәнаһидән иҗтинаб үзрә рузәне камил тотып, безне догаи хәйр илә йад кыйласыз. Ата-ана хакыны, вә хатыннар, вә хезмәткәрләр, вә күршеләр хакын ригая әйләп, мәзлумләрә носрәт, вә ятимләрә шәфкать вә гарибләрә ихсан әйләп, вә голәма вә олуглара тәгъзыйм вә кечекләре ригая әйләп // (*2б кәгазь*) үткән хөвиш вә әкърибайә зиярәт кыйлучы буласыз. Вә һәр көн тилавәте Коръәннән гафил улмай, шәбе хәерлек кыйлып, тәһәҗҗед үтәмәке ганимәт беләсез.

Мөмкин кадәре ишракъ намазы вакытыгача мәсҗидтән яки намазҗайдан купмаясыз. Вә голәмаи дин хозурында һәмишә булып, тәхсиле голүм үзрә мәшгуль уласыз, фасикъ вә бәдкярләр мәҗлесеннән дүз улып, салих вә мөттәкый илән һәм сохбәт уласызлар.

Икътидарыңыз улса, моталәгаи көтеб илә мәшгуль уласызлар. Гарәби фә фарси китапларын моталәгагә кадыйр булмасаңыз, төрки вә руми китапларыга нәзар кыйласызлар. Шигырь вә шаһнамә вә җәңнамәдән ихтираз идәсез – анларның файдасыннан зарары күбрәктер.

Кәсеп кыйлдыкта кәсепкә мөтәгалликъ мәсьәләне игътибар иде, хәрам-бозык кәсептән ерак буласыз.

Сезләр өчен васыятем вә нәсихәтем ошбудыр, вә һәм ризалыгым ошбундадыр.

Моның бәгъдендә белеңезләр кем, Хак Җәллә вә Галәнең мокаррар әҗәле бу бәндәи гасый мокассиргә килсә, минем мәтрүкәмнән тәҗһиз фә тәкфинем вә дәфенем өчен сарыф идәсез би-гайри ифрат-тәфрыйт вә би-гайри исраф вә тәкътир.

Моның бәгъдендә зиммәмдә улан адәмиләр хакларын (кем дәфтәрләрдә улыр) яки бәр-вәҗһи шәргый, дәгъваи шәргыя вә хөкеме хаким илә бу фәкыйрьдән алачакларын исбат кыйлынса, әлбәттә, бирәсез вә һәркемгә үземнең мокассирлегемнән иза вә хәкарәт улашдырган улсам, минем җанымдин ризалык, зинһар, сүммә зинһар, эстәгәйсез.

1920 нче елда 21 нче априлдә. Гакылым сахих вакытта үземнең ихтыярым илә васыять идәмән – минем өчен сиксән мең сум акчадан сарыф идәсез. Шул сиксән мең сумнан ун мең зиярәт сәдакасы, кабер караучыларга һәм өюгә кайткач өләшергә. Биш мең хисбәтән хәтем укучы хәзрәтләргә.

Кабер сәдакасына өч көнгә өч сарык.

Дүр өчен бер фәкыйрь әһел булган кешене ултыртырсыз. Үземезнең мөәзинне сәдакасыны биреп риза идәрсез.

Кышкар Гомәр мөәзин тәнемне тотып юучы булыр, үземезнең мөәзин булышчы булыр.

Шул сиксән меңнән алтмыш мең калама, артыграк калама – фидиямнән хисап кыйлып, тиешле карендәшләремезгә бирерсез. Тәфсыйлен, форсат булса, әйтеп калдырырмыз, насыйп булса.

***

Бу текст 17,5x22 см. зурлыгындагы ике кәгазьгә көрән төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы уртачадан түбән: кәгазьләрнең бөкләнгән урыннары аерылып чыгу дәрәҗәсендә.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «3415т» шифры белән саклана. Ул китапханәнең 2010 елда (июль аенда) Әтнә районына оештырылган архео-

график экспедициясе вакытында Ташчишмә авылында яшәүче Гөлсем Габбасовадан алынган.

Ишракъ намазы – иртә белән кояш күтәрелгәч укыла торган намаз.

Тексттагы «калама» сүзе – «каламы» дигәннең җирле сөйләм үзенчәлеге.

Кышкар – хәзерге Татарстан Республикасының Арча районындагы авыл.

Гомәр мәзин – Кышкар авылының бу мәзине 1930 нчы елларда нахакка репрессияләнгән, Архангельск шәһәренә сөрелгән һәм шунда һәлак булган.

### 118. Мәстүрә Фазлулла кызы васыятьнамәсе. 1920 ел

// *(1а кәгазь)* Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим.

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.

Әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин вәссаләте вәссәлләм галә сәйидина Мөхәммәдин вә алиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн.

Әмма бәгъдә, фә-һәза ма әүсат биһи әл-хәкыйрәтүл-мөзнибәти әл-могтәрифәтү бил-хәҗәзи вә тәкъсыйри Мәстүрә ибнәтү мулла Фазлулла әл-Кимеви әл-Казани фә-ән әшһәдү әл-лә иләһә иллә Аллаһу вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү, әмәнәт билләһи кәма васфи биһи нәфсиһи фи китабиһи би-әсмаиһи вә сыйфатиһи вә кабәләт җәмигъ әхкямиһи, әмәнтү билләһи вә мәляикәтиһи вә күтүбиһи вә рәсүлиһи вәл-йаумил-ахири вәл-кадәри хәйриһи вә шәрриһи мин Аллаһи Тәгалә вәл-бәгъси бәгъдәл-мәүти вәл-җәннәти вән-нари вәс-сөали вәл-хәшәри вәл-мизан вәл-күтүб вәс-сыйрати вәл-хәүзый вәл-хисаби көлләһү хаккыйн вә әннә әс-сагатә атийәтүн лә рәйбә фиһа вә әннә Аллаһә Тәгалә йәбгасү мән фил-кобури. Радыйәт билләһи Раббән вә бил-ислам динән би-Мөхәммәди салләллаһу Тәгалә вәсәлләм рәсүлән вә нәбийән вә бил-Коръәни китабән вә имамән вә бил-Кәгъбәти кыйбләти вә бил-мөэминини ихванән вә игътикад әннә тарика әһлис-сөннәт вәл-җәмәгати хаккун вә ма сиваһа батыйли вә гыйштү

галә һәзаль-игътикади вә әрҗү мин Аллаһи Тәгалә ән йәхтимә әмрәна бис-сәгадәти галә һәзаль-игътикади вә ән йәхшүрәна мәган-нәбийинә вә салихинә вә әш-шөһәдәи вәс-садыйкыйнә вә хәсүнә уляикә рәфыйка, амин, йа мөҗибәл-модтаринә.

Мин – фәкыйрә-хәкыйрә, гасыя Мәстүрә ибнәтү мулла Фазлулла васыять кыйлдым әүлядыма вә кардәшләремә итти-баг вә дуст-ярыма васыятемдер.



*Мәстүрә Фазлулла кызы васыятьнамәсе*

Хак Тәгаләйә бәндәлектә вә рәсүле әкрәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәс-сәлләмгә өммәтлектә садыйк улып, Хак Тәгаләнең нәваһиләреннән иҗтинаб идеп, әмре шәрифләрен бәрҗа кыйлып, дине исламда нә мәшруг вә мәэмүр бардыр – һәрберсенә ба-хөлус кылып, тән вә җан илә итагать кыйлып, хосусы фәраизы хәмсә вә важибларны калдырмай, вакытында әда кыйласыз вә бер-берегез арасында хөсне могашәрәт вә нәсыйхәт илә улып, әмре мәгъруф вә нәһи гань әл-мөнкәр илә улып, гокук вә һиҗр вә бәгъзе вә годавәт би-вәҗһе шәргый кыйлмаясыз вә һәр эшегездә, кавелдә вә фигыльдә вә гыйбадәт вә мөгамәләттә Хак Тәгаләнең боерыгынча вә рәсүле әкрәм Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәлләмнең сөннәте илә вә сәхабә-ү табигыйн вә сәләфе кирам вә әһлес-сөннәт вәлҗәмәгать тарикы илә уласыз. Вә нидер бидгать вә зыйлләт вә хилафе шәргъ вә дине исламдыр – анлардан ерак уласыз.

Вә әуса би-ма әуса биһи Ибраһим вә Ягъкуб галә нәбийина вә галәйһим әс-салəте вәссәллам кә-ма калә Аллаһу Тәгалә фи Кәлямиһи әл-кадими «Вә вәсса биһа Ибраһиму бәнийиһи вә Ягъкуб: «Йә, бәнийә! Иннә Аллаһә әстафә ләкүмү әд-динә фәлә тәмүтүннә иллә вә әнтүм мөслимунә», «Йә, әййуһа әлләзинә әмәну әт-таку Аллаһә хакка такатиһи вә лә тәмүтүннә иллә вә әнтум мөслимун».

Вә бәгъдә васыятемдер әүлядемә, әһле иттибагына вә кардәшләремә вә саир дуст, хөвиш вә талибә вә саир ихване диния – һәрберегез миннән разый буласыз. Хакыгезне хәләл итәсез каулән вә фигълән вә малән, гайбәтегез сөйләнгән би-вәҗһе шәргый орышылган вә сүгелгән вә малегез газаб кыйлынгандыр – һәрберсеннән без фәкыйрәдән разый булып, хакыңызны хәләл идәсез. Зинһар, йауме җәза вә хәшәрдә мин фәкыйрәне рисвай кыйлмагез. Әҗерегез заигъ булмас, хак дәгъва кыйлучыларны бәһри вәҗһи риза кыйлырга иҗтиһад идәсез, догагездән ташламаясыз, йадегезә килтереп, бер «Фатиха» вә «Ихлас» укып, рухымы бәхеш идәсез.

// *(1б кәгазь)* Вә мин бәгъдә васыятемдер – бурыч вә карзларым булса, һәрберсен кәнд тәрикәмнән даинлара әда кый-

ласыз. Тәрикәм кяфи булмас, зинһар, разый улсыннар. Бәнем өчен гозер-нияз идеп, ризалык вә хәләллык таләп итәсез. Зинһар, йауме хәшәрдә мөаххидә кыйлмасыннар, әҗерләре заигъ улмас.

Вә гарият нәрсәләрне сахибләренә биля тәваккыф вә ля мөнакашә кайтарып тапшырасыз, мөсаһәлә кыйлынмасын.

Вә мин бәгъдә васыятемдер – кайчан мәрызым мөшәддәд булып, мөкаддәре вакыт ирешеп, мохтазирә булсам, тәлкыйне шәһадәт вә тәүбәдә мөсаһәлә кыйлмаясыз. Вә «Сүрәи Ихлас» укымага йадыма килтерәсез. Вә «Аллаһуммә әгыйнни галә мөнкәратил-мәүти вә сәкәрәтил-мәүти»не укымага тәзкир идәсез. Вә вөсгате рәхмәт вә рижа вә гофранә дәләләт идән айате вә әхбарне тәзкир идәсез. «Иннә Аллаһу Гафурур-Рәхим», «Иннә Аллаһә йәгъфиру әз-зөнубә җәмиган», «Вә рәхмәти васыйгати көллә шәйин» аятьләре кеби, «калә Аллаһу Тәгалә мән галимә әнни зу кодрәтин галә мәгъфирәтиз-зөнуби гафәртү ләһү» хәдисе кеби вә мөхтәзирә хәлемдә соләхалардан бәгъзесе тәлкыйне шәһадәт вә тәүбә вә бәгъзесе кыйраәте сүрәи «Йасин» вә бәгъзесе Хак Җәлли вә Галәдән бу фәкыйрә өчен иманда сәламәт вә шәрре шайтаннан нәҗат таләп итеп, бәнем хөсне хатимә вә иман илә ахирәтә китмәгем илә дога илә мәшгуль улмакларыны кәмаль гозер вә нияз илә үтенәмен.

Вә бәгъдә кайчан җане газизем бәдәне зәгыйфемнән аерылса, тәкфин вә тәҗһиз вә дәфене бил-мәгъруф идәсез.

Әгәр тәрикәм, бурыч-карзларымдан зиядә улса, фидияи салаватин вә саумин вә саири ма вәҗәбә минәл-кәффарати вән-нөзүри вә гайриһаларны бирәсез.

Әгәр тәрикәм бурычларымнан зиядә булмаса яки фидиямә кяфи булмаса, бер адәмнән карз алып, бу муафыйк вәҗһе шәргы шәрифтер кыйлдырасыз, мөсаһәлә кыйлмагез. Мән кян фи хаҗәти ахиһи кян Аллаһу фи гауниһи.

Вә Коръән хәтем кылдырмакны үтенәм.

Әүляд, әкариб, дуст-ярыма гозеремдер – догаи сәдака илә йад идәсез. Хосусан, фи йауми мәүтин вә әүвәлү ма нәзәләт фиһи фи кабри илә җомгати.

Бу васыятьләремне әүляд, әкариб, дуст-ярыма бәрҗа кыйлмакларыны камил үтенеп гозер кыйламын.

Бу васыятьнамәне яздырдым бән мөвассыяи мәзкүрә.

Гафәрә Аллаһу лә-һума вә җәгалә ахирһу хәйрән мин әүвәлиһи вә әстәгъфируллаһи Тәгалә мин көлли зәнбин әзнәбти гамдән әү хатаән сиррән әү галә ниятән вә әтүбү иләйһи минәз-зәнби әлләзи әгъләмү вә минәз-зәнби әлләзи лә әгъләмү. Иннәкә әнтә галләмүл-гойуб вә гаффарез-зөнуб вә саттарел-гойуб.

19 зилкагъдә 1338 сәнәи һиҗри, 4 август 1920 сәнәи милади.

***

Бу васыятьнамә тексты 22х36 см. зурлыгындагы кәгазьнең ике ягына кара төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы яхшы (реставрацияләнгән).

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2020т» шифры белән саклана.

Васыять иясенең мулла Фазлулла әл-Кимеви әл-Казани кызы Мәстүрә дип язылганына карата искәрмә таләп ителә. Хәзерге Әтнә районының Күлле Киме авылында яшәгән мәшһүр укымышлы Фазлулла хәзрәт турында Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» һәм Р.Фәхретдиннең «Асар» хезмәтләрендә язылган. Аларда исеме Фазыл бине Ибраһим әл-Кимеви диелгән, «Асар»да ир балаларының гына исемнәре күрсәтелгән. Әлеге васыятьнең иясе менә шул Фазлулла мулланың кызы булган дип аңлашыла.

## 119. Йорт сату турындагы язма. 1922 ел.

Бер мең дә тукыз йөз егерме икенче елда гыйнварның утыз беренче көнендә Әбдери карьясенең Мортаза Мостафа угылыннан аның хәләле Миңҗамал Газиз кызы варис уларак разый булып, Гайнетдин Габделгазиз [улының] ызбасын сатты.

Урта мәхәллә мәсҗиденә Гайнетдин Габделгазизовның

угланнарыннан кайтып низаглашса, Мортаза Мостафа угылы һәм хәләле Миңҗамал үз ызбаларын бирергә разый булып, кулым куйдым: Мортаза Мостафин.

Һәм Миңҗамал Габделгазизованың сүзе шулдыр: ызбаны тирә-күршеләре ташып бетергәнлектән бимаза булып, Миңҗамал Габдегазизова разый булып, кулым куйдым: Миңҗамал Газизова.

Янә дә боларның разый булып сатканлекләреннән шаһит булып һәр икемез кулымызны куйдык.

Язылды бу условия гыйнварның 31/I нче йаумендә 1922 нче сәнәдә.

Һәм хакы тугрысында мәгълүм кыламын – 30 фунт арыш оны һәм 8 фунт тоз, 10 фунт алабута оны. Шуларга разый булып саттым: Мортаза Мостафин.

***

Бу текст язылган кулъязма бит 10х26 см. зурлыгында. Ул ачык шәмәхә төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә теркәлгән. Сакланышы уртача.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «507т» шифры белән саклана.

Әбдери – хәзерге Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районындагы авыл.

## 120. Могаһадә. 1923 ел.

// *(1а кәгазь)* 1923 нче ел 25 нче июль.

Могаһадә

Мин, түбәндә кул куючы, Галимҗан Закир угылы Җамалетдинев 1921 нче елның җәендә атам, кышында анам үлеп, круглый ятим булып калганнан соң, башта Бәйрәкә волосте Сафон хуторында приютта, аннан Себер Архангел приютында торып, Бөгелмәгә кайтарылып, аннан авылга йибәрелгәч, 1923 нче елның 25 нче июлендә Фәхретдин Хадимиевдә торырга туры килгәнлектән, Бәйрәкә сельсове-




*Могаһадә*

тында мәгълүм булу өстенә, аның илә үзара могаһадә ясадык.

Могаһадә шул рәвешле: Фәхретдин Хадимиев әтәй берлән бертуган абзый булганлыктан, приюттан кайтуым илә мине дүрт сыйныфлы эш мәктәбен тәмам иткәнче укытырга, өст-баш киемнәрен биреп, үз симиясе илә бергә ашау-эчү ягын тәэмин кыйлуны үз өстенә алып, дүрт сыйныфлы эш мәктәбен тәмам иткәннән соң янәдән сөйләшеп, тормыш турын хәл кылырга булдык. Хәзергә әле мин аның симиясе һәм эшчесе түгел. // (*1б кәгазь*) Фәкать анда ашау-эчүләр илә берлектә квартирдә генә торам.

Шул арада булган могаһадәнең дөрестлеге өчен мин – Галимҗан Закир улы Җамалетдинев үз кулым илә имза кылам: Галимҗан Закир.

Шулай ук мин – Фәхретдин Хадимиев – Галимҗан Закир улын башка торыр, тәрбияләнер урыны булмаганлыктан, тәрбиягә алып, дүрт сыйныфлы эш мәктәбен тәмам иткәнче өст-баш киемнәрен бирергә, ашау-эчү ягын тәэмин кылырга өскә алдым. Дүрт сыйныфлы эш мәктәбен тәмам иткәннән соң янәдән асрау-асрамау турында сөйләшергә юл ачык калдырыла.

Югарыда язылган могаһадәләрнең дөрест булуы өчен мин Фәхретдин Хадимиев имза кылам: Фәхри Хадими. Галимҗан.

Шушы югарыда язылган гражданнарның имзаларын хаклый Бәйрәкә авыл киңәше, дөресенә кулъязмасы белән мөһерен баса. [мөһер].

Башлык: М.Ахмитев.

Язгы: Зәки Тинбаев(?).

***

Бу могаһадә тексты 20х12,5 см. зурлыгындагы кәгазьнең ике ягына шәмәхә төстәге язу карасы белән, гарәп язуының нәсех төрендә язылган. Сакланышы канәгатьләнерлек.

Кулъязма Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «7213т» шифры белән саклана. Аны китапханәгә Казан шәһәрендә яшәүче Галия Хадмиева 2003 елның 17 мартында тапшырды.

# СҮЗЛЕК

*агяһ* – белеп тору, хәбәрдар булу

*айат вә әхбар* – аятьләр һәм хәбәрләр (хәдисләр)

*Аллаһу әгъләм* – Алла – иң яхшы белүче

*Аллаһуммә әгыйнни галә мөнкәратил-мәүти вә сәкәрәтил-мәүти* – йә, Аллам, миңа үлем алдындагы кыенлыкларны һәм газапларны кичерергә ярдәм ит

*андак* – шундый

*аслан* – бер дә, беркайчан да, һичбер вакытта

*ахирел-әмер* – ниһаять, ахыр чиктә

*ахиһи* – ир туганы

*әвамир вә нәваһисендә тәкъсыйр итмәк* – кушканнарын һәм тыйганнарын үтәмәү

*әгузү билләһи минәш-шәйтанир-ражҗим* – таш белән куылган шайтаннан качып, Аллага сыенам

*әгъкаб* – варислар, дәвамчылар

*әгъшар* – гошерләр, гошер сәдакалары

*әда кылгучы* – башкаручы, үтәүче

*әдна* – аз

*әй, кәнү фи әмрид-дөнья тәвасу бил-Хаккый* – дөнья эшләренә килгәндә, алар бер-берсенә нәсихәт бирә

*әйләмәясезләр* – итмәгез

*әйям* – көннәр

*әкариб* – якыннар

*әл* – кул

*әл имза* – имза

*әлхаль* – хәзер

*әлхәмде Лилләһи Раббил-галәмин вәл-гакыйбәтү лил-мөттәкыйн вәс-саләтү вәс-сәлләмү галә сәйидина Мөхәммәдин вә али сәйидина Мөхәммәдин вә алиһи вә әсхабиһи әл-кирам* – ике дөньяның хуҗасы Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр булсын. Һәм тәкъва бәндәләргә хәерле ахырлар сорыйбыз. Сәетебез Мөхәммәткә һәм аның барлык нәсәбенә, барлык хөрмәтле сәхабәләренә сәламнәр булсын

*әмәнтү билләһи вә мәляикәтиһи вә күтүбиһи вә рәсүлиһи вәлйаумил-ахири вәл-кадәри, хәйриһи вә ширриһи мин Аллаһу Тәгалә вәлбәгъси бәгъдәл-мәүт* – Аллаһыга һәм аның фәрештәләренә, китапла-

рына, пәйгамбәрләренә, кыямәт көненә, тәкъдиргә, Аллаһы Тәгаләнең хәерле эшләренә, мәетләрнең үлгәннән соң терелүләренә иман китердем

*әмвале наимә вә әнгаме саимә* – күчемле һәм күчемсез милек

*әмваль* – мал-мөлкәт

*әмляк* – милекләр, мал-мөлкәт

*әмре мәгъруф вә нәһи гань әл-мөнкәр* – кушылган изге эшләр һәм тыелган гөнаһлы гамәлләр

*әмтига* – мал-мөлкәт, товарлар, җиһазлар

*әр* – ир

*әрбабенә тәслим идәсәз* – ияләренә тапшырыгыз

*әрбир* – әйбер

*әркян* – нигез

*әркяне пәнҗгянәи ислам* – исламның биш вакыт намаз нигезләре

*әсбаб* – кирәк-яраклар

*әүвәлән* – беренчедән

*әүляд* – балалар

*әүляде сыйгар* – кечкенә балалар

*әфзаль* – өстен

*әһле бәйт* – хатын, җәмәгать

*әһле кобу*р – кабер әһелләре, мәетләр

*әһлес-сөннәт вәл-җәмәгать тарикы* – сөнни мәзһәбе

*әһле тарикать* – тарикать әһелләре, ишан-суфилар

*әһлия* – хатын

*әшкярә* – ачык

*әшһәдү әл-лә иләһә иллә Аллаһу вәхдәһү лә шәрикә ләһү вәл-мәлик вә ләһү әлхәмдү йухи вә йумит вә Һуа Хәййү лә йәмүт би-йәдиһил-хәйру вә Һуа галә көлли шәйин Кадир. Вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү. Аллаһу Әхәд, Аллаһус-Самәд; Ләм йәлид вә ләм йүләд; вә ләм йәкүлләһү куфүән Әхәд* – шәһадәт бирәм – хакыйкатьтә Аллаһыдан башка илаһи зат юк, ул бердәнбер, аның тиңе һәм иптәше юк, ул барлык нәрсәләрнең хуҗасы, ул үлми, мәңгелек, хәерле эшләр аңа хас һәм ул бөтен нәрсәгә дә кодрәтле. Шәһадәт бирәм – хакыйкатьтә Мөхәммәт – аның колы һәм илчесе. Аллаһ – бердәнбер, Аллаһ – мохтаҗ булмаучы, ул тудырмаган һәм тудырылмаган, һичкем аңа тиң түгел.

*әшһәдү әл лә иләһә иллә Аллаһу вәхдәһү, лә шәрикә ләһү вә әннә Мөхәммәдән рәсүлуллаһ, вә әннәл-җәннәтә вән-нарә вәс-сиратә вәл-мизанә вә сөалә Мөнкир вә Нәкир вә газабел-кабри лил-кяфирин вә ли-бәгъзи госсатил-мөэмининә вә тәнгыйми әһлит-тагати фил-кабри би-ма әрадә Аллаһу Тәгалә көлләһә хаккун* – шәһадәт бирәм – хакыйкатьтә Аллаһыдан башка илаһи зат юк, ул бердәнбер, аның тиңе һәм иптәше юк һәм хакыйкатьтә Мөхәммәт – аның колы һәм илчесе, шулай ук җәннәтнең һәм тәмугның, сират күперенең һәм мизан-үлчәүнең, Мөнкир белән Нәкир сорау алуының, кяферләр өчен һәм кайбер гөнаһлыларга

кабер газабының, итагатьле-диндар мөэминнәргә нигъмәтләр булачагына, Аллаһының теләгәне – хак

*ба-сафа* – гөнаһсыз
*батыйль* – ялган, бозык, яраксыз
*бахосус* – бигрәк тә
*ба-хөлус* – ихлас белән
*бәгъдә, бәгъдендә* – шуннан соң, соңында
*бәгъзе* – кайбер
*бәдәл* – хак, бәя
*бәдәле хаҗ* – ялланып хаҗга бару
*бәдәне зәгыйфь* – зәгыйфь бәдән (гәүдә)
*бәдкяр* – бозык кеше
*бәҗәд* – җитди, таләпчән
*бәка иман* – мәңгелек иман
*бәкъиә мәһәр* – мәһәрнең калган өлеше
*бәндәи гасый мокассир* – гөнаһлы, кимчелекле бәндә
*бәрҗа* – ирештерү
*бәхеш* – бүләк
*бәһре вәҗеһ талибе Хакны ирзага сәгый идәсез* – Аллаһының таләпләрен һәрберсен үтәргә тырышыгыз
*беткүнчә* – беткәнче
*би-вәҗһиш-шәргъ* – шәригать нигезендә
*би-гайри ифрат-тәфрыйт вә би-гайри исраф вә тәкътир* – капма-каршы чикләрдән һәм исраф итү белән саранлыктан сакланып
*бидгать вә зыйлләт* – пәйгамбәр заманыннан соң чыккан дин эше һәм түбәнлек
*билфараз* – әгәр
*бил-Хаккый вә тәвасу бис-сабри (Коръәннең «Әл-Гаср» сүрәсендәге 3 нче аятьтән)* – бер-берләрен хакка һәм сабырлыкка өндәгән
*биля гозер* – гозерсез
*биля җәбер* – җәберләмичә
*биля икраһ* – ирексезләмичә
*биля тәваккыф вә ля мөнакашә* – тоткарлыксыз һәм бәхәссез
*бина* – нигез, терәк
*бине, ибне* – улы (мәсәлән, Гали бине Сабир – Гали Сабир улы)
*биршук* – озынлык үлчәү берәмлеге, рус телендәге «вершок» сүзе
*бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим* – рәхимле, шәфкатьле Аллаһының исеме белән
*бителде* – язылды
*бихозур* – кәефсез
*би-хөрмәти сәйидел-мөрсәлин* – пәйгамбәрләрнең сәиде-юлбашчысы хөрмәтенә

*булмайа* – булмас
*булус* – волость

*важибел-вөжүд* – барлыгы шиксез булган
*вакыйг улган* – килеп чыккан
*варан* – барган
*вармагай ирдең* – бармасаң иде
*васый* – васыять итүче; васыятьне үтәүче вәкил
*васый мөхтар* – васыятьләрне үтәүче
*«Вә әннә әс-сагатә атийәтүн лә рәйбә фиһа вә әннә Аллаһә Тәгалә йәбгасү мән фил-кобури» (Коръәннең «Әл-Хаҗ» сүрәсендәге 7 нче аять)* – һәм шул сәбәпле сәгать, һичшиксез, киләчәк, аңарда бернинди дә шик юк. Һәм дә Аллаһ каберләрдәгеләрне терелтәчәк
